www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 25 (1390) 1 июль 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

«Әкият» курчак театрында узган «Шомбай» фестивале курчак спектакльләрендә дә көнүзәк темалар күтәреп булганын исбатлады.



12

Татарстанның халык артисты, җырчы Искәндәр Биктаһиров – тормыш мизгелләре, замана сәхнәсе, гаилә учагы турында...

19

Австралиядә яшәүче милләттәшебез Финзия Газизова җир читендәге дәүләттә тормыш үзенчәлекләрен һәм андагы татарлар тормышын бәян кыла.

Якынайтып ерак араларны, Ут күршеләр булып яшик әле!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Баулыда Санкт-Петербург рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Гыйләҗевнең картиналар галереясы ачылды.
- Чаллының Мактаулы гражданнарны, оешмаларны һәм тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү комиссиясе каланың картиналар галереясына аңа нигез салучы Гөлсабира Хәкимова исемен бирү тәкъдимен хуплады.
- Г.Камал театры Халыкара театр фестивале программасына Санкт-Петербург тамашачысына «Ирдәүкә. Мөһаҗирләр» спектаклен тәкъдим итәчәк.
- Казанның Сеченов урамында төзелә торган «Рауза» мәчетенә ай кую тантанасы узды.
- 2 меңнән артык кеше арасында уздырылган сораштыру нигезендә, Казан Россиянең иң матур шәһәрләре рейтингында өченче урынны алды.
- 5-7 августта Төмән өлкәсендә Күчем хан шәһәре – Искердә «Искер җыен» Халыкара татар мәдәни мирасы фестивале була.
- Татарстанның Халыклар Дуслыгы йорты Россия Иҗтимагый палатасында (Мәскәүдә) СССР халыклары телләрендә Бөек Ватан сугышы чорында язылган листовкаларның һәм плакатларның күчермәләреннән «Хәтерлибез!» дигән күргәзмә оештырды.
- Казан университеты докторантурасында тарихчы галим Рәшит Әмишовның революциягә кадәр яшәгән татар муллалары, ишаннары һәм абыстайларының тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган фәнни хезмәт әзерләгән.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Энгель ФӘТТАХОВ, Актаныш районының элекке башлыгы:

«Министр чагында да әйтә идем инде: балалар, ата-аналар, укытучылар – өч компонент. Белем бирү системасында берсен генә аерып ташлыйсыз икән, нәтиҗәгә ирешеп булмый. Ата-ана ул оппонент булмаска, киресенчә, үзе мәктәптән чыкмаска, балага белем алуда ярдәм итәргә тиеш».

СЫНАМЫШЛАР

3 июльдә яңгыр яуса, тагын 40 көнгә сузылачак ● 7 июльдә чык мул төшсә – кыяр уңа; йолдызлар күп күренсә – гөмбә мул була; яшенле яңгыр яуса – чикләвек уңмый ● Төш вакытында салават күпере чыкса, көн бозыла ● Коеп яуган яңгыр тиз туктый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 03 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 31 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 28 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **12 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **8 июльдә 17 сәгать 16 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

1 июль – График Гөлзирә Солтан кызы Бекташевага 75 яшь (1947);

– актер, Татарстанның атказанган артисты Фәнис Рәдиф улы Җиһаншинга 50 яшь (1972).

2 июль – филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Гомәр Фәез улы Саттаровның тууына 90 ел (1932–2020).

5 июль – филология фәннәре докторы, профессор Әлфинә Таһир кызы Сибгатуллинага 60 яшь (1962).

7 июль – инкыйлабчы, язучы, казах совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Мөхәммәтсабир Мөхәммәтшәриф улы Дәүләтшиннең (Сабир Шәрипов) тууына 140 ел 1882-1942).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 3 июль.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(29 июнь-7 июль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәкләк актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 2 нче көне

ҖАН АВАЗЫ



Рүзәл ЮСУПОВ, академик

Телебезне кадерсезләмик

Соңгы елларда туган телебезгә килгән бәла-казалар аркасында, аны кулланучыларның саны кимүен (статистика буенча, татарларның яртысыннан күбрәге үз телендә аралашмый), татар мәктәпләренең азаюын, гамәлдәгеләренең дә русча укытуга күчә баруын һәм халыкның шактый зур өлешенең милләтенә, теленә, мәдәниятенә битараф һәм тискәре карашта булуын аек акыллы кеше күрми, сизми кала алмастыр. Бу мең елдан артык тарихлы, борынгы дәүләтле, югары мәдәниятле татар милләтенең камил әдәби теленең яшәешенә җитди куркыныч яный дигән сүз.

Тел ул үзеннән-үзе генә бозылмый, аны без үзебез – бу телдә сөйләүче һәм сөйләшүче гади кешеләр дә, төрле һөнәр ияләре, шул исәптән журналистлар да – бозабыз, моңа хәтта туган телнең сафлыгы сагында беренче чиратта торырга тиешле язучылар һәм укытучылар да күпмедер дәрәҗәдә өлеш кертә. Милләтебезнең бүгенге хәленә кагылышлы ачы хакыйкать шул: телебез, бигрәк тә сөйләмебез һәм публицистика теле, көннән-көн ныграк бозыла, чүпләнә, катнаш-корама телгә әверелә бара.

Бу фикергә матбугат укучыларны азмы-күпме булса да инандыру нияте белән, нигездә, мәгълүмат чараларында соңгы бер-ике ай дәвердә хөкем сөргән тел ялгышларының, төгәлрәк итеп әйткәндә, туган телебезне бозып куллану очракларының кайберләрен күрсәтеп китәрбез, бу күренешнең барлыкка килүенең сәбәпләрен һәм телебез халәтен савыктырып саклау чараларын бәян итәрбез.

Ялгышлар күп, һәм алар телебезнең барлык өлкәләрендә дә карый. Сүзләр еш кына ялгыш мәгънәдә кулланыла, татар теленең табигый сүз төзелеше бозып ясалган лексик чаралар гамәлдә йөри, сүзләрнең сөйләмдә үзара мәгънә мөнәсәбәтләре бозыла, сүзләрнең бәйләнеш чаралары күп очракта дөрес сайлап алынмый, кулланылыштан чыгып, искергән сүзләрне тергезергә омтылу хәлләре бар, кайчакта алынма сүзләрне кабул итү тәртибе исәпкә алынмый, фигыль сүз төркемнәрен куллануда ялгышлар күп, сүзләрнең әйтелеш (орфоэпик) һәм язылыш (орфографик) кагыйдәләрен санга сукмау хәлләре дә аз түгел.

Бу һәм башка төрле күп санлы ялгышларның бүгенге көндә сөйләм һәм язма телебездә киң таралган булуының төп сәбәпләре берничә. Иң беренчесе – туган телебезне, җиренә җиткереп, бөтен үзенчәлекләре белән тулы белмәү, икенчесе – каләм һәм сүз ияләренең безнең тормышта зур урын алып торган тәрҗемә эшенең бу гамәлнең тәртибен, метод-алымнарын белмәгән кешеләр тарафыннан башкарылуы, өченчедән, татар телен дөрес куллану өчен җаваплылык булмау, дүртенчедән, милли мәгариф эшенең нәтиҗәлелегенә игътибар җитмәү.

Санап киткән факторлардан татар телен иң нык бозганы – рус теленнән ялгыш, механик рәвештә, сүзгә-сүз һәм хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү. Бу бүгенге көндә безнең мәгълүмат чараларында иң нык таралган чир. Кайбер каләм һәм сүз әһелләренең русчадан тәрҗемә иткәндә хәтта кулланган сүзләренең нинди мәгънә белдерүен үзләре дә белеп бетермичә яки аңламыйча эш итүләре гаҗәпләндерә.

«Өеңдә хайваннар тотучылар җанварларын теркәргә тиеш...». Димәк, бу җөмләнең авторы җанвар сүзенең мәгънәсен, җанварның өйдә тота торган тереклек иясе түгел икәнлеген белми.

«Ел башыннан Республика клиник хастаханәсенә хайван тешләүдән зыян күргән 125 бала мөрәҗәгать иткән. Балаларның 82 сен-эт, 34 ен – песи, 9 ын – елан, куян, тычкан тешләгән». Беренчедән, елан чага, икенчедән, елан белән тычканны хайван дип атамыйлар бит.

Шушы араларда республикабызның төп газетасында «Тамашачыны яратырга кирәкми, аны хөрмәт итәргә кирәк» дигән мәкалә басылды. Нәрсә уйлап язган моны автор, һәм ни уйлап бастырганнар мондый сүзләрне?! Тамашачыны ни өчен яратырга кирәкми икән?! Мондый гамәлләр дә тыелганмы икән инде әллә?!

«Коронавирус белән 26,8 мең кеше авырган, шуларның 23,1 меңе терелгән». Автор, савыккан, тазарган сүзләрен белмичә, терелү сүзен ялгыш кулланган. Клиник үлем кичергән кешеләргә карата гына кулланылырга тиешләр бу сүз.

«Табигый фәннәр академиясе» дип язалар еш кына. Тупас хата бу. «Табигать фәннәре» диярга кирәк.

«Су каланчасы» дип язалар, дөресе – «су башнясы». Каланча ул бөтенләй икенче нәрсә.

«Бабаларыбызның теле» (Язык предков). Ни өчен бабаларыбызныкы гына икән ул телебез. Әбиләр булмадымы икән әллә элек? «Әби-бабаларыбыз теле» диярга кирәк ләбаса.

«Коронавирус бирмәгән сабак» – мәкалә исеме. Коронавирус сабакны биргән, аны ала белмәү турында барадыр сүз. «Коронавирустан алынмаган сабак» яки «Коронавирустан сабак ала белмәгәннәр» дип әйтергә кирәктер.

«Былтыр Россия халкы телефон мошенникларына 136 миллиард сум акчасын биргән. Бу аннан алдагы елдан 39 процентка күбрәк». «Алдагы елдан» түгел, «элекке елдан, өченче елгыдан» диярга кирәк иде.

Уйлап тормыйча эш итү мисалы: «Әйе, юк сүзләренең мәгънәсен һәм вазифасын ачыклау». Сүзләре булгач, мәгънәсе һәм вазифасы гына була алмый, мәгънәләре, вазифалары булырга тиештер бит инде!

Менә бу җөмлә дә – шулай уйлап тормыйча гына эшләү мисалы: «32 буын туганын ачыклаучы гаиләләр бар». 32 буын булгач, туганын гына диярга кирәк идеме соң, ни өчен туганнарын түгел?! Сыйфат фигыль формасы да уңышсыз кулланылган: «ачыклаган гаиләләр».

Телебезгә ялгыш тәрҗемә итү аркасында килеп кергән кыйммәтләр (ценностидан калька) сүзе кулланыла. Кыйммәт ул – дорогой, ә ценность – хәзинә, байлык, мал. Димәк, духовные ценности сүзтезмәсен рухи кыйммәтләр дип түгел, рухи хәзинәләр дип тәрҗемә итәргә кирәк.

Телебездә җиңел генә эшләргә ияләнгән кайбер каләм ияләренең «иҗат җимеше» сылтама сүзе йөри: «РИА Новости тикшеренүләренә сылтама белән хәбәр итәнчә...». Сылтама – безнең телдә гаебеңне яки ялгышыңны икенче кешегә сылтау мәгънәсендәге фигыль сүз, ә бу фраза «РИА Новости тикшеренүенә таянып хәбәр итәнчә...» рәвешендә төзелергә тиеш.

Һәвәскәр тәрҗемәче-журналистларның дөрес эшләмәве аркасында, ялгыш мәгънәдә кулланыла торган сүзләрнең берсе – чакыру. Күп каләм әһелләре призвать (призывать) мәгънәсен шушы сүз белән тәгъбир итә. Бу зур ялгыш. Мәсәлән: «С.Лавров Россия-Украина сөйләшүләренең акрын баруы турында белдерде. Ул моны Украина хәбәрләренең «Азовсталь»дәге хәле белән бәйләп карамаска чакырды». Монда сүз бернинди чакыру турында да бармый. Оригинал мәгънәсе «Ул моны Украина хәбәрләренең «Азовсталь»дәге хәле белән бәйләп карарга кирәкми диде» рәвешендә белдерелергә тиеш.

«Аның (Василий Лихачевның – **Р.Ю.**) Татарстанга килүе югары университет белән бәйле» дип язып чыкты күптән түгел статусы буенча җитдиләрдән саналган бер газета. Нинди уку йорты икән ул «югары университет» һәм югарысы булгач, түбәне дә буламы икән университетның? – дип сорыйсы килә.

«Татарстан юлларында 1 апрельдән 30 ына кадәр авыр йөк машиналары хәрәкәте чикләнә». Бу, русчадан калькалаштырып, ягъни рус синтаксисы өлгесендә язу: ограничивается движение машин – машиналар хәрәкәте чикләнә. Движение ул – хәрәкәт кенә түгел. Бу җөмләне гади генә, саф татарча итеп: «...йөк машиналарын йөртү чикләнә» яки «йөк машиналарын йөртү туктатылып тора» дип төзергә кирәк иде.

Чын татарча машина йөри, поезд йөри, самолет йөри дип әйтелә. Әмма журналистлар еш кына, туган телнең андый үзенчәлекләре белән исәпләшеп тормыйча, рус теленнән хәрефкә-хәреф (механик рәвештә) тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Мәсәлән: «9 апрельдән Казаннан Минск шәһәренә атнага ике тапкыр самолет оча башлаячак», «... самолет йөри башлаячак» дисәләр, татарча дөресрәк булыр иде.

«Этләрнең балаларга һөҗүм очраклары булгалады». Бу җөмлә дә – русчадан ялгыш тәрҗемә. Саф татарча: «Этләрнең балаларга ташлану (яки балаларны талау) очраклары булгалады».

(Дәвамы 4 нче биттә).

КИЛӘЧӘКНЕ БҮГЕНГЕ БИЛГЕЛИ

Күпләргә мәгълүм бу гыйбарә үз асылы белән әле универсаль да: мәгънәви яктан ул, шәхси яки күмәк планда гына түгел, дәүләти дәрәҗәдә һәм хәтта кешелек дөньясының киләчәге өчен дә хак. Зурдан алганда, милләтнең дә киләчәген аның бүгенге хәле, милли аңда кыйммәтләр системасының рухи, әхлакый, хокукый һәм иҗтимагый-сәяси куелышы билгели. Бу язмада исә, югары вазифалы бериш затларның бүгенге хәлләргә карата әйткәннәренә таянып, халыкара мөнәсәбәтләрне тирән кризис шартларында җайга салуның уртак якларын һәм гомуми принципларын чамалап карарбыз. Ә гадәти халыкара мөнәсәбәтләргә кискен диссонансны Украинада башланган махсус хәрби операция кертте. Россия президенты В.Путин аның максатын, Киевтәге режим тарафыннан соңгы 8 елда Донбасста геноцидка дучар ителгән халыкны яклау, дип аңлатты. Сонрак, БМО генераль секретаре А.Гутерриш белән очрашканда, ул аның БМО уставына туры китереп башлануы турында да әйтте. АКШ президенты Джо Байден исә Украинадагы ул кризисны тарихтагы борылыш дип бәяләде һәм мондый хәл якынча 6-8 буынга бер генә туры килүен искәртте. Аныңча, Украинадагы вакыйгалар бүгенге дөньяда демократия һәм автократия арасында тәүге реаль бәрелеш булып тора. Ә РФ Иминлек шурасы сәркатибе Н.Патрушев әйтүенчә, Көнбатыш һәм Киев режимы үткәргән сәясәт нәтиҗәсендә Украина берничә дәүләткә таркалырга мөмкин. Шул ук вакытта, АКШ Дәүләт департаменты башлыгы Э.Блинкен бүген дөньяви тәртипне үзгәртергә сәләтле бердәнбер ил дип Кытайны атады. Күренә ки, фикер-карашлар каршылыклы һәм алар ниндидер уртак мантыйкка сыеп та бетми кебек. Әмма, ни гаҗәп, «Соломон планы»на алар тулысынча җавап бирә. Ә бу инде – Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүенә янә бер дәлил.

Белүебезчә, моңа кадәр дөньяви тәртип һәм халыкара мөнәсәбәтләргә кагылышлы мәсьәләләр белән БМО шөгыльләнде. Дөнья тотучылар өчен ул, асылда, глобальләштерү сәясәте механизмы ролен дә үтәде. Әмма аның нигезенә хокук көче түгел, ә көч хокукы өстенлеге принцибы салынган иде. Бу аның структурасында да (Куркынычсызлык Шурасында даими әгъзалар булып атом-төш коралына ия 5 дәүләт торуы һәм аларның вето хокукына ия булуы), эш принципларында да (БМО КШ карарларының үтәү өчен мәҗбүри булуы, ә Генераль Ассамблея карарлары киңәш дәрәҗәсендә генә калуы һ.б.) беркетелгән иде. Әмма, күренә ки, бүген инде мондый хәл планетада гаделлек һәм хокук өстенлеге принципларына җавап бирми һәм иминлек гарантиясе дә була алмый. Шуңа ул, БМО эшчәнлегендә генә түгел, халыкара хәлләрдә дә тирән кризиска китерде.

Россия тышкы эшләр министры С.Лавров мондый хәлне БМО өчен хакыйкать мизгеле буларак бәяләде һәм аны үзенчә: йә кешелек дөньясы БМО уставы буенча яши, йә һәммәбез дә кемнәрдер тарафыннан тагылган кагыйдәләргә буйсынып яшәүгә күчәбез, дип аңлатырга тырышты. Әлбәттә, аны аңларга була. Чөнки бүгенге устав Мәскәүгә вето хокукын калдыра. Бу исә аңа империячел мин-минлегенә җавап бирми торган карарларны (гәрчә алар халыкара планда мөһим булса да) үткәрмәү мөмкинлеге бирә. Бүген халыкара мөнәсәбәтләрдә күзәтелә торган тирән кризис нәкъ шуның белән аңлатыла да. Ә даими әгъзаларны БМО КШ дан чыгару механизмы уставта каралмаган. Шулай булгач, мондый гайре хокукый хәлдән чыгуның бер генә юлы кала: БМОны хокукый нигездә реформалау. Димәк, аның нигезенә көч хокукы түгел, ә хокук көче салынуы лязем. Әлегә исә БМОга Куркынычсызлык шурасының 5 даими әгъзасын (АКШ, Бөекбритания, Кытай, Россия һәм Франция), вето хокукын кулланган очракта, аның сәбәбен аңлатып бирергә чакырган резолюция кабул итү белән генә чикләнде. БМО ГА рәисе моның өчен 10 көн эчендә ГА сессиясен җыярга тиеш була. Ә БМОны хокукый реформалау өчен башка сәбәпләр дә бар. Әйтик, 2021 елда дөньяда хәрби чыгымнар 2,113 триллион доллар булган. Шул ук вакытта Җирдә йөзләрчә миллион кеше ачлыктан изалана. Илаһият кануннары буенча яшәгәндә, андагы ресурслар, юкса, планета халкын бар яктан да тәэмин итәргә җитәрлек. Димәк, Җирдә гаделлек вә иминлек тантанасы аша да гармониягә ирешү өчен, БМОны бүген илаһият кануннары өстенлеген тәэмин итү механизмы итеп тә реформалау мәслихәт.

Фоат УРАЗАЙ.

Каһарманнар китабы



Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге «Батырлар аллеясы» китабын тәкъдим итте. Китап Татарстан Дәүләт Советы «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлары берләшмәсе Әлки районы «Якташлык» җәмгыяте белән берлектә батырларны мәңгеләштерү уңаеннан нәшер ителгән.

«Батырлар аллеясы» китабының проект авторы – Россия кооперация университеты ректоры Алсу Нәбиева, автор-төзүче – Флюра Абдуллина, мөхәррире Нәфисә Габдрахманова. Рамилә Мансурова Россиянең Саклау министрлыгының «Халык хәтере» сайтыннан документлар туплаган.

«Казан кооператив институтының «Батырлар аллеясы»нда татар генераллары, Советлар Союзы геройлары, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре, язучы, композитор исемнәре куелды. Рейхстагка Җиңү байрагын беренче булып кадаган Гази Заһитов, ике тапкыр Советлар Союзы Герое булган Муса Гәрәев һәм Әмәтхан Солтан фотосурәтләре, алар турында мәгълүмат урнаштырылды», – диде Флюра Абдуллина.

Китап бәйрәменә Советлар Союзы Герое Зәки Хәбибуллинның кызы Әлфия Хәбибуллина, Советлар Союзы Герое Зәки Шәймардановның кызы Рушания Шәймарданова, Абдулла Алиш туганнары – Гөлшат һәм Азат Сөнкишевлар, Абдулла Батталның туганы Фәрит Батталов, Зиннәт Хәсәновның туганы Зина Якупова, Барый Шәвәлиев туганы Фәрит Шәвәлиев, Шәйхи Маннурның оныгы Камилә Тимпакова да килгән иде.

Алар китапны нәшер итүчеләргә рәхмәтләрен җиткереп, «Батырлар аллеясы» китабын татарлар яшәгән төбәкләрдә тәкъдим итү киңәклеге турында әйтте.

Кичәдә «Хәтерләрне яңартып» бәйгесенә нәтиҗә ясалды. Әлки, Буа, Кукмара районнары, Казан мәктәп укучылары батырлар тарафыннан язылган шигырьләрне сөйләгән. «Әлки районыннан Лилия Әһлиуллина җитәкчелегендә укучылар килгән иде. Шулай ук мәктәп укытучылары, мәдрәсә мөгаллимәләре, ата-аналар катнашты», – диде ул.

Кичәдә тарихчы галимнәр, язучылар һ.б. да катнашты.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

«Сәләт»тә һөнәрләр форумы

Биләр тарихи-археологик музей тыюлыгы территориясендә, XI Халыкара «Сәләт» яшьләр уку-укыту форумының беренче сменасы – «Һөнәрләр – Биләр-Форум»ның ачылыш тантанасы узды.

«Минем бу искиткеч урынга, әйдаманнарга һәм, әлбәттә инде, барлык катнашучыларга чиксез рәхмәтемне белдерәсем килә. Сездән башка бу форум булмас иде», – дип билгеләп үтте сәламләү чыгышында «Сәләт» яшьләр үзәге директоры Айгөл Габдрахманова.

Тел мохитендә татар телен өйрәнүнең әһәмияте турында «Адымнар - Алабуга» полилингваль белем бирү комплексы директоры Надир Курамшин сөйләде. «Әйдәгез, шушы дүрт көн эчендә татар телебезне бергәләп шомартыйк. Бүген сменада 700 бала, сез барысы белән дә таныша аласыз. Шуның йөзе белән генә булса да аралашып карагыз, тел байлыгыгыз ничек яхшырачагын күрерсез», – диде Н.Курамшин.

Смена ачылышында Malsi Music, Ilgiz һәм Zarina башкаруында «Сәләт» форумының «Ау» җыры тәкъдим ителде.

Форумның беренче сменасы укучыларның яңа һөнәрләр өйрәнүенә багышланган. Бу көннәрдә экология, IT һәм робототехника буенча остаханәләр узачак. Һөнәри сменада фән олимпиадалары, фәнни конференцияләр һәм иҗади фестивальләр җиңүчеләре һәм призерлары, «Адымнар» белем бирү комплексының 6-11 сыйныф укучылары, шулай ук «Сәләт»нең «Сәләт–Болгар–Туган тел» профильле сменасына сайлап алуны үткән балалар катнаша.

Мәдәният министры Ирада Әюпова Н.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы директоры Ольга Гыйльметдинова белән бергәләп әлеге уку йорты бинасы буйлап матбугат вәкилләре өчен экскурсия уздырды.

Рәссамнар мәктәбенә акча кирәк

Мәдәният министры Казан училищесы тарихы, исемнәре әлеге бина белән бәйле Мюфке һәм Фешин, гомумән, бу уку йорты зур өлеш керткән шәхесләр турында сөйләде. Импортны алыштыру мәсьәләсенең һәрвакыт актуаль булуын ассызыклап, И. Әюпова бинаның бары тик үзебездә җитештерелгән материаллардан гына төзелгәнлеген искә алды.

Карл Маркс урамындагы әлеге бинаның бер ягы төзекләнделгән хәлдә. Аның яңартылган көньяк тарафында студентлар укый. Аерма яхшы күренсен өчен, журналистларга бинаның төзекләндерелгән һәм әлегә ремонт күткән өлешләре күрсәтелде.

Бинаны тулысынча төзекләндерү өчен тагын 600 млн сумнан артык акча таләп ителә. Әлегә ремонт эшенең вакыты һәм аңа акча бүлеп бирелү турында анык мәгълүмат юк.

Ирада ханым хәбәр иткәнчә, сынлы сәнгать училищесы кысаларында яңа уку елыннан Креатив индустрияләр мәктәбе эшли башлаячак.

«Креатив индустрияләр мәктәбе – бюджет нигезендә өстәмә белем бирү максатларында башланган федераль проект. Аның безнең училищеда ачылуы – дизайн буенча эш тәҗрибәбез булуы һәм бөтен Россия буйлап дизайнерлар белән хезмәттәшлек итүебез», - диде училище директоры.

Креатив индустрияләр мәктәбендә 12-16 яшьлек балалар бушлай белем алачак. Укырга керүчеләр өчен сынаулар каралмаган. «Без укучылар кабул итү турында игълан иткәч, кем гариза биреп өлгерә – шул эләгә», – диде О. Гыйльметдинова. Училище карамагындагы мәктәптә виртуаль чынбарлык, дизайн, анимация һәм мультипликация, фото-видеопродукция студияләре эшләячәк.

Истәлекле стела

Кузбасста Идел буе Болгарстанында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган күп чаралар узды. Шуларның берсе – Кемерово шәһәренең Җәмигъ мәчете территориясендә истәлекле стела ачу.

Ул «Болгар – Көнчыгышка юл» проекты кысаларында Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды һәм мөфти Әлбир хәзрәт Крганов булышлыгы белән урнаштырылды.

Стеланың бер ягында Себер җирлегендә исламның таралышы турында хәбәр, икенче як Идел буенда 922 елда булган мәшһүр вакыйгаларның Россия өчен әһәмиятенә игътибарны юнәлтә. Истәлек билгесендә шулай ук Коръән сүрәләреннән аятьләр китерелгән.

1 нче биттә – Саха (Якутия) Республикасында Татарстан көннәре кысаларында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ысыах Туймаады якут милли бәйрәмендә катнашты.

Якут кардәшләрдә кунакта

Узган атнада Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре узды.

●Якутиядә узган Сабан туенда А. Николаевны чәкчәк белән сыйладылар.

Шул уңайдан Якутскига Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә хөкүмәт, парламент вәкилләреннән, әдәбият-сәнгать эшлеклеләреннән, эшмәкәрләрдән һ.б.дан гыйбарәт зур делегация килде. Ике республика җитәкчесенең очрашуында сүз нефть, газ, химия тармагы, машина, суднолар төзелеше, агросәнәгать комплексы предприятиеләренең хезмәттәшлеге, шулай ук азык-төлек продуктларын китерүне киңәйтү мөмкинлекләре, мәгълүматлаштыру һәм исәпләү техникасы белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлек перспективалары турында барды. Рөстәм Миңнеханов Саха (Якутия) башлыгы Айсен Николаевка төбәктә татар җәмгыяте эшчәнлегенә һәрьяклап ярдәм итүләре өчен рәхмәт белдерде. Бүген биредә 8 меңнән артык татар яши.

Очрашу кысаларында А.Николаев Татарстан Президентына Якутия АССР төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан беренче медальне тапшырды. Бу көнне җитәкчеләр якут совет язучысы, тарихта якутлардан туган тел өлкәсендә беренче галим Платон Ойунский һәйкәленә чәчәкләр салды.

Р.Миңнеханов Якутскида «Казан» скверын ачуда катнашты.

«Бу – барлык ватандашлар өчен дә мөһим вакыйга, чөнки Саха (Якутия) башкаласында якташлар очрашуы, мөһим чаралар уздыру урыны – татарлар өчен яңа әһәмиятле урын барлыкка килә», – диде Президент, чарада катнашучыларга мөрәҗәгать итеп. Скверда каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелачак.

Эш сәфәре кысаларында Р.Миңнеханов Саха (Якутия) Республикасының татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре белән очрашты, «Татарларда кунакта» күргәзмәсендә булды. Күргәзмә Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы фондларыннан оештырылган һәм Якутиянең Милли сәнгать музеенда ачылган.

Якутиянең Меңге-Хангалас районының Мэлдьэхси авылы янында саха халкының милли каһарманы, 1920-1930 елларда саха халкының азатлык өчен көрәш әйдаманнарының берсе, милләт тарихында таш күтәрү һәм хапсагай көрәшендә тиңдәшсез батыр Боссоойкога истәлек тактасын ачу булды.

Боссоойконың (1883–1930) чын исеме – Гыйззәтулла Рәхмәтуллин. Татар кешесе. Хатыны Латыйфа белән өч кыз һәм ике ул тәрбияләп үстерәләр. Аның этисе Гафиятулла бу якларга сөргенгә сөрелгән була. Аны сахалар бик хөрмәт итә, «Тулла татар» дип атыйлар. Улы Гыйззәтулланы исә, ике метр озынлыктагы буе һәм көчле булганы өчен, зур (большой) – «Боссоойка» дип атаганнар.

Язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин әлеге шәхес турында 2015 елда «Боссоойко» исемле хикәя язды. Аны саха язучылары якут һәм рус телләрендә бастырып чыгарды.

Әлеге чарада күренекле саха язучылары, журналистлары, җитәкчеләр, Боссоойконың якташлары һәм Татарстан кунаклары катнашты. Киләчәктә Боссоойкога һәйкәл кую һәм аның музеен төзү турында сүз алып барылды.

●Боссоойкога истәлек тактасы ачылышында.

Ялкынлы шәхес иде

Татар җәмәгатьчелеге узган атнада зур югалту кичерде. Җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, «Мәдәни җомга» газетасының даими укучысы һәм авторы Фатих Сибагатуллин вафат булды.

Фатих Сәүбән улы 1950 елда Татарстанның Арча районы Апаз авылында туа. Казан ветеринария институтын тәмамлый. Казан дәүләт финанс-икътисад институты, Саратов югары партия мәктәбе һәм Казан дәүләт финанс-икътисад институтында да белем ала.

1990-1995 елларда республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын җитәкли, 1995-1996 елларда Татарстанның Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры була. 1996 елдан 2007 елга кадәр Нурлат районы җитәкчесе булып эшли, 2007 елның декабрендә РФ Дәүләт Думасына сайлана.

«Иң тәҗрибәле һәм абруйлы җитәкчеләрнең берсе иде, гомер буе туган җиренә тугры һәм нәтиҗәле хезмәт иткән, республиканың күп кенә районнарын үстерү өчен, гомумән, агросәнәгать комплексы һәм Татарстан икътисады потенциалын арттыру өчен күп эш башкарган кеше.

Россия Дәүләт Думасында Фатих Сәүбән улының күп еллык актив эше иң актуаль республика мәсьәләләрен хәл итүгә дә, Россия дәүләтен ныгытуга да зур өлеш керттe», – диелә Татарстан Президенты кайгынамәсендә.

Ф.Сибагатуллин белән хушлашу Игенчеләр сараенда узды. Җәсәде туган авылында җир куенына иңдерелде.

Телебезне кадерсезләмик

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

«Уку йорты өчен «татар мәктәбе» исемен йөртү аеруча җаваплы. Бигрәк тә шәһәр җирлегендә». Икенче җөмләдә җирлек үз мәгънәсендә кулланылмаган: «шәһәр җирендә» яки «шәһәрдә» генә дияргә кирәк. Соңгы елларда җирлек сүзен бөтенләй үзенә хас булмаган мәгънәләрдә куллану гадәткә керде.

Бу язмабыз темасы уңаеннан бер мәгълүмат хакында әйтеп китү зарур. Күптән түгел абруйлы республика газетасында Казан шәһәреннән Фәрит Мөслимов дигән кеше «Ленин яклауга лаек түгел» исемле кечкенә генә хәбәрендә «Ленин – иң кабахәт кешеләрнең берсе. Акыллы булса да, явыз ул», дип язып чыкты. Бу әфәндегә шундый киңәш бирү мәгъкуль. «Җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән халык мәкален сөйләмебезгә карата да куллану зыянлы булмас иде. Сүзне үлчәп, сак сөйләргә кирәк. Дөньяның күп илләренә, халыкларына мәгълүм пролетариат юлбашчысын кабахәт дип атау – акыллы гамәл түгел. Ленинны яхшы беләме икән, аның хезмәтләрен укыганы бармы икән ул авторның?! Мондый сүзне башка берәүгә карата әйтсәң дә, Ленин турында әйтү – зур әдәпсезлек; бу бөек шәхесне, аның тау кадәр хезмәтләрен, казанышларын белмичә сөйләү. В.И.Ленин – Россиядә пролетар революция оештырган кеше, беренче социалистик дәүләт җитәкчесе. Ул төзеп калдырган Советлар иле зур казанышларга ирешә. Совет илендә татар халкының, аның мәдәниятенең, мәгарифенең үсеше өчен мөмкинлекләр зур иде. Мәсәлән, әле Сталин исән чагында һәр авылда татар мәктәпләре нәтиҗәле эшләп килде, Казанда да берничә саф татар мәктәбе бар иде, хәтта рус телендә укытыла торган техникумнарда да татар теле өйрәтелде. Сугыштан соңгы авыр елларда да, татар халкының рухи тормышы алга барсын өчен, күп нәрсәләр эшләнде. Тарихны яхшы белергә һәм җитди фикерләрне, бик уйлап, инанып кына әйтергә кирәк.

Төп темадан читкәрәк китүебез өчен укучылардан гафу үтенеп, телебездәге төгәлсезлекләр турында фикеребезне телебезне куллануда мәгънә ялгышлары шактый күп, һәм сөйләмебезгә игътибар җитми дип йомгаклыйк.

●Һиндстанның Чандигарх шәһәрендә бай адвокат җәмәгате белән аерылышкач, суд аны ай саен 25 мең рупия түләп барырга йөкләгән. Ир-ат әлеге хөкемне үтәмәгәч, элекке хатыны югарырак судка биргән һәм барыбер үз дигәненә ирешкән. Ире аңа йөз рупиялек дүрт купюра һәм вак тәңкәләр белән авырлыгы 70 килограммнан арткан 24,6 мең рупия китереп биргән. Алиментны вак акча белән түләвеннән зарланып, хатыны тагын судка биргән, әммә бу юлы мәхкәмә ирнең гамәлендә законсызлык тапмаган.

●Бүгенге көнгә Марс өслеге Җирдәге океан төбенә караганда яхшырак өйрәнелгән.

●Космоста йолдызлар саны Җирдәге ком бөртекләреннән күбрәк.

●Төчкергәндә, организмдагы бөтен функцияләр, хәтта йөрәк тә туктый.

Һәлак булганнар хәтердән җуелмасын

Бөтендөнья татар конгрессының конференцияләр залында Татарстанның төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте белән берлектә сугыш, кораллы көчләр һәм хезмәт ветераннары, галимнәр, туган якны өйрәнүчеләр, җәмәгать эшлеклеләре һәм гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Татарстанның һәм татарларның җиңүгә керткән өлеше» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды.

Программа кысаларында Бөек Ватан сугышы ветераны Харис Салихҗанның «Чутай бабай малайлары», һәвәскәр тарихчы Фәргать Әхмәтшинның Россия Герое Марат Әхмәтшинның тормыш юлына багышланган «Без – Кубрат хан оныклары», Татарстанның «Хәрби дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепановның «Нет в России семьи такой» (Бөек Ватан сугышында татарлар һәм татарстанлыларның батырлыгы турында) китаплар сериясе тәкъдим ителде.

«Хәрби дан клубы» ассоциациясе рәисе М.Черепанов Бөек Ватан сугышына бәйле катлаулы мәсьәләләрнең әле дә ачылып бетмәве турында ачынып сөйләде. Россиядә хәбәрсез югалучылар исемлегенә теркәлүчеләр хәзергә кадәр юридик яктан һәлак булучы дип саналмый. Безнең көннәрдә дә Татарстан җирләреннән яу кырына киткән һәм Кызыл Армия составында сугышкан 145 мең кешенең ничек һәлак булуы һәм җирләнгән урыны билгеле түгел. М.Черепанов бу хәлне – тарихыбызның һәм тормышыбызның гаделсезлеге дип белдерде. «Әгәр кеше вафат, дип исәпләнми икән, бу аның исән булуын аңлата, ягъни ул кеше хыянәтче булып чыга. Хәбәрсез югалган бу кеше 80 ел дәвамында кайда йөргән, нинди җирләрдә качып яткан соң? Әгәр дә ул сугышка, туристик сәфәргә дип китмәгән икән, фронтта һәлак булган дигән сүз. Әлбәттә, бу – дәүләт эше. Закон буенча, әлеге мәсьәлә белән шул кешенең туганнары шөгыльләнергә тиеш. Әмма хәзер аларның барысы да өлкән яшьтә, бу әбкәй-бабакайларның моңа сәламәтлеге дә, дәрманы да җитми», – диде ул.

2019 елның ноябреннән «Хәрби дан клубы»ның эшче төркеме тарафыннан эзләнүләр барышында Татарстан автономияле республикасында туган һәм хәбәрсез югалган дип исәпләнүче 34 мең 300 сугышчының кайда һәм ничек һәлак булуы турындагы мәгълүматлар ачыкланган. Бу хактагы хәбәрләр архивларда яшерелгән булган, алар күптән түгел генә серләрен ачкан һәм анда сакланган документлар Россия оборона министрлыгы «Халык хәтере» сайтында басылып чыккан. Бу эш Татарстан Президенты кушуы буенча башкарылган. «Бу әле генә ачыкланган исемлек тарала башлады. Ул мәгълүматлар һәр гаиләгә барып җитсен иде», – диде М.Черепанов.

Россия оборона министрлыгы сайтларында казынып эзләү 29 мең кеше турында бернинди мәгълүмат бирмәгән. Бу документлар «Үтә яшерен» грифы белән саклана. Тагын 120 мең сугышчының, шул исәптән әсирлеккә эләккән 20 меңгә якын кешенең карточкаларын тикшерү сорала. Бу кәгазьләр Татарстан дәүләт архивы фондларында саклана, әмма анда әлегә эзләүчеләрнең эшче төркеме әгъзалары кертелми.

М.Черепанов фронтка китеп хәбәрсез югалган туганыңның һәлак булуын исбатлау өчен, барлык документларны җыеп, фронтка киткән кешенең сугышта һәлак булырга мөмкинлеген, аның исән түгеллеген, монда кайтып пенсия алмавын судьяга дәлилләү кирәклеген әйтте. Аңлашыла ки, бу – бик сәер гамәл.

Хәбәрсез югалганнар мәсьәләсе 1952 елда ук Германиядә дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителгән. «Әгәр фронтка киткән кеше, әсирлеккә эләгеп, аннан исән чыкмаган икән, бу аның һәлак булуын белдерә. Ни өчен безгә бу мантыйкны кулланырга ярамый?» – диде ассоциация рәисе. М.Черепанов һәр гаиләдә һич югы үзләре эшләгән «Нет в России семьи такой» дигән брошюралар формасында булса да сугышта катнашкан әтисе, бабасы турында мәгълүмат сакланырга тиеш, дип исәпли. Аның авторлыгында нәшер ителгән китапта һәлак булучыларның исемлеге тупланган.

«Татарлар, тыйнак халык буларак, ата-бабаларының данлы эше турында сөйләргә оялган, аларның батырлыгын, булдыклылыгын мактау, горурлану кабул ителмәгән. Яшерен документларны үз күзләрем белән күргәч, аны йозакта тотуның мәгънәсе юк икәнлегенә төшендем. Безнең күп каһарманнарыбыз – бабаларыбызның исемнәре яшеренгән, онытылган», – дип искәртте М.Черепанов.

2000 елда Төрекмәнстанда «фронтка киткән кеше хыянәтче булмаса, аның һәлак булуын танырга» дигән фәрман имзаланган иде. М.Шәймиев Татарстан Президенты булган вакытта Министрлар Кабинеты «Хәрби дан клубы» үтенече белән шундый ук карарны кабул итте. «Моны гадел карар дип саныйм. Кызганыч, хәзер дә «хәбәрсез югалды» дигән сүзләр Хәтер китабына кертелә», – диде ассоциациясе рәисе.

М.Черепанов сугышта һәлак булган бабаларны исән яки хәбәрсез югалган дип санаудан туктыйк дип, туган якны өйрәнүче, тарихчы, юристларга мөрәҗәгать итте. «Филолог буларак аңлатам: хәбәрсез югалгансың икән, димәк, син начар кеше. Ватанны саклаучыларга мондый тамга кую, моның белән горурлану дөрес түгел», – дип саный ул.

«Хәтер» мәчете имам-хатыйбы, Бөек Ватан сугышы ветераны, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Харис Салихҗанов «Чутай бабай малайлары» дигән китабында Вятка губернасы Малмыж өязе – Балтач төбәге халыкларының нигезләнү тарихын, авылда яшәгән шәхесләрне бәян иткән.

Чутай авылында бик күп галимнәр туып-үскән. Алар арасында өч фән докторы, дистәдән артык фән кандидаты бар. Харис ага физика-математика фәннәре докторы, парамагнит өлкәсендә зур белгеч булган Нургаяз Гарифьянов турында аеруча горурланып сөйләде. Хәзер Казанның бер урамы аның исемен йөртә.

Х.Салихҗановка Бөек Ватан сугышы башланганда 14 яшь булган. Фашист Германиясенең Советлар иленә басып керүе турындагы хәбәрдән халык тынсыз кала. Яу кырына китәсе егетләрнең исәбе – бихисап. Беренче көннәрдә үк сугышка кузгалырга җиде кешегә чакыру килгән, аларны хөрмәтләп озату өчен авыл клубына җыелалар.

«Алар клуб сәхнәсендә ярым түгәрәк булып утырган иде. Залның ишеге ачылды, байраклар болгап, быргылар уйнатып пионерлар, октябрятлар килеп керде һәм һәр бала, сәхнәгә менеп, үзенең абыйсы, бабасы, әтисе янына басты. Алар, әти-абыйларына «Фашистларны җиңеп кайтыгыз», – диде. Залның арткы рәтендә авылның хөрмәтле кешесе Нурзадә хәзрәт утыра. Ул Г.Тукайны, Г.Барудиларны белгән, Муса Бигиев белән аралашкан кеше була, үзе авылда мулла гына түгел, табиб та, ветеринар да. Зал аягүрә басып аңа ихтирамын күрсәтә. Чутайдан барлыгы 226 кеше сугышка китә, 107се фронт юлларында ятып кала. Болар хакында да китапта тәфсилләп язылган», – дип искә алды Харис хәзрәт.

Лаеш районыннан туган якны өйрәнүче Фәргать Әхмәтшин «Без – Кубрат хан оныклары» дигән хезмәт язган. Ул, пенсиягә чыккач, эшне үз нәсел тарихын өйрәнүдән башлаган. Казанда сакланган документлар буенча әтисе һәм әнисе ягыннан нәселенең шактый буынын ачыклаган. «Кызганыч ки, Мишә елгасы тамагына урнашкан туган җирем – Лаеш районындагы Япанча авылы (Мишә Тамагы), 1955-1957 елларда Куйбышев сусаклагычын корганда су астында калган», – диде ул. Бу авылның исемен Казан ханлыгының гаскәр башлыгы Япанча бигә бәйләп аңлаталар. Галим М.Әхмәтҗанов анда Япанча бинең утары, биләмәсе булуы, Лаеш ягында ханлыкның атлы гаскәре тотылуы турында яза. Япанчада 1519 елны җирләнгән кешенең кабер ташы да сакланган. Бу авылда гомер-гомергә почта булуы, Сөембикәне, Япанча кичүе аша чыгып, Казанга алып килүләре дә, авыл яныннан каторжаннар юлы узуы да халык хәтерендә теркәлгән. Әмма төбәкче архивларда утырса да, Япанча би турында әллә ни мәгълүмат таба алмый. Аңа бәйле урыннар Лаеш, Әтнә һәм Кайбыч районнарында да бар. «Монда бер үк шәхес турында сүз барамы, анда да ханлыкның атлы гаскәрләре тотылганмы, әллә Япанча би ыруына бәйле кешеләр яшәгәнме – шуны ачыклыйсы иде», – диде Ф.Әхмәтшин. Ул мәгълүматлар Россия дәүләт борынгы актлар архивында булырга мөмкин дип фаразлый. «Япанча авылын гына түгел, аның янәшәсендәге Ханкирмән, Ташкирмән, Табай (Атабай) авыллары, Калатау (ул кирмән вазифасын үтәгән) тарихын да өйрәнергә кирәк», – ди төбәк тарихын өйрәнүче.

Ф.Әхмәтшин, Бөек Җиңү көнен каршылаганга инде сигез дистә ел вакыт үтсә дә, сугышта катнашкан авылдашларының исемлеге төгәл булмавына да борчыла. Рәсми документлар буенча Япанча авылына бары 9 кеше генә сугыштан кайткан дип исәпләнә. Исемлек буталып беткән. Исәннәр һәлак булганнар арасына кертелгән яки киресенчә. Төбәкче 94 яшьлек Хәдичә апа белән эзләнеп, исән кайтучыларның 72 кеше икәнен ачыклаган. Бүген су астында калган Байчуга, Чулпан, Агайбаш авыллары буенча хәлләр тагын да аянычрак. Ф. Әхмәтшин Табайда (Атабай) Япанча бәккә истәлек тактасы куярга, шушы ук җирлектә Байчуга, Чулпан, Агайбаш, Мишә Тамагы, Табай авылларын кертеп Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемлеген төзү, һәм аларга стела куярга, Россия Герое Марат Әхмәтшинга Табайда музей оештырырга тәкъдим итте.

Түгәрәк өстәл утырышы барышында шулай ук «Татарстан төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» җитәкчесе, тарихчы-археолог Альберт Борһанов туплаган «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии» дигән җыентык, Лениногорск районыннан төбәкне өйрәнүче Наил Сәйдәшевнең үз нәселе һәм авылдашлары турында хезмәте, язучы һәм тарихчы Марсель Гариповның Азнакай районыннан Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм каһарманнар турында язган китабы тәкъдим ителде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Иҗат – язмыш ул

Айрат Суфиянов Чаллы каласында яши. 1985 елдан алып 2018 елга кадәр КамАЗның двигательләр заводында эшләде, хәзер Чаллының «Мәйдан» журналында проза буенча мөхәррир. 2006 елда ул әдәбият сөючеләрне «Кылычлы җил» китабын чыгарып шаккатырды. 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2020 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган альманахта 95 шигыре дөнья күрде.

– Айрат, әдәбиятка ничек килдегез сез?

– Мин 1958 елда Башкортстанның Балтач районындагы Усман авылында туып-үстем. Әткәем Тәлгать гомер буе Ленин исемендәге колхозда агроном булып эшләде. Әнкәем Тәнзилә дә колхоздан аерылмады. Ял иткәннәрен хәтерләмим. Икесе дә хезмәт ветераннары булып лаеклы ялга чыкты. Әткәй – сугыш ветераны, өздереп гармунда уйнаганы һаман күз алдымда. Мәрхүм абыем Фәрдәт иң югары камиллеккә күтәреп, йөрәкләргә үткәрерлек итеп Җәлилнең «Вәхшәт», Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»н укыганда зал басып кул чапкан, күпчелек халык елаган иде. Абыйның уңышы белән якташыбыз, сәнгатьле сөйләү остасы Айрат ага Арсланов котлавы да күз алдымда тора.

Томанлы вә куркыныч төш кебек кенә хәтеремдә: абый мине дулаган ат астыннан читкә тартып алды да, үзе чыгарга өлгермичә ат арбасы астында калды. Ике урыннан аягы сынып, тугыз ай шифаханәдә ятты... Бу вакытта миңа 4 яшьләр тирәсе, абыйга 9 яшь тә тулмаган. Шуңа да карамыйча, ул атларны, бигрәк тә колыннарны нык ярата иде... Әткәй дә, газиз әнкәй дә, абыем да, биш яшь ярымда суга баткан энекәшем дә ахирәттә...

Сөекле Тукаебыз язганча, авылыбызның һәр ягында шаулап торган, җиләк-җимешкә, чикләвеккә, гөмбәгә, төрле-төрле дару үләннәренә бай катнаш урман. Наратлары күккә тиеп тора. Каеннары актан да ак.

Без үскәндә шул ук ай иде,
Тойгыларга күңел бай иде.
Кешни-кешни офык ягына
Томырылып чапкан тай иде.

Туган авылымның татар халкының кабатланмас каһарманы, тарихта Батырша исеме белән билгеле Габдулла Галиев туган Югары Карышка якын булуы белән горурланам.

Аллаһка шөкер, төп нигезебез таралмады: анда йортыбызның имин бөтенлеген саклап энем Илдар яши. Балачак табигать кочагында үтте. Кыйгазы елгасындагы язгы ташу вакытында боз «иярләп» йөзгән чаклар, текә ярлардан суга чумган куркусыз мизгелләр офык артларында калды... Балачактан ук әдәбиятка тартылсам һәм 12 яшьтән уйларымны шигырь калыбына салырга тырышсам да, иҗатка урау, сикәлтәле юллар аша, бик озак килергә туры килде. Юк, экияттәге кебек ай үсәсен көн үсмәдем... Әмма заводта тимер-томыр, май, тузан, төтен арасында ара-тирә югалып калгаласам да, күңелемдә шигърияткә мәхәббәт сүрелмәде. Һич арттыру түгел: завод эчендәге шау-шу арасында да каеннар шавын, сандугачлар, тургайлар сайравын, чишмәләр челтерәвен, торналарның, кыр казларының, сыерчыкларның туган якларына кайткандагы авазларын ишетә, мәтрүшкәләрнең исен тоеп, җилдә ничек тирбәлгәннәренә кадәр күреп әсәрләнә идем. Миңа зур дәрәҗәләргә ирешеп, йомшак бәрхет келәмнәргә генә басып йөрү бәхете елмаймады... Ләкин үкенмим. Гомер буе гади халык белән бергә, алар язмышын үз күзгем – иҗатымда да чагылдырып яшәргә омтылдым... Билгеле, авыз тутырып, тумыштан бирелгән иҗади, рухи мөмкинлекләр тулысынча кулланды, дия алмыйм. Адәм баласы нинди мохиттә дә хыял-өметләрен чиста килеш саклап, халкына, кешелек дөньясына сүз әйтергә тели. Шагыйрьлек, Сүз – Аллаһы Тәгаләдән иңгән иман, язмыш, могҗизадыр. Бохарада озак еллар укып кайткан, 11 телне белгән, авылыбызның указлы мулласы булган зурәткәем Суфиян да шигырьләр яза, зурәнкәем, үзе хәзрәт кызы Кәшифә дә дини, дөньяви, хәтта фәнни гыйлемгә ия зат иде.

– Сез социаль челтәрләрдә дә иҗатыгыз белән таныштырасыз. Анда шигъриятегезне ничек бәяләлиләр?

– Өч ел инде шигырьләремне социаль челтәрләргә дә урнаштырып барам. Аларда заманга, милләт, тел язмышына кагылган кичерешләрем, уй-фикерләрем дөнья күрде: җәмгысы сигез йөзләп шигырь. Арада кыскалары, озыннары да бар. Робагыйлар да куйдым. Сәбәбе гади. Иҗат итү – минем рухи ихтыяҗым. Ул яшәешемә су, һава, туфрак кебек үк зарур. Әлбәттә, халкыбыз укысын, уянсын, берләшсен өчен дә. Чөнки әйтәләр бит: «Каләм изгегә тартыр...» Мин дә үз иҗатымда хаклык, дөреслек, гаделлек, изгелек эзлим. Күп кенә шигырьләремдә Аллаһы Тәгалә исеме кабатлана. Табигать, туган як, тормыш, без яшәгән чор, кешенең җан халәте, киләчәк турында борчылулы кичерешләр, ирек, хокук, мәхәббәт киңлегендә илһамлануга да зур урын бирелгән. Һәркемгә йогынты ясаган сәяси вәзгыятьне дә читләп узганым юк. Кешелек дөньясын коткарачак матурлыкка, иминлеккә сабыйларча беркатлылык белән инанып язам... Укучыларым арасында шигырьләремә анализ ясаучылар күп булу, иҗатыма бирелгән уңай бәя күңелне сөендерә.

– Кайберәүләр сезнең иҗатка күбрәк пессимизм, күңел төшенкелеге хас, ди.

– Шигырьне төрле кеше төрле күзлектән кабул итә. Мин йөз процентлы хакыйкатькә дәгъва итми язам. Минем караш башкаларныкы белән тәңгәл дә килмәскә мөмкин. Ләкин рухи халәтем матурлыкка, мәрхәмәткә күз йомган, кояшка артын борган битарафлык та түгел. «Нәфрәттән дә мин мәхәббәт эзлим»... Хәер, бөтен иҗатымны тәфсилләп өйрәнсәләр, анда минем җанның һәрбер хәрәкәте чагылдырылган. Бу катлаулы, болгавыр заманда кешеләргә дөреслек кирәк. Ялтыравык, шалтыравык ялганга табынып йотылу – фаҗига. Күңелне кузгаткан тәэсирләр күп. Хаксызлык, ялагайлык, комсызлык, хокуксызлык, шәфкатьсезлек, имансызлык, ерткычлык. Болар – инсаният дөньясына тискәре йогынты ясаган шайтани көчнең төп билгеләре. Дөньяның караңгы ягын гына күрү дә дөрес түгел. Кара төннән соң да таң ата. Тормыш тулаем каршылыктан корылган... Без шул барлыкта яшәргә, сыналырга хөкем ителгәнбез.

– Сезнең сүзләргә язылган җырлар да бар.

– Әйе, махсус җыр текстлары язмасам да, 30га якын шигыремне көйгә салдылар. Бу өлкәдә аеруча милләтпәрвәр җырчы-композитор Флүрә Талипова активлыгы белән аерылып тора. Ул «Әйтмә миңа», «Әгәр язмыш», «Хәтер», «Йөрәкләргә шакыйм», «Усман авылы»на көй язды. Равил Галиев «Кыр казлары»н, яшь җырчы Азалия «Очам, очам»ны башкара. Башкортстан җырчысы Гүзәл Әхмәтова «Әнкәемә», «Төнге абага», «Мәхәббәт күпере»н халыкка ирештерде. «Кайттым туган ягыма» Илнар Сәйфиев, Салават Фәтхетдинов репертуарында да бар. Көен Наил Мортазин язды. Якташым, талантлы җырчы-композитор Алсу Шакирова (Шакирә) күп кенә шигырьләремә көй язып, үзе үк халкыбызга да җиткерде.

– Сез ни өчендер китап чыгаруны суздыгыз. Сәбәбе бармы?

– Китап чыгаруны сузуымның сәбәбен үземнең артык акрын кыймылдаудан, үз-үземне оештырып бетерә алмаудан һәм... ялкаулыгымнан күрәм. Беренче «Кылычлы җил» дип исемләнгән китабым кульязмасын Чаллы язучылар берлеге рәисе Фәкил Сафин нәшриятка илтеп тапшырды. 2003 елда «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә китапка керәчәк шигырьләрнең кайберләрен укыган идем. Ул вакытта талантлы шагыйрьләр Рәшит Бәшәр, Фирүзә Җамалетдинова иҗатыма югары бәя бирде. Китабым дөнья күргәч, Айдар ага Хәлимнең «Шәһри Чаллы» газетасында «Ак биләүләр моңы» дигән мәкаләсе басылу зур сөенеч булды.

– Кайсы шагыйрь рухи дөньягызга якын, кадерлерәк?

– «Үз күлмәгең үз тәнеңә якын» дигән әйтем бар бит, Чаллы шагыйрьләре арасыннан Кадыйр Сибгатуллин, Айдар Хәлим, Данис Хәйруллин, Рәшит Бәшәр, Фәкил Сафин, Габделнур Сәлим, Зөләйха Минһаҗева, Әлфия Ситдыйкова, Сирень Якупова, Лилия Фәттахова, Лилия Гыйбадуллина алдында баш иям. Өммәтебезнең сакчысы-яклаучысы Фәүзия апа Бәйрәмова аерым хөрмәткә лаек. Әлбәттә, башкалабыз Казанда да шигърият казаны кайнап тора... Үрнәк алырлык шагыйрьләр әле дә бар, булган һәм... булачак!

– Быел яңа китабыгыз нәшрият планына кергән, диләр. Нинди исем бирдегез? Көтәсезме?

– Әлбәттә, көтәм. Ачымы, татлымы, төчеме иҗат җимешемне өммәттәшләрем дә татырга тиеш. Үзгәреш булмаса, китапның мөхәррире – Газинур Морат. Китапның исемен ике вариантта: йә – «Өмет догасы», йә – «Өченче сулыш». Кайсын кулай күрерләр. Яңа китабымны чыгаруны нәшрият алдында Фәкил Сафин да, Газинур Морат, Вахит Имамов, бүгенге рәисебез Ркаил Зәйдулла да йөз суын түгеп йөрде, аларга рәхмәтлемен.

Р. МӘХМҮТОВА.

● Роберт Миңнуллин белән.

● 60 яшьлек юбилейга багышланган шигърият кичәсендә шагыйрьне язучы Фәкил Сафин котлый.

Айрат СУФИЯНОВ

Бәндә кайсы гасырда да Тәүбәсезлек әсире...

КАЙТЫГЫЗ, АККОШЛАРЫМ!

Чыңлап акты кар сулары,
Еракта ак кышлары.
Күлләр сезне җирсеп көтә –
Кайтыгыз, аккошларым!

Күк йөзендә кояш көлә
Сибәләп балкышларын.
Тугрылыкның үзе булып,
Кайтыгыз, аккошларым!

Баса алмыйм, йөрәгемдә
Юксыну алкышларын.
Гүзәл каеннар иләнә
Кайтыгыз, аккошларым!

Ерак офыклар артына
Төбәлгән язмыш зарым.
Зинһар өчен, соңламагыз –
Кайтыгыз, аккошларым!

Куркасызмы корбан булып
Яшәүдән туган якта?..
Канлы куллар бәйсезлекне
Шашынып буган якта.

Көтәсезме яхшылыкның
Яманлыкны җиңгәнен?
Иркен сулышка юл ачып
Арткарак чигенгәнен.

Юнәлтеп аклык катына
Вакытның агышларын,
Ничәнче ел көтәм инде –
Кайтыгыз, аккошларым...
Кайтыгыз, аккошларым!

САГЫНДЫРДЫ

...Кара диңгез төпсезлеген айкап,
Дулкыннары белән чайкап-чайкап,
Энҗе-мәрҗәннәрен чагылдырды...
Ялым тәмам... арып юлга чыктым.

Күзләремнең сары дымын сыктым.
Туган якның юл тузаны кунган,
(Язмышымның игезәге булган)
Кочагыма сыенырга туган
Әреме дә шундый сагындырды...

КЫЙБЛА ЯККА АКТЫМ

Чишмә булып бәреп чыккан идем
Бәгыреннән туган җиремнең.
Кыйбла якка актым…
Буйсынмадым
Әмеренә заман җиленең…

Чыңлый-чыңлый кыйбла якка актым, –
Кояр өчен тиңсез диңгезгә…
И кешеләр, тамчым кайтавазын
Ишеттерсәм әгәр мин сезгә,

Сөенермен, дулкын сулышыннан
Тотармын да хөрлек нотасын.
Түбәнлектә түгел, биеклектә
Гомеремнең соңгы ноктасын

Куяр ният белән фанилыкта
Ничә гасыр икән яшәдем?..
…Бакыйлыкта балкып бөреләнә
Чыкка чумган иҗат чәчәгем!..

ЯЗ КИЛӘ

Көлә-көлә ягымлы яз килә,
Кыр казлары кайта тезелеп.
Авазлары, гүя бербөтенлек
Бишегеннән төшә өзелеп.

Бу мизгелдә беркем сукранмыйдыр,
Сыкранмыйдыр кебек изелеп.
Каеннарны яшел җилләр коча,
Яшәү дәрте арта сизелеп.

Җирдә – җәннәт! Җирне котлый-котлый
Яшел яшен уйный күкләрдә.

Без уяндык, зинһар, саклагыз, дип,
Яшь үләннәр башын күтәрә.

Тын алышым куанычлы, иркен.
Тәэссоратларым да саф, садә.
Әйтерсең, мин – яз илчесе булып
Табигатьтә туган ханзадә.

Кар сулары аккан тау башына
Офыкларның тигән күкрәге.
Бисмилламны әйтеп, җирдә ауныйм, –
Тәүге тапкыр күкләр күкрәде...

Сандугачлар сайрый... «Әллүки»не
Көйләп, чыңлый тимерчыбыклар.
Безнең җыр ул – ватанпәрвәр җыр, дип,
Аңлау көтә бездән чыпчыклар...

Аңлау көтеп, әй, җырлыйлар алар.
Көн күзеннән чыга яшь бәреп.
Бер шигырем язда калсын иде
Яшәргә... миннән соң яшәреп...

САГЫНЫРМЫН

Аланнардан хуш-ис аңкый.
Күзләреңдә кояш балкый.
Шул куаныч шәүләсен дә
Сагынырмын гомер бакый.

Тыным белән ак чәчәкнең
Таҗларына исемеңне
Язган саен назлап торыр,
Саф мәхәббәт хисе мине.

Мәхәббәт ул – талант кебек.
Ия аңа азлар гына.
…Хәтер-каурый хатлар яза
Яшьлегемнең язларына.

БЕР ТАМЧЫ НУР

Байлык катыннан эзләмим
Бәхетем киләчәген.
...Мин юләрме? Тезләнгәнмен
Кочаклап кыр чәчәген.

Рәхмәт хисе таҗларыннан
Чыккан шикелле саркып.
Елмаеп карыйм күкләргә
Таңгы кояштай балкып.

Бик биектә, башым – күктә
Җан сафланган, үзгәргән.
Тереклеккә бер тамчы нур
Йога минем күзләрдән.

Шул халәтне тасвирларлык
Илаһи сүзләр табып,
Дөньяда яшәү ниятем
Үземне ачып, танып.

Кыска мизгел – яшәвемдә
Рухи уяндым янып.
...Күз күрмәгән терәгемә
Үссен кемдер таянып...

ЯЗ

Йөрәктә – яз! Күзләрдә – яз!
Аңда да – яз! Канда да – яз!
Кояш балкып чигү чигә,
Көн чалт аяз, көн чалт аяз!

Күккә ашкан биек таулар.
Итәкләре – яшел бәрхет.
Кошлар сайрый, таллар шаулый,
Һәр тарафта яшел бәхет.

Кыр казлары очкан якка
Күз карашым төбәлгәндә,
Рәхәтләнәм, шул төркемдә
Үзем очып тирбәлгәндәй.

Язгы җилләр кочак-кочак
Өләшкәндә бөтнек исен,
Бөтен ажунга тарала
Дулкын-дулкын сөю хисем.

Шикләнмим: язын туганга
Алгысынам язлар җитсә.
Күбәләкнең канат җиле
Керфекләргә тиеп китсә.

Язда гына илһамыма
Яшәү өргән – аһәңдәшлек.
Әйтерсең лә китмәс өчен
Мәңгелеккә кайта яшьлек.

…Йөрәктә – яз! Күзләрдә – яз!
Аңда да – яз! Канда да – яз!
Сабый бала елмаюын
Хәтерләткән, көн чалт аяз!
Көн чалт аяз!

ЯЗЛАР ҖИТСӘ

…Әллә, вакыт борыла да, күчерәме соң артка?
Яшәреп китәм язларда, күңелем күтәрелеп!
Дөньяга балкып караган күзләрем чәчәк ата,
Көчем арта, тау-ташларны иңемдә күтәрерлек.

Төенләнә дә, бөреләр, яфрак ярып шаулыйлар.
Язлар җитсә, җилемләнеп, йомыла яраларым.
Яшел яшенгә уралып, әй, ләззәт уянулар!
Күк катында сайрый-сайрый талпына тургайларым.

Юкәләрдән йогып кала бал тәме иреннәргә.
Җир йөзенә килгәнгәме, язның илчесе булып!?
Карап ятам хуш-ис чәчкән зәп-зәңгәр сиреньнәргә
Илһамымның бишегеннән моң игенчесе булып.

« Газап татыган көннәрең, оныт син, – диеп, – оныт!»
Баш очымда күрәчәгем – елмайган ап-ак болыт!..
Шуңа ышанып яшәүдән куаныч табып, үсәм…
Иң мөһиме, җир йөзендә, мин һаман исән… исән!

ӘСИР

Яшәешнең асылында
Мәңгелек сугыш... һәм... кан.
Кылыч уйлап табылмаса, –
Золым чәчеп танылмаса,
Кирәкмәс иде калкан...

Һәр күзәнәк, һәр тере зат
Дошманыннан саклана.
Дөнья алдында көчленең
Фәлсәфәсе аклана...

Җиңгәннәр юк... Шатланганнар
Вакытлыча шатлана.
Егылачак тантананың
Айгырына атлана.

Өзелгәннәр тузан эчеп,
Изелеп кала аста.
Яулап күнеккән затлар да
Нәфес сазында – хаста.

Җанда кайный фанилыкның
Миһербансыз тәэсире.
Бәндә кайсы гасырда да
Тәүбәсезлек әсире.

Чордан чорга агу булып
Шулмы күчкән тәкъдире?..

Кайчан соң төшәр исенә
Әл-Мәликнең* исемнә
Юнәлтелгән тәгъбире?..

Юлыннан язган кешелек
Кайтырмы акылына,
Гомер бакый асылынса, –
Өч көнлек** дан кылына?

***Әл-Мәлик** – Хөкемдар. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бар. Әл-Мәлик шуларның берсе.

****Өч көнлек** – дөньяның да, кеше гомеренең дә фанилыгына ишарә.

ТЕЛ

Ирәеп, нәрсә әйтим?
Тел – ятим, мин дә – ятим.
Тел – өстә, мин дә – өстә.
Тормыш үзе җан күрергә
Теләгән якты төстә.
Тел – милләтне саклап торган
Калкан-кылычлы көч тә.
Канат куеп, югарыга
Күтәргән ак фәрештә...
Тел кагылса, – кагылам.
(Шагыйрь телдә чагыла.)
Тел киселсә, – киселәм.
Тел өзелсә, – өзеләм.
Тел изелсә, – изеләм.
Тел ачынса, –ачынам.
Тел ачыкса, – ачыгам.
Тел ачылса, – ачылам.
Тел тотлыкса, – тотлыгам.
Гүя аем тотылган...
Телнең жаны – Илаһи Сүз
Кем кимсетер кадерен?!
…Күпме байлык, әгәр тапсак
Мәрхүм сүзләр каберен…
Чәчәк куеп, дога укып,
Тезләнәсем килә бер.
Бәлки, алар терелер дә,
Минем арттан иярер...
Өстәп тагын ни әйтим?
Тел – хаким, мин дә – хаким!..

«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында тамаша залындагы олы абый-апалар балалардан да уздырып көлә, кул чаба икән, башкалабыз Казанда «Шомбай» халыкара курчак театрлары фестивале бара дигән сүз. Спектакль тәмамлангач, аларның сәхнәгә менеп, курчакларны, сәхнә бизәлешләрен игътибар белән өйрәнүләре «Шомбай» фестивалендә күбрәк күрергә, яңаны үзләштерергә омтылуларын күрсәтә. Курчак театры бинасы янындагы чәчәкләр паркында бала-чага һәм аларның әти-әниләре эстрада каршындагы урыннарны эләктереп калырга ашыга, отышлырак урыннар өчен хәтта сугышырга әзер икән, «Шомбай» фестивале бина эченә генә сыймыйча, урамга, паркка ташып чыккан һәм Казан халкын үзенә җәлеп иткән, димәк.

«ШОМБАЙ»

Атна дәвамында Казанда әнә шундый күңелле күренешләргә шаһит булдык. Быел IV фестиваль элеккеләренә караганда да колачлырак узды. «Әкият» театры фойесында аның тантаналы ачылышында кунакларны Татарстан мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова сәламләде. Курчак театрларына багышланган «Театр Чудес» журналының шеф-редакторы Нина Монова басмага презентация үткәрде. «Әкият»нең сәнгать җитәкчесе Илгиз Зәйниев «Алтын битлек» кебек абруйлы һәм башка театр премияләрендә курчак театрлары өчен номинацияләр бик аз булуы җәһәтеннән борчылуын белдерде. Нәниләр өчен иҗат иткән артист, режиссерларны, рәссам, композиторларны түбәнсетү түгелме бу, дип мөхтәрәм жюри һәм Мәскәү, Тольятти, Пермь, Түбән Тагил, Белгород, Ульяновск, Новосибирск, Саратов, Рязань, Белоруссиянең Гродно, үзебезнең Чаллыдан килгән театр коллективлары алдында бик мөһим мәсьәләне күтәрде. 91 ел тарихы булган атаклы С.Образцов исемендәге театрның Х.К.Андерсен әсәренә нигезләнеп куелган «Снеговик» спектакле белән ачылуы үзе үк фестивальнең җитдилеген, зур дәрәҗәсен, колачын күрсәтә. А.Нечаев 40 минут буе берүзе спектакль уйный, төрле тавышлар белән сөйләүче дә, декорацияләрне алмаштыручы да үзе. «Снеговик» «Алтын битлек» премиясе белән бүләкләнгән. Безнең фестивальдә исә А.Нечаев иң шәп актер төрендә бүләккә ия булды.

Фестивальдә күңелне тырнаган нәрсә – актерларның көннән-көн күбрәк алга чыгуы. Жюри рәисе театр белгече, тәнкыйтьче О.Глазунова да бу җәһәттән ризасызлыгын күп тапкыр белдерде. Курчак спектакле һаман саен драма театрлары тамашаларына охшый бара, диде. Бу хәл курчак йөртү культурасының югалуына китерә. Кечкенә, нәфис курчаклар белән ничек идарә итү кирәклеге онытыла. Фестивальдә дә бериш тамашаларда өрфиядәй нәзберек нәфис курчаклар янында артистларның зур йөзләрен күреп, кәеф китте. Артистларның сәхнәдә еш күренүеннән, пәрдә артында яшеренергә теләмәвеннән курчак театрының әкияти тылсымы югала кебек.

Республикабызның башкаласы Казанда узган бу зур чарада бәйгедә сынашырлык милли спектакльләребез булмавы да күңелгә шатлык өстәмәде. Дөрес, «Әкият»нең тамашалары, шул исәптән «Сертотмас үрдәк» тә кунакларга күрсәтелде. Әмма бәйгедән тыш уйналган бу спектакльләрне җитди игътибарга алдылармы икән? Чаллы курчак театрының спектакле дә татар әсәре нигезендә түгел, атаклы

● Түбән Тагил театрының «Хочу быть волком» спектакле.

● Чаллы театрының «Кроткая» спектакле.

классик Ф.Достоевскийның повесте буенча куелган. Фестиваль жюрие безнең кальлыларны мактап туя алмады. Юньле биналары да, әллә ни игътибар да юк, шуңа карамастан репертуарлары кызыклы булу өстенә, үзләре курчак театрлары фестивале һәм белем бирү форумы үткәрә, диделәр. Шуңа өстәп, Достоевский кебек катлаулы, җитди авторларның әсәрләренә алынудан да курыкмыйлар. Эшчеләр шәһәрендә бүгенге көндә кабатланмый торган кызыклы спектакльләр куелуы – үзе шаккатмалы хәл. «Кроткая» спектаклен режиссер Илгиз Зәйниев куйган. Бу – Илгизнең Чаллы курчак театрында өченче иҗат эше. Алдагы икесе кебек үк, «Кроткая» да үзенчәлекле килеп чыккан. Режиссер язучы әсәрләрендәге рухны һәм повестьта сурәтләнгән чорның хиссиятен дөрес тасвирлауга ирешкән. Бу тамашада ичмасам рәхәтләнеп курчаклар уенын карыйсың. Рәссам Денис Токарев бик лаеклы рәвештә дүртенче «Шомбай» фестиваленең бүләгенә лаек булды.

Фестивальдә тамашачы Саратов шәһәреннән «Теремок» театрының «Клочки по закоулочкам» исемле спектаклен дә бик яратып карагандыр, чөнки яз җиткәч, үз йорты эрегәнгә, бичара куянкайны җылы оясыннан куып чыгарган хәйләкәр төлке турындагы әкият барчасына билгеле булса да, Г.Остер аны яңа мәгънәләр белән баеткач, спектакль гаилә белән җыелышып карый торган кызыклы тамашага әйләнгән. Артистлар Д.Ковдя, Р.Сопко, А.Черепанов курчаклар белән дә заманча тамашалар куеп булуын дәлилләдә һәм фестивальдә иң шәп ансамбль төрендә бүләккә лаек булды.

Курчак театрларын түбәнсетүчеләр, аңа җитди игътибар бирмәүчеләр бик ялгыша, әлбәттә, чөнки бүген бу төр театрлар тема һәм жанр ягыннан бик алга китте. Нинди генә темалар күтәрелми анда! Түбән Тагил курчак театрының Швейцария язучысы Б.Вегенаст әсәре буенча куелган «Хочу быть волком» спектакле, мәсәлән, яңа, тапталмаган булуы белән кызыклы һәм тамашачы алдына мөһим сораулар куя. Үз табигатеңә каршы бару үз асылыңны югалтуга китерә, дигән фикерне үткәреп кенә калмый, җитдирәк нәрсәләр турында да уйланугa этәрә. Көчкә каршы көч белән чыгып, кайчак коточкыч вәхшигә әйләнергә мөмкин. Төп герой сарык бәрәне әнә шулай бүре булырга омтылып, үз туганын ашап куя икән, тамашачыга уйланырга нигез бу спектакль.

Рязань дәүләт өлкә курчак театры артистлары, язучы Ч.Айтматовка ияреп, «Пегий пес, бегущий краем моря» спектаклендә Себернең аз санлы халыклары тарихы темасын күтәргән, аларның мәдәниятен алга сөргән, адәм баласының табигать белән бәйләнешен калку итеп күрсәтергә омтылган икән, бу да уен-муен эш түгел. Курчаклар аз булса да, су стихиясе, томан, Себер халыкларында сакланган ыругларга ышану оста күрсәтелгән. Рязань театрына кадәр Ч.Айтматовның бу әсәре дөньяның бер курчак театрында да куелганы булмаган. Кыюлыгы һәм тылсымлы, серле, әллә чын, әллә уйдырма ыруглар дөньясын кызык тасвирлаганы өчен, Борис Константинов фестивалебезнең иң шәп режиссеры буларак бүләккә лаек дип табылды.

Тольятти театрының «Повесть временных лет» спектакле рус дәүләтенең тарихына тәнкыйть күзлегеннән карарга өйрәтә. Анда тасвирланган Олег кенәзне, княгиня Ольганы, Владимир кенәзне мисалга алсаң да, барысы да халыкны кырып, аннан көлеп яшәүче вәхшиләр итеп сурәтләнә. Рус тарихы ялган белән тулган, дигән фикер үткәрелә. Гади ха-

● Саратов театрының «Клочки по закоулочкам» спектакле.

● С.Образцов исемендәге дәүләт академия үзәк курчак театрының «Снеговик» спектакле.

САБАКЛАРЫ

● Саратов театрыннан бүләккә лаек булган Д.Ковдя, Р.Сопко, А.Черепанов.

● Ульяновск театрыннан «Золотая рыбка» спектакле иҗатчылары.

лык утын пүләне зурлыгындагы агач кисәкләре аша тасвирлана. Авторлар халыкның наданлыгына әнә шулай басым ясарга теләгән. Бер сәгать дәвамында утын пүләннәрен әле берсе, әле икенчесе кыра. Тамашаны курчак театры спектакле дип әйтергә тел әйләнми, биредә бер курчак та юк бит, аның каравы кансыз патшаларны фаш итү бу сәхнә әсәрен көчле итә. Режиссер А.Янушкевичның «Повесть временных лет» спектакле фестивальнең иң шәп тамашасы буларак бүләкләнүе махсус сайланган мәдәни күзәтүчеләрне аптырашта калдырды. Курчак театрында кансыз вәхшиләр турындагы тарихны карарга байтак тамашачының күңелләре карышкандыр. Мәдәни күзәтүчеләр исә төлке белән куянкай турындагы Саратов спектакленә үз бүләкләрен бирде. Бүген халыкны алдау, кан кою шулкадәр кешенең үзәгенә үткән, хәтта курчак театрлары да вәзгыятькә битараф кала алмый һәм «курчак югала» дип зарланган жюри да тамашачының күзен ача торган «Повесть временных лет» спектаклен алга сөрә...

Берәүләр курчак уйнаудан качса, икенчеләр, киресенчә, курчакка кайту юлларын эзли. «Шомбай» фестивалендә Мәскәүдән «Бродячий вертеп» театры шаккатырды. Театр нибары өч кешедән гыйбарәт. Дарья Пенская – грек теле белгече, Александр Греф һәм Елена Слонимская – химик-технологлар. Көннәрдән бер көнне алар, һөнәрләрен ташлап, Скоморохлар театрының тарихын өйрәнүгә керешә, дөньяның төрле китапханә, музей, архивларында җыелган мәгълүмат нигезендә фәнни реконструкцияләр ясап, тамашачыга күрсәтә. Театр моннан утыз ел элек барлыкка килсә һәм анда байтак кеше эшләп китсә дә, бүген «Вертеп»та өчәү генә калганнар. Үзләре борынгы музыка уен кораллары ясый, җырлый, балчыктан әвәли, костюм тегә. Химик-технологлар чәчәкләр паркында ике кич рәттән тамаша күрсәтеп кенә калмады, кызыклы лекция дә сөйләде. Беренче ширманы ничек реконструкцияләгәннәрен кызык итеп бәян иттеләр. Эзләнә торгач, болар алман галиме, сәяхәтче, дипломат Адам Олеарий сәяхәтнамәсенә тап була. Ул XVII гасырның 30 нчы елларында Мәскәүдән Персиягә барышлый бөтен күргәннәрен дәфтәргә теркәгән. Олеарий рус халкының надан, «варвар» икәнен, яратып аракы чөмергәннән соң, «собака» кебек һәм аннан да яманрак сүзләр белән бер-берсен тиргәп сугышуын, зина кылуын гына язмаган, ярминкәләрдә зиначыларның эшен фаш итеп курчак тамашалары куюын да теркәп куйган. Аның рәсеменнән күренгәнчә, XVII гасырда ширма итәктән ясалган. Ир-заты өстендәге озын итәкне башын капларлык итеп югары күтәрә һәм төшмәсен өчен биленә таяк белән беркетә. Шуннан соң ике кулы белән ширма-итәк өстендә курчак уйната. Әмма Олеарий язмаларыннан башка бер җирдә дә итәк-ширма турында бернинди мәгълүмат теркәлмәгән. Аның каравы Иранның Тәһранында, Үзбәкстан, Төркмәнстанда итәк-ширма турында мәгълүматларны байтак очраталар. Шуннан чыгып бу ширма шәрык илләрендә барлыкка килгән дигән нәтиҗәгә киләләр. Урамда курчакларны уйнатканда тавыш үзгәрткеч «пищик» кулланалар. Шуның аша сөйләгәндә, тавыш «чинап» чыга. «Пищик» шулай ук борынгы чорлардан бирле килә. Казан тамашачысы «Шомбай» фестивалендә химиклар реконструкцияләгән чын Петрушка театрын күрү бәхетенә ия булды.

Казан халкы хәйран калып сөйләрлек бу тамашаларны республикабызның Мәдәният министрлыгы белән берлектә «Әкият» Татар дәүләт курчак театры оештырды. Ирада Әюпова Мәдәният министрлыгының махсус бүләген Белоруссиянең Гродно шәһәреннән өлкә курчак театры М.Ю.Лермонтов әсәре буенча куйган «Демон» спектакле өчен биреп, классиканың мөһимлеген ассызыклады. Курчак театрында да классик калыпны, ягъни курчакны югалтмаска иде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.



● Виктор Антоновның «Цирк на нитях» театры тамашасы.

Мәдәни җомга
1 июль
№25, 2022

Хажи ӘХМӘТҖАНОВ

БЕРДӘНБЕРЕМ



Зәйнәп ханымның хәзер бөтен дөньясы – дүрт стена. Автоавариягә эләгеп, бик каты имгәнү сәбәпле коляскага береккәненә дә дүртенче ел китте. Көннәр-төннәр буена шушы тар бүлмәдә. Уйларның ниндие генә килми дә, кайларга гына алып китми. Нигә тормышында аңа гына бөтен нәрсә аркылы килеп торды соң әле? Ә бит гомер юлы яхшы гына башланган кебек иде...

Зур, тату гаиләдә үсте, урта мәктәпне иң алдынгылар арасында тәмамлады, шул ук елны институтка керде. Диплом алып чыккач, аны зур гына авыл мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп җибәрделәр. Тик ике ел гына рәхәтләнеп үз һөнәре буенча эшләп калды ул. Алтмышынчы еллар иде, бөтен милли мәктәпләрдә барлык фәннәрне дә рус телендә укытуга күчерделәр, туган телгә нибары 2-3 сәгать кенә торып калды. Атнасына. Ул күләм белән генә кая барасың? Балаларны туган телләреннән аеру сәясәтенең башлангычы иде бу. Шуңа җан әрнеде.

Соңлабрак булса да кияүгә чыкты. Ире авылда яшәргә теләмәде. Шәһәргә килеп урнаштылар. Монда һөнәре буенча эш таба алмады. Йә мәктәп-интернатта тәрбияче, йә китапханәче булып эшләргә туры килде. Кызына ике генә яшь иде – ире ташлап, икенче хатынга китте. Инде менә инвалидлык.

Шулай да аның җанын иң әрнеткәне, иң хафаландырганы – бердәнбер кызы белән уртак тел таба алмау, тәгәрләрге – кызының каты табигатьле, тискәре булып үсүе. Каян килгәндер аңа шундый бәгырьсезлек, тупаслык, югыйсә, үзенең нәселендә мондый каты күңелле кеше юк иде. Күрәсең, атасы ягына тарткандыр. Шулай тупас табигатьле иде шул ул.

Ана белән кыз арасында салкынлык, ызгыш күптән башланды. Өченчедәме укыганда, мәктәптән кайтты да әнисенә дәгъва белдерде:

– Нигә миңа Әминә дип исем куштың? Хәзер миңа «Аминь» дип дәшәләр. «Бетте» дигән сүз бит.

– И, кызым, – диде Зәйнәп. – Бик тә матур исем ич. Хәзер ул сирәк тә. Ә бит кая карама Альбина да Альмира. «Әминә» дип йомшак итеп әйтсеннәр.

Юк шул, килештерә алмады. Хәзер инде «Аля» дип кенә йөртәләр. Кызы үзе шуңа бик канәгать.

Бераз үсә төшкәч иде, тагын әнисенә яңа таләп:

– Нигә эти безнең белән тормый?

– Соң ни эшләтим, икенчене тапкач.

– Димәк, үзең гаепле, үзең тота белмәгәнсең.

Күпмедер вакыт үтүгә тагын җанга тия:

– Нигә без бер генә бүлмәле фатирда торабыз? Әнә башка кызларның үз бүлмәләре бар!..

– Монысына да шөкер итик, син бәләкәй чакта әнә күпме вакыт кеше почмакларында яшәргә мәҗбүр булдык...

Кызы үскән саен, таләпләре арта барды. Инде хәзер, нигә мине табиблеккә укытмадың, мин шәфкать туташы гына булып калдым, табибләр безгә әмер биреп кенә утыра, ә без көн буе йөгерәбез, ди. «Соң, кызым, үзең мединститутка имтихан биреп карадың, керә алмадың бит», – дигәнгә җавабы әзер: «Башкалар акча биреп укырга керә, ә син бирә алмадың», ди. Ялгыз анага андый зур акчаны каян алырга инде – монысын да аңларга теләми.

Кияүгә чыкканда тагын конфликт. «Кызым, нигә инде башка милләт егетенә чыгасың, үзебезнең мөселман кешесе юкмыни?!» – дигәнгә ачуы гына кабарды: «С ним мне жить. Что ты понимаешь в любви!» - дип кенә җибәрде. Килешергә туры килде, ни эшләмәк кирәк. Хәзер инде кызы әнисе белән бөтенләй татарча сөйләшмәс булды. Әнисе татарча эндәшсә, анысы - урысча җавап бирә. Янына килеп йөрүләре дә сирәгәйде.

Менә оныклары туды. Зәйнәп ханым зур куаныч белән каршылады аны. Тик исем кушканда тагын каршылыклар килеп чыкты. Анысы да аларча булды.

Үзе барып йөри алмагач, Зәйнәп оныгын сирәк күрә хәзер. Ул аны гел сагынып яши. Кызы улын ияртеп килсә, куанычыннан ни эшләргә белми. Тик менә тагын хафа: бер килүендә караса, ни күрә биш яшьлек баланың муенына тәре такканнар.

– Ни эшләвегез бу? Күземә күрсәтмәгез шуны, – дип әйтергә дә өлгермәде, кызы баласын җилтерәтеп алып чыгып та китте. «Я у них живу, у них свои законы, они мне создали условия жизни», – дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Шуннан бирле инде килгәннәре юк. Өзгәләнә ана җаны. Аяклары йөрмәгәне генә җитмәгән, күңеле дә яралы хәзер. Ирексездән күзләргә яшь тыгыла. Язмыш нигә шулай бер кешегә каныкса, кайгы-хәсрәтен өсти генә бирә икән...

«Ярый, түземле булыйк, – дип үз-үзен тынычландыра Зәйнәп. – Вакыт – иң яхшы табиб, диләр бит әле. Биш яшьлек сабый гаепле түгел. Менә үсә төшәр, дөньяны үзе аңлый башлар. Менә шунда нәнәсе белән дә аңлашыр. Өмет бар бит әле аңарда. «Нәнәй», дип эндәшә дә башлаган иде, «исәнмесез» дип килеп кергән иде. Зәйнәп шунысына да шөкер итә.

«Бердәнберем» дип үстергән иде кызын. Инде бердәнбер өмете оныгына күчә. Аклансын иде өметләре.

...Зәйнәп ханым өчен бүген дөнья белән аралашуның төп чарасы – радио. Менә хәзер генә аннан җыр яңгырады:

Заман авыр, димә әле,
Башыңны имә әле,
Авыр булса да матур ул
Бу дөнья дигәннәре...

Зәйнәп ханым, арбасын тәгәрәтеп, тәрәзә янына килде. Пәрдәләрен ачты. Әнә нинди матур итеп кояш чыгып килә. Яңа көн башлана. Бәлки, бүген аның бердәнбере килер...

Атнаның сәяси мизгелләре

Җитди очрашулар атналыгы

Атна «Зур җиделек»нең (G7) Бавариядә (Алманиянең көньягы) чираттагы очрашуга җыелуыннан башланып китте. G7 илләре (АКШ, Алмания, Бөекбритания, Италия, Канада, Франция һәм Япония) лидерлары 26-28 июнь көннәрендә анда чираттагы саммитларын үткәрде. Алмания канцлеры Олаф Шольц рәислегендә үткән ул чарада тышкы сәясәт һәм иминлек (шул исәптән Россиягә Украинадагы хәлләр буенча басым һәм санкцияләрне көчәйтү) мәсьәләләре, шулай ук климат үзгәрү, макроикътисади хәл, инфляциягә каршы көрәш һәм инвестицион хезмәттәшлеккә кагылышлы проблемалар да игътибар үзәгендә булган. АКШ президенты Джо Байден анда Мәскәүнең G7 төркеме һәм НАТОның бердәмлеген какшату теләге максатына ирешмәве турында белдергән. Очрашуда катнашучылар Украинада Россиянең җиңүенә юл куймаска һәм Киевкә, күпме кирәк – шул кадәр ярдәм күрсәтергә килешенгән. «Зур җиделек» шулай ук, Кытайның «Бер пояс, бер юл» проектына көндәш буларак, глобаль инфраструктура һәм инвестицияләр буенча үз партнерлыгын җәелдерергә карар кылган. 2027 елга кадәр анда җәлеп ителәчәк инвестицияләр күләме 600 миллиард долларга җитәргә тиеш. Очрашуда видеоэлемтә аша Украина лидеры В.Зеленский да чыгыш ясаган. Ул анда Киевнең конфликтны озакка сузарга җыенмавы, якын айларда Көнбатышның актив ярдәменә исәп тотуы турында белдергән.

Җитди очрашу Испаниядә дә үтте. НАТО илләре лидерлары, бу илнең альянска керүенә 40 ел тулуга багышлап, үзләренең 36 нчы саммитына Мадридта җыелды. Көн тәртибендәге төп мәсьәлә - альянсның 2030 елга кадәр исәп тотып төзелгән яңа стратегик концепциясен кабул итү. Әле очрашуга кадәр үк анда НАТО өчен төп куркыныч чыганагы дип – Россия, ә системалы янау чыганагы итеп Кытай күрсәтеләчәге мәгълүм булды. Яңа концепция Мәскәү белән бәйләнешләргә нокта куя һәм Европада НАТО көчләренең моңа кадәр күрелмәгәнчә җәелдерелүен (әйтик, тиз реакция ясау көчләрен бүгенге 40 меңнән 300 меңкешегә җиткерелүен) күздә тота. АКШ президенты бу җәһәттән, НАТО үз тарихында киң мөмкинлекләр ачу мизгелен кичерә, дип белдерде. Саммитта Төркиянең Финляндия һәм Швецияне альянска әгъза итеп алуга каршы булмавы да ачыкланды. Шулай итеп, Көнбатыш Россияне янә бер кат «Кытай кочагы»на этәрде, дияргә була һәм геосәясәи уеннарда моның үз исәбе бар. Украинада үткәрелә торган махсус операциянең дә кайбер нәтиҗәләре күренә. Мәгәр, бу атнада Россия президенты В.Путин да җитди очрашулар үткәрде. Ул Дүшәнбедә Таҗикстан лидеры белән зур әңгәмә корды, Ашхабадта (Төркмәнстан) исә «Каспий бишлеге» (Әзәрбайҗан, Иран, Казахстан, Россия һәм Төркмәнстан) саммитында катнашты һәм анда да ике яклы очрашулар узды.

Фоат УРАЗАЙ.

Мисбах мәчете

Бу мәчет 1552 елның 15 октябрендә Явыз Иван гаскәрләренә каршы Казан шәһәрен яклап шәһит булган мөселман кардәшләребез истәлегенә Мисбах Гыймалетдинов җитәкчелегендә төзелде. Мәчет диварына шушы хакта алтакта беркетелгән. Мәчетнең проектын архитектор М.Басыйров иҗат иткән.

Кешеләр, авырый башласа, гадәттә, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп: «Терелсәм, игелекле гамәл эшләр идем», – дип нәзер әйтә. Бөек Ватан сугышы ветераны Мисбах Гыймалетдиновның да, Яр Чаллыга күчеп килгәч, 73 яшендә күзләре начар күрә башлый. Катаракта зыяны. Шулчак олпат ветеран: «Күзләрем күрә башласа, дин юлында булыр идем, мәчет төзетер идем!» – дип, догалар кылып, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә. Ул чакларда Чабаксарда яңа гына ачылган сырхауханәдә ике күзенә дә операция ясата. Һәм 94 яшендә вафат булганчы... гомумән күзлексез укый, яза.

Мисбах Ибраһим улы 2020 елда бакыйлыкка күчкән. «Әтиебезнең озак яшәп, гел яңгыз шәбездә булуына күнегелгән иде, үлемен бик авыр кичердек, – ди аның төпчек кызы Әлфия ханым. – Тик бу нисбәттән берни дә үзгәртеп булмый шул. Коръәндәге «Әл Гыймран» сүрәсенең 145 нче аятендә дә: «Бер җан да Аллаһының рөхсәтеннән гайре үлмәс», диелгән бит».

Әлфия ханым әтисе хакындагы матбугат язмаларын күрсәтә, ә алар дистәләп... Мисбах Гыймалетдиновны аралашучан, тапкыр, һәркемне тыңлый белүче, яхшы киңәшләр бирүче дә үз итүче кеше буларак искә алалар. Ул үз тормышы хакында да хәйран сөйләгән... Бу язмалар күбесенчә Бөек Ватан сугышында күргән михнәтләр хакында, ә менә Яр Чаллыда мәчетләр төзелешендә актив катнаша башлагач, тарыган бар авырлыкларын әлеге язмалар аша бик ачыклап та булмас... Ул аның күңелен тырнап торган хатирәләр. Андый тискәре хатирәләре белән ул бүлешеп тә тормаган. Яңа бер мәчет төзергә керешкәндә (сүз башка мәчет хакында әле), кешеләр арасында үзара низаглар килеп чыга. Ветеран шуннан соң кулын селтәп, низагчылар белән әңгәмәсен өзә. Аның белән аралашырга теләмәүче бәндәләр дә күбәя. «Игелекле эшкә әтием хакында начар фикерләр дә ишетергә туры килде. Имеш, бу мәчетне нигә төзегән?! Әйе, әтием 2000 елда Кол Шәриф мәчете күчермәсенә охшатып кечкенә генә мәчет төзи башлады, – ди Әлфия Мисбах кызы. – Дөрестән дә, әүвәл ул зур мәчет төзүдә катнашырга уйлаган иде, әмма күпләрнең каршы торуы аркасында шушы проект сызылды. Әтием каланың ветераннар советында мәш килде. Утырышларының берсендә яңа мәчет белән мәдрәсә төзергә карар кылганнар икән. Чиновниклар янына үзе барды, җир участогын да, иганәчеләр эзләү белән дә үзе шөгыльләнде. Нәтиҗәдә, җир дә табылды, төзү материаллары да... Әмма мәчет төзелеше мәсьәләсе буенча низаглар килеп чыккач, әти бу башлангычтан ерагайды. Үзенә башка булышчылар, фикердәшләр тапты. Берничә предприятие җитәкчесе дә аңа ярдәм күрсәтте. Күп кешеләр булышты аңа. Әтием озак еллар умартачылык белән шөгыльләнде. Бал сатып җыйган акчасына башта хаҗ кылырга барам, дия иде. Аннары шул бар булган акчасын әлеге мәчет төзелешенә сарыф итте. Мәчет 2003 елның 15 октябрендә ачылды. Халык аны ошатып кабул итте!

Әти-әнием Норлат районының Зирекле авылындагы йортларын мөселман гаиләсенә сатып, Чаллыга күченеп килгән иде. Менә хәзер шул йортта гомер итүче Әминә ханым белән аның ире Ирек ифтар мәҗлесендә әтиэнием, абыем рухына багышлап дога кылдырды. Туган йортның мөселман гаиләсенә күчеп, догалы нигез булып калуы – яхшыга икән ул».

Мисбах Гыймалетдинов 1926 елда Зиреклeдә туган. 1941 елда ул комбайнчы ярдәмчесе булып, уңыш җыюда катнашкан, бераздан үсмерне комбайнчы итеп үк куйганнар. Аннары механизатор булып та эшләгән. 1944 елда, 18 яше тулу белән, аны да армиягә алганнар. Солдатларны мари урманындагы Суслонгер гарнизонына, коточкыч авыр шартлардагы укыту частенә җибәргәннәр. «Анда күргән михнәтләрне сөйләп бетерерлек түгел. Өстәге кием теткәләнеп, тишелеп бетте, ә аяк киемнәребезнең табаннарын кадаклар һәм чыбыклар белән беркеттек, – дип искә алган Мисбах абый ул айларны. – Барысы да бу шартларга түзә алмады, салкынлык, юешлек, начар ашату сәбәпле, ир-атлар кырылды. Күбесе яшь иде. Без землянкаларда яшәдек, әмма аларга су чыга иде, аякларыбыз суда итты, шул су өстенә агач ботаклары гына салынган иде... Дүрт айдан соң, ниһаять, фронтка җибәрелүебезне сөенеп кабул иттек, чөнки беренче тимер юл станциясендә үк безгә кайнар ботка бирделәр, яңа өс-баш өләштеләр. Мине исә разведкага билгеләделәр. Фронт линияләрен бихисап мәртәбә уздык, әмма бер заданиене үтәгәндә, бүлегебез сирәгәйде. Минем дә аягым яраланды. Разведка өчен яраклы булмагач, танкист булачаксың, диделәр. Безнең экипаж 3 нче Белоруссия фронтының 5 нче гвардия танк армиясе составында иде. Берлинга кадәр җиттек. Одер елгасын да кичтек. 1945 елның апрелендә без дә штурмга ашкынучылар арасында идек. Берлинда ул көннәрдә җимерелмәгән бер бина да калмагандыр... Рейхстагка беренче булып байрак кадаучы милләттәшләребезне шунда белдек. Рейхстаг өстенә байрак беркетергә омтылган биш йөзгә якын сугышчы һәлак булды. Инде сугыш бетте дигәндә генә, күпме гомерләр өзелде...

Үзем 1945 елның 28 апрелендә бәлагә тарыдым. Безнең танкка снаряд тиде, ут капты, яна башладык. Контузия алдым һәм яраланып, госпитальгә элэктем. Җиңү көнен дә шунда каршыладым».

«Әтием үз батырлыклары өчен I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденына, III дәрәҗә Дан орденына, «Батырлык өчен» медаленә, маршал Г.К.Жуков исеменнән килгән рәхмәт хатларына да лаек булган. Ул сугыштан соң бер ел узгач кына, туган якка әйләнеп кайта алган, чөнки аңа җитди дәваланырга туры килгән, – ди Әлфия ханым. – Ул Кара-Күлнең бер чибәре саналган әниебез Миңсара белән гаилә корган. Алар бәхетле яшәде. Гаиләдә без өч бала үстек: апам Зөлфия, абыем Нурислам һәм мин.

Әтием башта машина йөртүче булып эшләгән, аннары экстерн рәвештә укып, мәктәптә белем бирә башлаган. 42 яше тулгач, Казан педагогика институтына кереп, география укытучысы дипломын алды ул, Зирекле урта мәктәбендә гомер буе география укытты. Мин дә башта Арча педагогика училищесын, аннары Казан пединститутын тәмамладым. Шулай ук география фәненнән белем бирдем. Чөнки әтием миндә шушы фәнгә кызыксыну уятты. Мин генә түгел, башка укучылар да аның дәресләрен көтеп ала иде.

Әнием Миңсара колхозда хезмәт куйды, һәрчак дин юлында булды. Намазлар да кылды, корбан да чалдырды. Советлар чорында дин кануннары басылган китапларны таратканы өчен, аны хөкемгә дә тарттылар. Ә әтиемне, сугыш кичкән кешене, корбан чалган өчен партия билетын алып, эшеннән азат итәргә үк теләделәр. Әти-әни көчле рухлы иде, авырлыкларны лаеклы үттеләр. Безнең күңелгә дә иман орлыгы чәчтеләр.

Менә хәзер аларның юлын дәвам итеп, шушы «Мисбах» мәчетен карап торам. Ул көн дә ачык. Аның тирә-юне – гөлчәчәк бакчасыдай. 39 нчы мәхәллә территориаль үзидарә рәисе Мәдинә Мөхәммәтҗанова мәчет янындагы мәйданда төрле чаралар да уздыра. Мәдинә ханым әтием исән чакта да аның белән төрле бәйрәмнәр оештыра килде. Чаллының Касыймов бульварында урнашкан әлеге кечкенә мәчет алдында быел да Җиңү бәйрәме уңаеннан мәдәни чара узды.

Шушы кечкенә мәчетне дин үзәгенә әйләндереп, анда намазлар укылсын, дин һәм татар теле дәресләре алып барылсын өчен, ул бөтен көчен салды. Дөрес, ул планетадагы иң кечкенә мәчет! Шул сәбәпле Гиннесс рекордлар китабына да кертелде. Аның эчке мәйданы – 10 кв.м. Мәчет эченә барлыгы 10 кеше сыя».

Шунысын да әйтик: Мисбах Ибраһим улы – алты яшеннән үк әнисез калган ярым ятим. Аның әтисе дүрт улын һәм бер кызын берүзе үстергән. Бөек Ватан сугышына киткән типсә тимер өзәрлек ир-атлар, абыйлары 45 яшьлек Исмәгыйль, 42 яшьлек Миңневәли, 39 яшьлек Касыйм афәт утына кереп, бер-бер артлы юкка чыккан. Олы абыйсы – Ленинград блокадасында, уртанчысы – фин җирендә, ә Касыйм абыйсы Сталинград өчен барган сугышта.

Мисбах абыйның әтисе Ибраһим Гыймалетдин улы да заманында танылган мулла булган. Ветеран үз архивында кулдан язылган бер кульязманы да кадерләп саклаган. Ә ул кульязманы Мисбах абыйның дәү әтисе Ходайбирде язып калдырган икән. Кульязманың таушалган битләрендә милли тарихыбыз – Алтын Урда чоры, Казан ханлыгы хакындагы бәян. Дәү әтисе Ходайбирденең язмышы шул: бервакыт авыл мәчете баскычына... чүпрәккә төрелгән ир баланы калдырып киткәннәр. Авыл бае (ахрысы, аның уллары булмаган) шушы кечкенә малайны үзенә уллыкка алган да, аңа әлеге исемне кушкан. Ир бала бик матур, акыллы, тырыш булып үскән, бай да улына яхшы белем бирергә теләп, аны Төркиядә үк укыткан... Шушы нәсел дәвамчысы Мисбах Ибраһим улына ихлас максатны гамәлгә ашырып, Җир йөзендә иң кечкенә, әмма чын мәчет төзергә насыйп булган.

Тик сугыш ветераны үзе исән чакта, үзенең бар изге гамәлләрен башкаларга әйтмәгән дә. Югыйсә, Мисбах Ибраһим улы Норлат районына Кара-Күл авылы мәчетенең проектын ясатып кайтарган, ярдәм йөзеннән шушы мәчеткә ун мең сум акча да юллаган, ул тапшырган 50 мең сум акча Кара-Күл авылында күпер төзегән кешеләргә хезмәт хакы итеп түләнгән. Соңрак халык аны шушы авылның почетлы гражданы итеп тә сайлаган. Норлат районының Бикүле авылында мәчет төзелешенә 25 мең сум, Иске авылы мәчетенә 20 мең сум тапшырган. Башкортстанның Ишембай мәчете төзелешенә 50 мең сум юллаган, Апас районының Танай-Тура авылы мәчете өчен дә 50 мең сум сәдака биргән һ.б... Туган авылы Зиреклегә дә күп тапкырлар матди ярдәм күрсәткән.

«Әтиебез төзелеп кенә килүче мәчетләргә акчасын кызганмады, – дип җөпли хөрмәтле Әлфия ханым. – Барысына канәгать булып гомер итте ул. «Кем Аллаһ ризалыгы өчен мәчет төзетсә, Аллаһ ул бәндәсенә җәннәттә йорт төзер», диелгән. Шулай була күрсен!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһиров үз йорты белән Казан үзәгендә яши. Алмагачлар шау чәчәктә утырган чак. Легендар җырчы бүген дә формасын югалтмый, тавышы элеккечә күркәм. Хуҗа 70 яшен тутырган димәссең!

ЭШЛӘП ҮСКӘН

Искәндәр Биктаһиров яшьлегеннән аерылмыйча яши кебек. Чөнки туган ягы – Чирмешән районының Чыгтай авылы белән араны һич өзми. Туган нигездә хәзер бертуган энесенең гаиләсе яши.

– Әти-әни 12 бала таба! Дүртесе бер яшькә җиткәнче үк вафат була. Сигезебез исән-сау үстек. Нәселдә җырчылар күп. Абыйлар баянда уйнады. Сәнгатькә һәвәслеге зур булгач, әти дә гармунда уйный иде. Әтинең төсе булып калган гармунда уйнаганнарым әле дә истә. Кечкенә чагымда аның яныннан китмәдем. «Арча көйләре»н сузып җибәрүе була, тизрәк әти янына йөгерәм. Чирмешән ягында аш бүлмәсен «почмак» дип йөртәләр. Әни шунда нидер эшли, үзе җырлый. Салих Сәйдәшевнең «Өмә көе»н көйләгән икән. Соңыннан, сәнгатькә килгәч кенә, нинди җырлар башкаруын аңладым. Авылда барысын да белеп бетермисең бит. Әнинең моңлы тавышына соклана идем. Гөлсем Сөләйманованың тавышы аны хәтерләтә. Әти-әнинең кайчан ашаганнарын да күргән булмады. Сигез балага ничек ризык әзерләп, ничек киендереп бетергәннәрдер? Үз-үзебезне аклау өчен чират буенча көтү көтәргә йөрдек. Урманга гөмбәгә дә! Кычыткан җыеп, аны киптереп тапшыра идек. Әз-мәз булса да акча! Аңа китап-дәфтәр ала идек. Әнием 96 яшен тутырып китте. Үз акылында иде. Урын өстендә авырып та ятмады. Әни ничек барысына да өлгерә иде икән?! Апаларым сөйләве буенча, ул һәр сайгак, һәр почмакны чиста итеп тоткан. Без күп булгач, әни ипине дә тау-тау өеп сала иде. Чүпрәсе дә әйбәт булгандыр, анысын да үзе ясый бит! Шикәр чөгендерен гектар-гектар итеп эшкәртергә бирәләр иде. Көз көне тапшыргач, шикәр белән дә, акчалата да биргәннәре истә. Эштә чыныгып үскән гади авыл балалары инде без, – дип үскән елларын искә ала И.Биктаһиров.

КАЗАНГА ТАРТЫЛУ

Гап-гади авыл егетенең халык артисты дәрәҗәсенә ирешүе дә зур тырышлык билгеседер. Үҗәтлек тә ярдәм иткәндер. Казанга килү тарихы да бормалы. Авылдан туры Казанга түгел, ә юллар аны Лениногорск шәһәренә китерә. Анда бертуган апасы Җәмилә яши. Искәндәр слесарь булып эшкә урнаша. Шәһәрдә теркәлеп, армия сафларына китә. Элек авылдан чыгып китәргә авыр булганга, шәһәргә китеп теркәлә торган булалар. Карелиянең Петрозаводск шәһәрендә хезмәт итеп кайтада, Лениногорскидагы авиация заводына эшкә урнаша. Нефть һәм газ сәнәгате институтының кичке механика бүлегендә укый.

– Заводта эшләгәндә җырлый башладым, – дип дәвам итә И.Биктаһиров. – Үзешчән коллективта шөгыльләндем. Авыллардагы сәхнәләргә чыктык. Берсендә Казаннан заводка эш сәфәре белән килгән җитәкче: «Искәндәр, сиңа Казанга җыр һәм бию ансамбленә барып карарга кирәк», – диде. 3 курсны тәмамлаганнан соң, Казанга киттем бит! Мәскәүгә китеп уку мөмкинлеге дә бар иде, әмма барыбер Казан үзенә тартты. Татарстан башкаласына сәнгатькә якынаермын дигән уйлар белән килдем. Әгәр дә җырчы булмасам, барыбер сәнгать өлкәсен сайлар идем. Казанга химия-технология институтына документларымны тапшырдым. Читтән торып уку бүлегенә укырга кердем. Казанга килгән

АВЫЛ БАЛАСЫ

елны җыр-бию ансамбленә бик күп яшьләрне кабул иттеләр. Йөзләгән кеше җыелган. Бөтен егетләрне тезеп бастырдылар. Алмаска да тырышканнар иде. Чөнки эшләгән заводта бик күп хезмәт хакын ташлап килгәнмен. «Шуның кадәр хезмәт хакын калдырып, монда 60 сумга киләсеңме?» – диделәр. Укуымны дәвам итәчәкмен дигәч, алдылар. Нәтиҗәдә, бергә кергәннәр арасыннан мин беренче халык артисты булдым. Мактанмыйм, бу – бары тырышлык нәтиҗәсе.

БАЛАЛАРЫҢ ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ ЙӨРСӘ...

Уңышка ирешкән һәр ир-ат артында зирәк, акыллы хатын-кыз торганын беләбез. Факия ханымның да роле зур була. Заманында ул шәфкать туташы булып эшли. Ире белән бергәләп Сәйдәш, Ихтыяр исемле ике ул үстерә. Бүгенге көндә Факия ханым лаеклы ялда, оныклар үстерешергә ярдәм итә.

– Факия сәнгать кешеләре белән аралаша, бөтен татар артистларын белә иде. Шуннан сөйләшеп киттек. Безнең өйдә һәрвакытта да милли рух хөкем сөрде. Факия татар ашлары пешереп каршы алды, балаларны үстерде. Хәтта мин аны 10 ел эшләтмәдем, шулай теләдем. Чөнки артист буларак та танылган идем, бик күп кеше белә. Ә шулвакытта балаларың әйле-шәйле йөри башласа, нәрсә була?! Тәртипле үссеннәр, дигән уй белән хатынны өйдә утырттым. Элек бит без айлар буе гастрольләрдә йөрдек. Хәзер инде олы улыбыз Сәйдәшнең үз гаиләсе бар. Г.Камал театры артисткасы Гөлчәчәк Гайфетдинова белән 8 яшьлек Саҗидә, 6 яшьлек Җәннәт исемле оныкларыбызны үстерәләр. Кече улыбыз Ихтыяр әле өйләнмәгән. Балет биючесе булырга укыды. Мәскәүгә дә җибәрдек. Әмма бисе килми башлады. Хәзер башка юнәлештә эшли. Сәйдәш заманында төрек лицеен тәмамлады. Төрек телен бик яхшы белә. Тәрҗемәче булып эшли. Төрек футболчысы Карадениз белән дә хезмәт куйды, хәзер башка төрек белән эшли. Дөресен әйтим: ике улымның да сәнгать юлыннан китүен теләдем. Югыйсә, Сәйдәш тә Казан мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлаган иде. Элегрәк аппаратура куеп, бик җайлы гына минем белән гастрольләрдә йөрделәр. Үз теләкләре белән сәхнәгә чыгып, җырладылар, биеделәр дә. Бүген инде сәхнәгә тартылу юк. Мин аңа да риза. Хәзерге эшләре үзләренә ошый икән, без, ата-ана, риза булып яшибез. Иң мөһиме – үзләре, балалары сау-сәламәт булсын гына дибез.

ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ...

И.Биктаһиров үзе белән бәйле истәлекләр белән дә бүлешә.

– Кайсы ел икәнен төгәл хәтерләмим. «Татарстан яшьләре»нең баш мөхәррире Харис Әшрәфҗанов иде. Редакциягә бер төркем кешеләр килеп керде. Мин дә шунда. Затлы гына киемле, өлкән яшьтәге бер кеше турында «Ул Муса Җәлил белән бергә төрмәдә булган», - диделәр. Алексей Иконников! Бөтен әйберне дә сөйләп бетерми, разведчик булган, ахры. Муса Җәлил аның үзен белгәнме? Әмма ул аның Муса Җәлил икәнен белгән. Соңрак Муса Җәлил йортына Әминә Җәлилова оныклары белән килгәч тә, шунда сөйләп, җырлап уздым да, каршымдагы Рафаэль Мостафин: «Син күрдеңмени, беләсеңмени аны?!» – дип минем сүзләрне раслап куйды. Ул бит күп нәрсә белә. Муса Җәлилгә бөтен төрмә караучылары хөрмәт белән караган, ди. Бүлмәсен чиста тоткан. Аны әллә кайларга алып китеп, матур тормыш күрсәтеп, Берлин буйлап йөрткәннәр. Рестораннарда татар бәлешләре пешереп ашаталар иде, ди. Менә шулай Җәлил белән аралашкан Алексей Иконников белән аралашырга туры килде, – дип сөйләде халык артисты.

Икенче истәлек биюче Рудольф Нуриевнең әнисе белән бәйле. Заманында И.Биктаһиров җырчы Римма Ибраһимова белән эшли башлагач, Баулыларга кадәр йөреп, Башкортстанның Яркәй районына гастрольләргә чыгып китәләр. Мәдәният сараенда концерт биргәннән соң, берничә хатын рәхмәт әйтергә дип, артистлар янына җыелыша.

– Көн кояшлы иде, –дип исенә төшерә җырчы. – Берничә ханым арасында аллы-гөлле зур яулык бәйләгән бер апа басып тора. «Бу хатынның улы – бик танылган биюче, чит илгә качкан», – дип әйтеп куйды берсе. Ул вакытта сүзнең мәгънәсен аңламадым да. Гастрольдән кайткач кына, качакның Рудольф Нуриев икәнен әйттеләр. Элек илен ташлап качкан, дигән сүз бар иде. Әнисе әллә Яркәйгә кайткан булган. Чыгышы буенча Казан татары, монда үскән, диләр. Ире Хәмит абзый Башкортстаннан.

СТАЛИННЫ БЕЛГӘН МӘМЛӘКӘТ

Нигериядә, Сенегал, Төркия, Урта Азия республикаларында, АКШта, Италиядә җырлап, андагы милләттәшләребезгә татар моңын тараткан Искәндәр Биктаһировның антиквар әйберләр яратуын күпләр белмидер дә. 2013 елда салып кергән өендә затлы әйберләргә урын мул бирелгән. Дивар сәгате, көзге, өстәл, картиналар кебек өй җиһазларын ул антиквар кибетләрдән сатып алган. Көзгенең пыяласы бераз кырылу сәбәпле, аны яңага алмаштырган. Кешедән калган начар энергетика дигән нәрсәгә ышанмый. Шуңа да андый әйберләрне курыкмыйча өенә алып кайта.

– Таҗикстан якларында мамык җыю буенча иң алдынгыларыдан булган, кыска гына буйлы Мәмләкәт Нахангова дигән бер апа бар иде. Язучы Мәхмүт Хөсәен белән Артекта очрашканнар. Мәмләкәт апаны Казанга чакырып алганнар. Аның белән аралаштым. Аңа багышлап җыр яздырганнар, имеш. Сүзләрен Мәхмүт Хөсәен язган. Мәмләкәт апаны Казанга ни өчен чакырганнарын белмим. Шуннан без дә Таҗикстанга гастрольгә бардык. Ул апаның телефонын алган идек, өендә кунак булырга туры килде. Кара агачтан сырлап эшләнелгән өй җиһазы, диварда борынгы картиналар эленеп тора. Арада нәни Мәмләкәтне Иосиф Сталинның алдына утыртып сурәтләгән картина бар! Заманында Мәмләкәт апаны Сталин шәхсән үзе кабул иткән булган. Сугышка кадәр үк булган хәл, күрәсең, – дип бәян итте миңа әңгәмәдәш.

БАРЫСЫНА ДА ШОУ-БИЗНЕС КИРӘК!

Җырчыны борчуга салган нәрсәләр дә бар. Хәзерге вакытта үзең теләгән җырларны барлык концертларда җырлап булмавына шакката. «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»ләрне музейга гына барып җырлый диярлек. Г.Тукайның гаять зур әсәрләрен үз концертларында да җырларга ниятли. Шулай ук Сара Садыйкованың кайбер әсәрләрен тамашачыга ишеттермичә җаны түзми.

– Хәзер кешеләргә озын көйләр кирәк түгел бит, күңел ача торган җырлар гына тыңлыйлар! Барысына да шоу-бизнес кирәк! Озын җыр белән сузма әле дип, концерт оештыручы режиссёрлары да әйтеп тора! Барысына да дәртле җыр кирәк. Әлбәттә, андый җырларым да бик күп. Тамашачы белән милли җырлар аша аралашырга кирәк. Халык көйләрен тупламыйча булмый! Бүгенге көндә дә берничә халык җыры таптым, алар чиратта тора. Аннары элеккеге җырларны заманлаштырып җырлауга да уңай карыйм. Милли тембрың, сөйләмең белән күтәреп чыга ала аласың икән, димәк, булдырасың! Татар эстрадасында шоу эшләр алдыннан, милләт дигән төшенчәне онытмасыннар иде. Беренче чиратта, милләтне кайгыртырга кирәк. Безнең бурычыбыз – татар милләтен саклау! Җиңел җыр белән генә давыл кузгатып булмый. Җырның мәгънәсе – безгә иң мөһиме!

Әңгәмәбез ахырыида җырчының бүгенге чыгышлары белән дә кызыксындым.

– Сезне концертлар белән бөтен җирдә дә көтәләрдер инде?

– Көтә, ди, орып бирәләр! Хәтта сабантуйларга да эләгеп булмый. Үзең тыкшына башласаң, сезне яхшы беләбез, җавап бирербез дип әйтәләр дә, ахырда бер кырыйда торып каласың. Район сабан туйларына да эләккәнем юк.

– Чирмешән Сабан туена дамы?

– Чирмешәннәргә мин бөтенләй кирәк түгел! Өч ел элек катнашкан идем, анда да үзем сорап! Валлаһи, аптыраш. Югыйсә, Президент мине зурлап машина да бирде, юбилейлар оештырырга да ярдәм итә. Заманында Шәймиев тә зур фатирлар биреп калдырды. Аларга мең шөкер! Ә Чирмешән районында шундый тенденция элек-электән килә, сәнгать кешеләренә хөрмәт бөтенләй юк. Юбилей белән котлап, хәтта районның мәдәният бүлегеннән сыңар телеграмма да сукмадылар! Калган хәлне үзегез чамалагыз.

Эльза ГАЗИЗОВА.

Җырчының шәхси архивыннан алынган фотолар һәм автор фотолары файдаланды.

Язучылар корылтаеннан өч-дүрт көн узды, ләкин анда булган кайнар чыгышлардан, ызгыш-талашлардан әле һаман да башым чатнап тора сыман. Бик шау-шулы узды ул. Аның нәкъ менә мине иҗат оешмасына рәис итеп сайлавы, анда күтәрелгән катлаулы мәсьәләләрне юлга салырга тиешлегем күңелемнең бимазалануын тагын да арттыра. Мондый да зур ышанычны аклый алырмынмы-юкмы? Шушы атна да тулмас кыска гына арада миңа язучылар белән дә, алда көткән мәсьәләләрне хәл итәрдәй башка затлар белән дә аралашырга туры килде. Хәтта президентыбыз Минтимер агай Шәймиев белән дә очрашу насыйп булды.

Мөфтинең тәрбия дәресе

Сайлануыма бер ай булгач, 1999 елның 27 августында мин мөфти хәзрәт Исхакыйдан дәгъвәтнамә (чакыру) алдым. Манара башына ярымай куелган рәсемле кәгазьгә зәвык белән язылган, элек бик укырга туры килмәгән өслүбтәге әлеге чакыруны кат-кат укыдым. Мөфти хәзрәтләре, бер вакыт табып, үзләренең хозурына рәхим итүемне үтенгән иде.

Әлеге хатны укыгач, ике төрле каршылыклы уй барлыкка килде. Беренчесе – күңелемдә рәхмәтлелек тойгылары уяну. Җөмһүриятебезнең иң югары дәрәҗәдәге дин әһеленнән шундый өндәмә алу көн саен була торган хәл түгел. Госман хәзрәтне аз булса да беләм. Аның төрле уңай белән булган чыгышларын, вәгазьләрен ишеткәнем бар. Ыспай итеп түгәрәк сакал йөртүче бу кеше бик ягымлы итеп, мантыйк белән, сүзен ибе-җебенә туры китереп, тәмләп сөйли. Еш кына сүз арасында Коръән аятьләре белән дәлилләп баруы да аңа карата олылау хисләре уята. Мондый затлы шәхес чакыргач, бармый ярамас. Әле тагын шунысы да бар, бу чакыру шәхси дәгъвәт кенә булмаска тиеш, мине каләм ияләре оешмасының җитәкчесе буларак күрергә телидер. Димәк, анда бару-бармау синең шәхси ихтыярыңда гына түгел.

Тәүге сүзем итеп: «Ике төрле уй туды», – дидем бит әле. Ә күңелдә каршылык барлыкка килүенең сәбәбен үзем генә беләм. Инде хәзер, ул көннәргә 25 еллап вакыт узгач, әйтергә дә ярыйдыр... Ә теге вакыйга болай булды. Шул ук 1999 елның 27 июлендә миңа иртүк Мәдәният министрлыгыннан шалтыраттылар.

– Бүген Казанда Диния нәзарәте бинасы ачыла. Сезне дә шул тантанага чакырабыз. Президент сәгать унда килә, сез, әлбәттә инде, аны каршы алганда ук була күрегез.

Сәгатькә карап алдым, ун туларга 23 минут. Язучылар йорты белән Диния нәзарәте бинасы бер-береннән ерак түгел. Ун тулыр-тулмаста мин барып та җиттем. Министрыбыз Илдус Тарханов инде анда иде, ул дустанә рәвештә хәл-әхвәл сорашкач, миңа Президент янындагы кешеләрдән бик аерылып йөрмәскә кирәклеген дә искә төшерергә тиеш тапты. Чөнки мин андый югары даирә затлары белән бергә йөреп өйрәнгән кеше түгел, гадәттә читтәрәк булуны мәгъкуль күрәм. Бу юлы инде җитәкчебезгә якынрак булып йөрергә кирәк икән.

Минтимер агай да мине күреп алды. Башта ым белән исәнләште, мин якынрак килгәч, кул биреп тә күреште. Урамдагы халык алдында тантаналы чыгышлар ясалып, ишел тасма да киселгәч, мин дә җитәкчеләр һәм шәхесләрдән калмыйча, бинага кердем. Халык әлегә тышта калды. Башта беренче каттагы бүлмәләрне карап чыктык. Аннан соң, Президент белән мөфти артыннан, икенче катка күтәрелдек. Аларга ияреп йөрүчеләр шактый күп, кайбер бүлмәләргә сыеп та бетмиләр. Мин, тар җирләрне тарайтып йөрмим әле дип, алардан арткарак калдым. Ул арада миңа төбәп Вафа хәзрәтнең якынлашуын күреп алдым.

– Әссәламегаләйкем, хәзрәт!

– Вәгаләйкем әссәлам вә рәхмәтуллаһу вә бәрәкәтүһү.

Без Вафа хәзрәт белән таныш лар идек. Мин аны иң әүвәл Мәрҗани мәчетенең имамы Габделхәбир хәзрәт янында очраттым. Ә Габделхәбир хәзрәт белән бергә ун ел элек, 1989 елның 14 декабрендә, Екатеринбургта һиҗри ел исәбе белән ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү мәрасимнәрендә катнашу насыйп булган иде. Шунда якыннан аралашу җае чыкты. «Уралмаш» заводының мәдәният сараенда төп чаралар узды. Екатеринбургның үзәк мәчетендә дә булдык. Анда үзебезнең Арпаяз авылы кешесе Госман Мостафа улын очратуым да хәтердә калган. Шуннан кайткач, йомыш төшеп, Мәрҗани мәчетенә Габделхәбир абзый янына кергән идем, шушы Вафа хәзрәт белән дә очраштык. Бу абруйлы дин әһелебез – Татарстанның баш казые да. Шуңа күрә Казанда да, районнарда да мәгълүм зат. Ул төрле дини мәрасимнәрнең үзәгендә була. Бер елны Аксубай районының Иске Кыязлы авылында мәчет ачуда катнашкан идек. Ул да Вафа хәзрәттән башка узмады. Әлеге бина ачылышына да килгән икән.

Без Вафа хазрәт белән шатланып күрештек. Хәл-әхвәл белешкәч, әлеге бинаны күрүдән алган тәэсирләр турында сөйләшә башладык. Шул вакыт, кемдер, яныбызга килеп, Вафа хәзрәтне икенче бүлмәгә чакырып алды. Зур зал уртасында ялгыз калдым һәм башкалар кереп киткән якка юнәлдем. Шул вакыт яныма миннән дә гәүдәлерәк, мускуллары кулмәк җиңнәренә көчкә сыйган бер тупасрак йөзле адәм якынлашты. Шактый нык тавыш белән әйтте:

– Сез кем? Бирегә ничек кердегез? Сез беренче булып керергә тиешле кешеләр исемлегендә юк.

– Гафу итегез, миңа Мәдәният министрлыгыннан бирегә килергә куштылар.

– Без берни дә белмибез, сез исемлектә юк!

– Ярый, юк икән, мин китә дә алам.

– Әйе, китсәгез, дөрес булыр.

Башымны горур тотып, аскы катка төшә торган баскычка юнәлдем. Теге сөрхәнтәй арттан ияреге телгән иде дә, тавышымның көчен эшкә җигеп, кискен генә әйттем:

– Ияреп килмәгез, мин юлны беләм!

Ул шулай да, мин бинадан чыгып киткәнче, артымнан карап торды кебек. Һәрхәлдә аркамдагы «күзләрем» шулай сизә иде.

Ишек төбендә керү нәүбәтен көтеп торучы кешеләр, бу нигә чыгып бара инде дип, сәерсенеп тә калгандыр. Миңа уртадан юл бирделәр.

Каршыма институтыбызның педагогика кафедрасында эшләүче доцент Мәхмүт Әхмәтҗанов очрады. Ул нәкъ шундый сорау бирде:

– Нигә бик тиз чыгып киләсез, ачылу тантанасы бетте дәмени?

– Юк, әле дәвам итә, бик ашыгыч эшем килеп чыкты.

– Язучыларның шул булыр инде. Ярый, бинаның эченә керепкарамыйча китү юк. Мин ишеге ачылганчы көтеп торам әле.

...Шуннан соң, бу бинага кабат килү түгел, ул якка борылып та карамыйча йөри идем, менә шундый чакыру алдым. Алда әйткәнемчә, бу хәл уйланырга мәҗбүр итте. Акылым барырга кирәк дисә, хисләрем аңа каршы килә. Шулай да салкын акыл белән уйлагач, бару ягы җиңде. Чөнки бу аңлашылмаучылыкта мөфти хәзрәтләренең катнашы юктыр. Аннан түбәнрәкләр, ул-бу килеп чыкмасын дип, шулай эшләргә булгандыр. Аларның пединститут профессорын, әдәби тәнкыйтьчене белмәүләрен, танымауларына гаҗәпләнергә кирәкме икән?

... Бинага килеп керүгә, ишек төбендә утыручы абзый ачык йөз белән каршы алды:

– Сезне телевизордан күргәнем бар. Әйдәгез, узыгыз, мөфти хәзрәт киләсегезне әйтеп куйды. Ул көтеп тора. Менә, килгәнегезне әйтим әле.

Абзый телефонга үрелде. Мин исә таныш баскыч буйлап икенче катка күтәрелдем. Йомшак кәнәфидән урын күрсәттеләр, мөфтидә кеше булуын әйттеләр. Залны карап чыктым. Теге көннән соң монда шактый үзгәрешләр барлыкка килгән. Диварларда төрле каллиграфияләр белән язылган Коръән аятьләрен зиннәтле рамнарга куеп элгәннәр. Идәнгә яшел келәмнәр җәелгән. Мин утырган кәнәфи янына тәбәнәк кенә өстәл куелган. Анда дини китаплар тезелеп тора. Шуларның берсен кулыма алам. Шул вакыт уң яктагы ишектән чалма-чапан кигән Госман хәзрәт күренде. Ул ачык чырай белән:

– Фоат әфәнде, рәхим итүегезгә рәхмәт, – дип килеп күреште.

– Мөфти хәзрәтебез үзе чакыргач, ничек рәхим итмисең? Илтифатыгызга рәхмәт.

Без, бик җылы итеп, ике куллап күрештек. Ул залның бер читендәге өстәл янына алып китте. Бер хатын-кыз өстәлгә ябылган япманы алып куйды. Анда табын әзерләп куелган икән. Без, чәй эчә-эчә, сөйләшеп киттек.

– Менә Диния нәзарәтендә дә, Язучылар берлегендә дә яңа җитәкчеләр пәйда булды. Дөресен әйткәндә, безнең алда торган бурычлар бер – ул да булса рухи кыйммәтләребезне саклау, үстерү. Шуңа безгә үзара хезмәттәшлекне ныгытырга кирәк. Бергәләп эш итә торган юнәлешләрне табу һәм хәрәкәт итү лазем. Каләм әһелләре дә динебезнең асыл нигезләрен халкыбызга җиткерүдә файдалы эшләр башкара ала...

Әңгәмәбез шул тирәлектә барды. Үзара хезмәттәшлекнең байтак юлларын искә төшердек, аларны алып баруның ысулларын барладык. Үзем аның белән сөйләшәм, үзем эчемнән генә мөфти хәзрәт теге көндә килеп чыккан кытыршылыкны искә алырмы дип уйлап утырам. Әмма андый сүз килеп чыкмады. Иң ахырдан, әмин тоткач, ул биредә эшләүчеләрне чакырды. Араларында теге олы гәүдәле егет тә бар иде. Мин аның йөзенә карадым. Ул күзләрен идәнгә текәде. Алар белән дә аяк өсте генә сөйләшеп алдык.

Госман хәзрәт йомгаклап әйтеп куйды:

– Бу абыегызны да белеп калыгыз. Ул бүгенге көндә җөмһүриятнең язучылар оешмасы җитәкчесе. Хезмәттәшлегебез алга таба еш һәм максатчан булыр дип ышанабыз.

Мин шунда гына Госман хәзрәтнең әдәпле итеп бергә эшләүчеләренә тәрбия дәресе бирүен аңладым. Ул, әлбәттә, соңрак булса да теге җайсыз хәлне белгән, гафу үтенүне менә шушылай итеп оештырган иде. Һәрхәлдә мин шулай уйладым.

Әйе, дини оешмалар җитәкчеләре дә үз эшләрендә педагогика һәм психология фәннәре өйрәтүләрен шушылай нечкәләп белеп эш итә икән. Әлбәттә, әлеге фәннәр дини өйрәтүләр белән дә каршылыкка керми, киресенчә, бу өлкәдәге казанышларыбызны баета гына. Аларны бергә үреп алып бару гына әйләнә-тирәдәгеләр белән дөрес мөнәсәбәтләр урнаштырырга ярдәм итә. Кешеләр белән эш иткәндә, башкача булуы мөмкин дә түгел.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.
12 июнь 2022 ел.

Гаяз ИСХАКЫЙ:

Зәки Вәлиди кемдер?

(Дәвамы. Башы 22-24 нче саннарда).

«Туран» җәмгыятендә һәр атна бер тапкыр ачык лекция укыла вә бөтен төрек бәйрәмнәрендә бөтен кабиләләрнең яшьләрен туплаган чәй мәҗлесләре ясала һәм төрле кабиләнең яшьләре арасында дуслык өчен мәйдан хәзерли иде. 23, 24, 25 нче елларда Берлинның төрек [җәмгыяте] каршында «Туран» мәҗлесләре иң җанлы вә иң яраткан докладлар укылды. Һәм чыгышларга килгән төрекләрнең саны көннән-көн арта килеп, җәмгыять даими бер прогресска туры килеп, һәм үзенә журнал чыгару фикерен барлыкка китерүгә якынлашкан иде. Нигездә, Совет Россиясеннән совет паспорты белән килгән төркестанлылар бу чыгышларда күп файда күрде. Мөһаҗирләрнең бу төрекчелек хәрәкәтләре Берлиндагы большевик илчелегенең хуҗасына һич тә хуш килмәде вә моңа контр буларак большевик илчелеге башкорт коммунисты Галимҗан Идрисинең (Әлимҗан (Галимҗан) Ибраһим улы Идриси (1887–1959), журналист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. 1915 елдан Германиядә яши. Ул 1922–1924 елларда Бохара Халык Совет Җөмһүриятенең Германиядәге вәкиле вазифасын башкара) идарәсендә бастион большевик Сурих та (Яков Захарович Суриц (1882–1952), совет дипломаты, 1922–1923 елларда РСФСРның Норвегиядәге дипломатия вәкиле) аерым бер клуб төзеп, һәм бу клубта коммунизм сәясәтендә төрек студентлары тәрбия итәчәк көтеп тә, атнада ике тапкыр мәҗбүри чыгышлар ясый башладылар, һәм «Туран» клубыннан китү тыелган иде. Фәкать совет паспортлы студентлар, коммунист кушуы буенча мәҗбүри буларак киткәннәре хәлдә, «Туран» клубына яшерен рәвештә килә һәм көннән-көн төрек агымында кала иде. З.Вәлиди 1924 ел Берлинга килгән вакыт (Вәлиди Берлинга 1924 елның 15 февралендә килә) «туранчылар»ның юлбашчысы Фуад Туктар, Гаяз Исхакый бәкләргә мөсафир булган вә аларның арадашчылыгы белән «Туран» клубына элек мөсафир сыйфатында, соңрак әгъза сыйфатында кабул ителде. Бу вакытларда «туранчылар», «советчылар» арасында бәхәсләр шактый куәтле булганнан, болар арасында мөнәсәбәт тәмам туктатылган бер хәлдә иде. З.Вәлиди әфәнде, элек Берлинда китапханәләргә китеп, гыйлем юлында эшчәнлеген башлады. Фәкать «советчылар» клубына да авырлык белән генә бара башлый. Ул вакытта большевик илчесе булган Крестинскийга (Николай Николаевич Крестинский (1883–1938), совет сәяси эшлеклесе, дипломат. 1921 елдан РСФСРның (СССР) Германиядәге тулы вәкаләтле вәкиле) да берничә тапкыр визит ясый (болар махсус комиссиянең тикшерүе белән мәйданга чыгарылмыштыр). З.Вәлиди әфәнденең бу хәрәкәте «төрекче» арасында фетнә уятырга башлаганнан, З.Вәлиди әфәнде бу сурәттә хәрәкәтнең тугры булмаганын сөйләгән вә үзенә бу рәвештә хәрәкәтләрдән ваз кичәсен искәрткән иде. З.Вәлиди әфәнде [моңа] каршы: «Крестинский – иске дустым. Минем мөгамәләмнең Россиядән сыену урыны хакында рөхсәт сорар өчен киттем», – фәлән диеп җавап биргәндер. Бу вакытларда З.Вәлиди әфәнденең «туранчы» әзәри, төрекмәнстанлылар арасында бер икейөзлелек орлыгын атты һәм төрек-татар студентларына каршы бер дошманлык фикеренә керергә тырышу хәбәре алынганнан соң, мәсьәләне ийе (яхшы) рәвештә хәл өчен З.Вәлиди әфәндегә яңа искәртү ясады. Моның аркасыннан З.Вәлиди әфәнденең советлар клубына китеп, советчы студентларына кабиләчелек нигезендә лекцияләр укыган хәбәре алынды. Озак та үтмәде, Берлинда тупланган Мәскәүнең рәсми сәясәтенә каршы килгән коммунистларның иҗтимагый фәненә кушылып китте вә моннан коммунизм нигезендә (милләтчелек һәм төрекчелек хәрәкәтенә начарлык итү нигезендә) чыгышлары мәгълүм булды һәм, ниһаять, ике ярым интернациональлек журналында чыгышы басылды. Бу чыгышның тавыш чыккан иде. Бу доклад дөньяда барлыкка килгән «җәмгыять» исемле бер Төркестан коммунист фиркасе исеменнән сүз сөйли иде, «туранчы»ның бөекләре Төркия төрекләрен яшерергә теләп, үзе туплатып, З.Вәлиди кечкенә бер мәҗлес чакырды һәм үзенең хәрәкәтеннән бер белдерү ясады. З.Вәлиди төрле ялганнар уйлап тапты һәм, ниһаять, «мин коммунист фикерендәмен, төрекчелек, милләтчелек барысы да буржуазиядән алданмак өчен иҗат итәргә тиешләрдер» кебек сүзләрдә булынды. «Туран» җәмгыяте З.Вәлидине, җәмгыятьтән читләштергәннән соң, гомуми бер хәленә бәйләде. Бу хәл белән хәбәрдар булуыннан З.Вәлиди, Берлиндагы большевик шымчылыклар белән («Туран») клубында яшерен мәҗлесләр ясап, советлардан алып бөтен студентларга «Туран» җәмгыятенә килмәскә әмер бирделәр һәм мәҗлестә бөек бер тавыш-гауга ясадылар. Мәҗлес бердәм, ниһаять, «Туран» җәмгыяте аерым бер комиссия сайлады. З.Вәлидинең хәрәкәтен тикшерде һәм аны әгъзалыктан читләштерде, ләкин шул форсаттан файдаланып, советчы клуб эшчәнлеген куәтләндерде вә З.Вәлиди әфәндедән лекцияләр укытып, бөтен бу хәрәкәтләр, татарларның үзенә дошман кебек тәкъдир итте, «Туран» җәмгыятенең берлек нигезенең боргалануына сәбәп бирде. Бу хәрәкәттән соң «Туран» җәмгыяте, иске вазифасына кайтармыйча, вә акрынакрын моннан соң З.Вәлиди, мәсьәләдән хәбәрдар булмаенча, әзәри матбугатында татарларга каршы мәкаләләр нәшер итте. Аурупадагы бөтен татар колониясе бу ялганчы хәрәкәт өчен З.Вәлиди әфәнде белән бөтен мөнәсәбәтен кискән иде вә аңа бойкотлар игълан итте. Шул араларда доктор Риза Нурбәк (Риза Нур бәй (1879–1942), төрек докторы, сәясәтче, дипломат һәм дәүләт эшлеклесе) Берлинга килде вә З.Вәлиди әфәндене Төркиягә чакырды. Совет Россиясенә кайтыр өчен Төркиягә күчтек […] арасында икеләнеп калган З.Вәлиди, ниһаять, Төркиягә китү ихтыярында һәм дә большевикларның Берлиндагы илчесенә [ГПУ] шымчылары булган Агабеков (Г.Исхакый бу урында РСФСР (СССР) тышкы разведка идарәсе хезмәткәре Георгий (Григорий) Сергеевич Агабековны (Арутюнов) (1895–1938) күз уңында тота кебек. Ул 1930 елда Истанбулдан Франциягә кача. Кремльнең сәясәте һәм Гадәттән тыш комитетның махсус бүлеге эшчәнлегеннән риза түгеллеген белдерә) тарафдарларына үзенең гаебен танып, большевик кушканны үтәүче Галимҗан Идрисидән алган ярдәмнәр бәрабәрендә Габделкадыйр исемендәге берсе (Фәтхелкадыйр Сөләйманов (Габделкадыйр Инан) (1889–1976), әдип, публицист, галим, башкорт милли хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе) белән Төркиягә юнәлде. Төркиягә Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Фуад Туктар кебек илле яшьлек җәмәгать хезмәткәрләре урнашкан иде, вә



болар монда урнашкан Совет илчелегенең әгъзасы янына килмәде. Бу эштә З.Вәлиди исеме большевикларның алдында бер кул булды. Ул да Көпрүлүзадәнең [Фуад Көпрүлүзадә (1890–1966), төрек галиме] Хәсән дус итеп Садри Максуди бәйгә сәяси мәкаләләр яздырды. Шул вакытларда (1925 еллар) Анкарада «Инкыйлаб» исемендә бер гәзитә (бу газета турында әлегә мәгълүмат табылмады) нәшер ителә башлаган иде. Гәзитә төрек революционерына тирәнрәк керергә һәм төрек инкыйлабына большевикларны кертергә тырыша иде, вә сөйләүләренә күрә большевик хөкүмәтенең акчасына нәшер ителә иде. З.Вәлиди гәзитәнең идарәсе белән якын мөнәсәбәткә керде. Вә аның наширләре белән «Инкыйлаб»та Садри Максуди, Гаяз Исхакыйга каршы мәкаләләр бастыра башлады. Аның белән генә калмады, Ага углы Әхмәд (Әхмәт Агаоглы (1869–1939), җәмәгать һәм сәяси эшлекле), Акчура углы Йосыфка (Йосыф Хәсән углы Акчура (1876–1935), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист) да ачу тотты, вә бер татарча кавемлеге фикерен аңлатырга теләсә дә, хөрмәт белән кабул ителмәде. («Инкыйлаб») ниһаять, хөкүмәтенең әмере белән ябылды. З.Вәлиди мөгаллим сыйфат белән Көпрүлүзадәнең әтрафында урын алды. Һәм берникадәр вакыттан соң, Төркиядә булган төркестанлы мөһаҗирләр белән берләшеп, төркестанлы Чокай углы Мостафаның оештырган «Яшь Төркестан» журналы мөхәррире булды (Төркестан милли бәйсезлек идеяләрен таратуда төп рольне башкарган «Яшь Төркестан» журналы 1929–1939 елларда Парижда басыла. Баш мөхәррире – Мостафа Чокайоглу. Бу журналда З. Вәлиди язмалары да барлыгы мәгълүм).

Фәкать озак вакыт үтмәде, төркестанлылар арасына кереп, фетнә белән төркестанлылар бәрабәренә дошман ясады һәм Төркестан мөһаҗиртен деморелизе итте. Ниһаять, төркестанлылар бу әфәндененң читләштерелүен [соңарап кына] белделәр вә З.Вәлидине араларыннан чыгардылар. Һәм аның белән катгый [эш] иттеләр. Моннан соң З.Вәлиди башкорт кавеме фәлән исемендә бәгъзе мәкаләләр фәлән берлә Идел-Урал мөһаҗирәтенең хәрәкәтенә кысылырга теләве дә уңышлы булмады. Россиядән чыккан мөһаҗирнең арадашлыгы шикләнү буларак читләшкән бер тормышка хөкем ителде, һәм бу фетнәченең бәласеннән мөһаҗирәт берничә ел тыныч калды. 1930 елларда З.Вәлиди, Совет Россиясендә яклау табу өчен, большевиклар белән дуслыгын [көчәйтер] өчен, «Төркестан тарихы» исемендә язган бер китапны [З.Вәлидинең «Хатирәләр» китабыннан күренгәнчә, «Төркестан тарихы» 1924–1925 елларда Европада язылган. Ул бу хезмәтендә XX гасырның 20 нче елларындагы Төркестанда булып узган мөһим сәяси вакыйгаларны тарихын чагылдыра. Китап, Истанбулга килгәннән соң, Мисырда нәшер ителгән.] Истанбулда бастырды. Бу китапның максаты тарих [исеменә] түгел. Төркестан вә Идел-Уралдагы милли хәрәкәтләрен кысу өчен булган китап басылуы мәгълүм булды. Ул китапта З.Вәлиди Идел-Урал төрек Милли Идарәсе дуслыгына каршы бәхәс иткән бөтен милләтчеләре Төркестанның милли хөкүмәте һәм милли хәрәкәтен инкяр иткән бер эшләр кебек күрсәтергә тырыша вә бик күп ачык тасвирлап яла ягулар, сәхифәләр тутыра. Китапның ялганнан гыйбарәт булганны җимерү өчен, «Яшь Төркестан» мәҗмугасында Мостафа Чокай углының мәкаләләрен тәнкыйть итү дә җитәдер. Моннан соңгы дәвердә З.Вәлидинең Истанбулда Әлфөнүн атлы әфәндегә [бу шәхес турында әлегә мәгълүмат табылмады] бәйләнүе һәм руслык рухындагы студентларга кадәр кыйммәт сарыф итеп, төрек дошманы Бартольдка (Василий Владимирович Бартольд (1889–1930), шәркыятьче, тарихчы) каршы фикер карашыннан начар күрсәтү өчен көч куюы һәркемгә мәгълүмдер. «Төрек тарихы»нда иң мөкаддәс урын ул – уртак төреклек хәрәкәте яратылышында төрек тарихы корылтаена каршы никадәр әдәпсезлек, наданлык хәрәкәтләре дәлиллидер. Бу иптәш, үзен «профессор» кушаматы белән һәр җирдә тәкъдим иткәне хәлдә, башлангыч белемдә алган бөтен мәгълүмат бер авыл имамы булган бабасыдыр. Урта мәктәпләрдә укып, хисап, геометрия, физика, зоология, ботаника, география кебек фәннәрдән тәмам алды. Югары мәктәпнең капкасыннан да шундый юл белән үтмештер һәм фәтване һичбер вакыт укымагандыр. Тарих хакында, нигездә, Төркестан тарихы хакында кулына төшкән китапларны укымыштыр вә мондагы мәгълүматлар туплангандыр.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Мәдәни җомга
1 июль
№25, 2022

Әхмәтзәки хәзрәт

Казан каласының Залесный бистәсендә бер ай элек кенә Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге яңа мәчет ачылды, тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Татарстан Милли музее фондында Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллинның 115 данәдән торган китапханәсе саклана. Әхмәтзәки һәм Габделхәбир хәзрәтләр белән без 1989 елда Идел буе Болгарстанында һиҗри ел исәбе буенча ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үткәндә музейда оештырылган шәмаилләр күргәзмәсен ясаган вакытта танышкан идек. Билгеле сәбәпләр аркасында ул вакыт дини төшенчәләр мөселман галимнәре язган китаплардан түгел, ә көнчыгыш мәдәниятен өйрәнгән ориенталистлардан калган чыганаклар буенча өйрәнелә иде. Ә аларның шәригать кануннарына никадәр тәңгәл килгәнлеген ислам белгечләре генә тәгаенли ала. Шуңа күрә Казан университетының Лобачевский исемендәге китапханәдән алган информациягә тәгаенләргә Казандагы гомер буе ябылмый эшләп килгән Мәрҗани мәчетенә барып, андагы ике хәзрәтебез нигъмәтен тыңларга туры килде. Ул вакыт Габделхәбир хәзрәт Яруллиннан музейга, күргәзмәгә хаҗдан кайткан сувенирларын да алдык. Күргәзмәгә Болгар чоры археологик истәлекләрен һәм 60лап шәмаил куйдык. Һәрберсенә зур-зур аңлатмалы язулар да элдек.

Мәрҗани мәчетендәге Әхмәтзәки хәзрәтнең җомга вәгазьләренә еткәем дә йөрдем. Әхмәтзәки хәзрәт вәгазь сүзләрен катлауландырмый, һәр кешенең белемено карый аңлата белә иде.

Үзе исән чакта Әхмәтзәки хәзрәт һәм аның хатыны Галия апаның өйләренә барып, алар белән бергә җәмәгать намазы укыганым, намаздан соң хәзрәтнең тәсбих тартканы һәм дога кылганы сәгадәт мизгелләре булып бәгырьдә калды. Ул вакыт алар өчен иң якын кешеләре – уллары Әдип абый һәм шәкерте Тәлгать Таҗетдин булганлыгы истә. Кылынган һәр изге эш шул икәүнең берсе хакына эшләнә була иде.

Әхмәтзәки хәзрәтнең китапханәсен 1997 елның 29 декабрендә хезмәттәшем Илнур Газизуллин белән алып кайттык. Ул вакыт Мәдәният министрлыгы музейга экспонатлар алырга билгеле бер күләмдә акча бүлеп бирә, аны тәгәл шул эшкә генә тота, ә ел ахырында ул акча тотылып бетмәсә, икенче елда аның суммасы киселә иде. Шуңадыр һәр ел ахырында күз уңында тотылган ядкарьләрне музейга алу мөмкинлеге хикмәти Хуҗа Насретдин өлгерлеге белән башкарылып килде. Шул ук көнне әйберләр тасвирланып, комиссиясе аша үткәрелеп, акчасы хуҗаларына күчерелде.

Безне Галия апа бик сөенеп каршы алды. Китаплар бер бүлмәле хрущевка квартирасының урамнан керә торган ишек башындагы шүрлектә тезеп куелган. Галия апа: «Акча кирәкми, файдасы булырлык җиргә урнаштыра күрегез», – ди...

Китапханәнең барлык нөсхәләре дә диярлек революциягә чаклы чыккан, Мисырда, Истанбулда, Казанда, гарәп шрифтында гарәп, төрек, фарсы, татар телләрендә басылган. Китапларның күбесе шәригать буенча:

– Камаледдин Сүвәйси әл-Искәндәринең Шәмсетдин Әхмәд Казыйзадә керткән тулыландырулары белән Мисырда басылган «Фәтхел-Кадыйр шәрхе»нең тулы сигез томы;

– Имам Хафиз әл-Манзариның «Китаб әт-тәргыйб вә эттәрхиб мин әл-хәдис». Мисыр, 1906;

– Шәйхелислам бине Әсәдулла Хәмидинең «Мөхтәсарел-Кодури» тәрҗемәсе. Казан, 1911;

– Шәех Ибраһим әл-Хәләби. Шәрхел-кәбир әл-мөния әл-мөсаллә. Мисыр, 1878;

– Шәрхел-Сәйед Гализадә Шәригател-ислам. Истанбул, 1902;

– Имам Галәведдин Әбү Бәкер бине Мәсгуд әл-Касани әл-Хәнәфи. Китабе бидан әс-синан фи тәртиби аш-шаран. Мисыр;

– Шәрхел-төхфәтел-мөлек. Казан, 1902;

– Китабел-һидая вә кифая. Казан, 1905,

– Китабет-тәкърир вәт-тәхбир. Мисыр, 1908;

– Мөхәммәд әл-Кахшани. Җәмигы әр-рөмуз. Казан, 1895;

– Мохтасарел-викая. Казан, 1902;

– Борһанеддин Гали бине Әбүбәкер Мәргыйнани. Әл-һидаяи мәгаль-кифая. Казан, 1905;

– Китабе фәтави Гали әфәнде. Шәригать хөкемнәре;

– Имам Хафизеддин Мөхәммәд Ратавил Базазия. Казан, 1889.

Тәфсирләрдән:

– Мәфатих ел-гайб яки тәфсирел-кәбирнең 8 томлыгы. Мисыр, 1890;

– Җәгъфәр әт-Табарри. Җәмигыль-бәян тәфсирел-Корьән. Мисыр;

– Җәләләйн тәфсире;

– Тәфсир тибияни вә тәфсир мәвакиб. Истанбул,1903;

– Сафавател-гыйрфан фи тәфсирел-Корьән. Казан, 1902...

...Китапларның күбесендә Әхмәтзәки хәзрәтнең үз кулы белән язган искәрмәләре, кем милкендә булып, кемгә күчкән, күпмегә сатып алынганлыгы турында информация бар. Шулар арасында Габдрахман Мостафа улы, Кыяметдин Ногман улы, Габдуллажан Шәяхмәт улы Халитов, Шәех Шәрәфеддинов, Гыяседдин Якубов, Касыйм Латыйпов, Исмәгыйль әл-Габди, Габдрахман әл-Согуди әш-Шәфыйги, Мөхәммәд бине Нурмөхәммәд, Пәрвәзетдин – Зыя Камали, Иргали Нигъмәтҗан улы Бабичев исемнәре, мөһерләр, язулар бар. «Нөзһәтел-мәҗалис» китабында: «Сахибел китап Хөснулла бине Бикмөхәммәдов, вакыф, Хәерби карьясе мелла Гариф абзыйдан. Бу китапны сатып алып кайттым мин Мөхәммәдгариф бине Миңлегали 1320 сәнәсендә сәфәрнең 10ында (1902 ел 20 май)». Шәех Ибраһим Хәләбинең «Шәрхел-Кәбир» китабында (1878) – «Бу китапны бән Исмәгыйль Муса улы Бистә Мөхәммәд Йосыф мәхдүм акчылы 5 сумга сатып алдым» – дигән. Әхмәд бине Гали әр-Разиның Корьән тәфсиренә Әхмәтзәки хәзрәт «1968 елның 3 сентябрендә 15 сумга алдым», «Мөхиббе ләдуния» тәрҗемәсен 1968 елда 5 сумга алдым», дип язган.

Имам Мөхәммәд Рази хәзрәтләренең 9 томлык зур тәфсирендәге язулар бик мөһим һәм кызыклы (Мисыр, 1890). Анда Әхмәтзәки хәзрәтнең мөлкәт язулары, беренче томның форзац битендә китапның авторы турында «Кәшфез-зөнун» китабыннан алынган информация. «Ошбу китап иясе мәрхүм Габдеррахман Галибшаһ угылы дип догалар кылырсыз дип үтенеп калдык», – дигән язулардан Әхмәтзәки хәзрәтнең бабаларыннан килгән Алишев фамилиясе Габдрахман Галибшаһ улыннан килә дип уйладык. Тәфсирнең VIII томының титул битендә «Шамсумухамед Нурмухамедович Зябиров. Дер. Сасмак Малмыжского уезда» дигән мөһер куелган.

Китапханәдәге мөһим китапларның берсе «Сафавател әл-гыйрфан фи тәфсирел-Корьән». Ул китап Казанда Домбровский матбагасында 1899 елның апрель аенда басылган. Титул битендә Әхмәтзәки хәзрәтнең «Алишев Зәки Мораса» дигән язу һәм аның остазы «Мөхәммәдкасыйм Габделгәлләм угылы» дигән имза, кырый буйлап русча «Указный мулла 2 соборный мечети Салихов,» – дигән мөһер куелган. «1907, 13 май,» – дип язылган. Китап эчендә Әхмәтзәки хәзрәт кулы белән язылган татар телле язу кисәкләре бар. Бу тәфсирле Корьән зур хәрефләр, каллиграфик матур язу белән язылып аскы өлешендәге аңлатмалары басма хәрефләр белән бирелгән. Китап реставрацияләнгән, төзәтелгән вакыт алды-артына берничәшәр бит акбурланган кәгазь өстәп кертеп калдырылган. Дермантин тышы да мөселман китабына туры китереп батырып бизәкләнгән.

«Мөкаддимәи бидан мәга шәрхи Габдулла вә Мәгази». Казан, 1899 – мәдрәсәләр өчен гарәп теле грамматикасы китабының форзацына болай дип язылган: «Бер адәм миңа һәдия итеп бирде 1976 елда. «Үзем мин укырга бу китапларны белмимен», – диде. Аңарга да кемдер һәдия итеп биргән булган. Сәфәргали Гомәр улы Тукаевныкы булды. Хәзер дә бу көннәрдә минем милкем булды. Үзем инде картлык яшьләренә ирештем, 95 яшькә җиттем. Дөньяда торырга өмет бетте. Инде мин файдаландым кирәк кадәрле бу китаплардан. Миңа инде шул җитәдер. Үземнән соң бу китаплардан файдаланырдай варисларым юктыр вә татар кардәшләремездә андыйлар юк. Бу китаплар әрәм булмасын дип шундый фикергә килдем. Казан карт шәһәр, татар илләренең мәркәзе дип, анда файда алучылары да булыр дип, анда тапшырырга карар кылдым. Мин кирәк кадәр файдаландым, миннән соңра укучылар да файдалансыннар. Бу хакта дәләлә итеп тапшыручы имамларымызга да Алла рәхмәт кылсын. Чит илләргә Урта Азия адәмнәренә бирергә дә ярыйдыр. Сәфәргали Гомәр улы».

Галия апа Габделкәрим кызы Сафиуллина – үз нәселе буенча Абушаева – китапларны тапшырганда «кирәкле кешеләр файдалана алырлык җиргә урнаштыр» дигән иде. Гомумән, аз сүзле Галия апаның хәтергә кереп калырлык зирәк сүзләре күп иде. Үз нәселе ягыннан да мәгърифәтчеләр нәселеннән булгандыр. Икесе дә, үзләре шәхесләре турында сөйләшергә яратмады. Әхмәтзәки хәзрәтнең нечкә талдан үргән башлыкка чорналган чалмасы ун еллап музейда сакланды. Мин аны, ышаныч язуы белән, Габделхак Саматовтан алган идем, соңыннан Габдулла хәзрәткә илтеп тапшырдым. Хәзер Мәрҗани мәчете музеенда экспозициягә куелган. Чалма белән бергә күк төстә уң якка төймәле өс киеме бар иде. Аны да чалма белән тапшырган идем. Кесәсендә кульяулыгы да бар иде. Әхмәтзәки хәзрәт бер мәҗлестә хуҗадан бер тастымал сорап алды да сәдаканы шунда төрде һәм «Мәрҗани мәчете тартмасына илтеп салырсыз», – дигән иде.



Китапларны Әстерханнан килгән, Әхмәтзәки хәзрәтнең шәкерте Юныс Нәбиуллиннан беренче дин белеме алган Җәмилә Заһидуллина тасвирлады. Һәрвакыттагыча, Марсель абый Әхмәтҗанов белән киңәшләшеп эшләдек.

1400 елда (1979-1980) имам Тирмизинең Ташкентта Азия һәм Казахстан олысы дини идарәләре тарафыннан кульязмадан офсет ысулы белән бастырып чыгарылган «Китабеш-шәмаилен, нәбәват» китабының титул битендә Әхмәтзәки хәзрәтнең үз кулы белән язылган шәҗәрәсе бар: «Имам Зәки бине имам Сафиулла бине Сибгатулла бине Нигъмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим бине Әлмәт бине Сәрмәт бине Алыш. Галишаһ Кәнвани, мөзафәтел-Тәтеш».

Ризаэддин Фәхреддин «Асар»ында Әхмәтзәки хәзрәтнең шәҗәрәсендәге бабаларыннан түбәндәгеләре турында язылган.

«Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт бине Әлмәт бине Алыш. Чистай ягында имам булып 1210/1796 елда вафат булган. Кабере Әлмәттә. Балаларыннан вә онықларыннан хәтта бу көннәребезгә кадәр олуг затлар килеп чыга тора. Үзе язган «Каһестани» ахырында болай ди: Бу нөсхә Казан вилаятенең Болгар ягы Нугай юлында яңа Әлмәт авылында 1178/1764 елда җомга көн Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт Хафиз бине Әлмәт әл Әфзал бине Алыш тарафыннан язылды. Милади белән 1744 елда, перепись вакытында «Ибраһим Сәрмәт улы – 54 яшендә, Хөсәен Ибраһим углы 20 яшендә, Җәгъфәр Ибраһим углы 15 яшендә, Зәйни 12 яшендә, Хәмәл (кучкар) йолдызлыгында» дип язылган икән. Казан шәһәрендә зур сәүдәгәр Бикбау бине Исхак бине Солтангали кызы әлеге затның никахында булуы кайбер җыентыкларда күренде. Кизләү авылындагы Гобәйдулла хәзрәтләре моның углы иде.

Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим Чирмешән елгасы буендагы Кизләү авылында имамлык һәм шәехлек иткән. 72 яшендә шәүвәл аеның 26/6 июль көнне, 1238/1823 елда вафат булган. Кабере Кизләүдә булып, өстенә куелган ташы да бар. Габдессәлам бине әл-Кариле хозурында гыйлем өйрәнгән, Вәлид бине Әмин әс-Сәгыйдидән белем алып, камиллеккә ирешкән һәм үзеннән дә күп затлар укып өйрәнгәннәр. Хатыны Иске Сәлман

мирасы

авылының Әбелкасыйм кызы Хафизә булып, 1248/1833 ел зөлкагдә / апрель аенда вафат булган. Вә икенче хатыны Габидә Әхтәм кызы да шул ук Сәлман авылыннан булып, 1258/1842 Казан шәһәрендә вафат булган.

Балалары: Нигъмәтулла, Рахмәтулла, Мөхәммәд, Хәбибулла, Габделбәдигъ, Әхмәд, Хәбибә, Мәхбүбә, Гайшә, Фатыйма. Хәбибулла Кәкре Тау авылында һәм Габделбәдигъ Исәнтимер авылында имам булып, Әхмәд кечкенә яшьтә вафат булганнар. Хәбибә Алабуга өязе Илмәт авылы Назар Илмәт угылы никахында, Мәхбүбә Уразгилде фамилиясендә Бикмөхәммәд бине Мөхәммәдрәхим никахында, Гайшә Чистайда Габделхәким исемле зат никахында, Фатыйма Казанда Кәшәй Мортаза никахында булганнар. Башка балалары турында алда аерым сүз булачак.

Шәкертләре һәм тарафдарлары: Габделваһаб бине Иманкол әр-Рәҗәби, Бәшир бине Җомгаколый әл-Җәбәли, Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәти, Монасыйб әл-Җәбәли, Һибәтулла бине Исхак әл-Мачауый, Әхтәм әл-Җәбәли, Ярулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышый, Хәмзә әл-Җәбәли һ.б. Уз телебездә тарикать-ишанлык әдәпләре хакында бер китабы булган. Бу зат хакында Мәрҗани: «Заманында мәшһүр вә олуг галимнәрдән бере иде. Мөридләр тәрбияләп, ишанлыкта шәех иде», – дигән.

Нигъмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр Чистай өязе Әлмәт авылында имам булып, 82 яшендә 1269 (1853) елның 22 җөмадиел-ахирендә (22 март) вафат булды.

Балалары: Гатаулла, Хәйрулла.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдерахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һәм башкалар. Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдадидан – кыйраәт гыйлемен, атасы шәех Гобәйдулла бине Нигъмәтулладан тарикать гыйлемен алган.

Шәкертләре: Телгә алынган уллары, Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәрәви, Габделваһһаб бине Иманколый әр-Рәҗәби, Габид бине Габделҗәлил әл-Кармышый һәм башкалар.

Хәлифәсе: Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәрәви иде. Хәбибулла бине әс-Сенбери исемле затның моның хакында сөйләнгән мәрсиясе бар.

Әхмәтзәки хәзрәтнең Нигъмәтулла бабасы белән бертуган (А.Р.) Рахмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви мәшһүр Кизләү-Корманай авылында имам вә мөдәррис булып, 1261/1845 ел рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Үзенә алмаш булачак һәм гыйлеменә дә варис итеп саналачак баласы калмады. Токымы өзелмәгән, бәлки, киләчәктә берәрсе күренер.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, атасы шәех Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади һәм башкалар. Шәкерте күп вә дәресе файдалы булганын сөйлиләр. Бу кемсә хакында фазыйл Мәрҗани: «Заманында булган шәехләрнең берсе, кыйраәт гыйлеменең имамы иде; гыйльме кыйраәттә Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәтидән маһиррак вә яше кечкенә исә дә туганы шәех Нигъмәтулла әл-Әлмәтидән белемлерәк иде; мөрид тәрбиясе белән дә шөгыльләнде», – дигән.

Мөхәммәд бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви Чистай мозафәте Кизләү карьясендә имам вә шәехлек итеп, 80 яшьләрендә ике йөз туксан алтынчы (1296/1879) ел, 26 Зөлхиҗҗәдә (29 ноябрь/11 декабрь) вафат булды вә шул авыл каберстанында атасы Гобәйдулла ишан янына дәфен ителде. Ташы бар, мәкъбәрдә язылган нәрсәләре үлчәүсез сүзләрне мөштәмил (үз эченә алган).

Атасы Гобәйдулла вә агасы Нигъмәтулла ишан хозурларында укып, Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәрәвидән мөрид тәрбиясе хакында мәэзүн (берәр эшкә хокук бирелгән) иде, диләр.

Мәхбүбкәмал исемле хатынынннан Маһи, Гайшә, Әхмәд, Мәхмүд, Гайнелхәят, Сөләйман исемләрендә вә Маһиҗәмал исемле икенче хатынынннан Зәһирә исемендә кызы булып, өченче хатыны Гыйльмеҗиһаннан баласы булмаган.

Сахибе тәрҗемә хакында фазыйл Мәрҗани: «Кавеме бәйнендә гыйлемгә вә китап моталәгасына һәвәсле булып, тәкълиддән чыгарга һәм рәгъбәте бар иде, киез итек үзәренә мәсех (чистарту; кул белән сыйпау) тарту дөрестлеген сөйләр иде. (Максуды тула оек булса кирәк, юкса киез итеккә мәсех кылу дөрестлеге хакында ихтиляф булмаса кирәк), ахыр гомерендә үзенең әсхабенә хитаб кылып: «Ата-бабаларымыз кыска төнләрдә ястү намазы фарыз түгел – мәсләгендә булса да, мин монларга хилаф булса да, укуны лязим дип, игътикад итәмен вә укыйм, сез һәм укыңыз вә куймаңыз!» – дигәнлеге мәнкуль (сөйләнгән), агасы Рахмәтулла бине Гобәйдулла мәкамы берлә кыйраәте гүзәл иде», – ди («Мөстәфадел-әхбар». Җ. 2. 228-229 б.).

Вафат булганында ишанлык ике кешегә калды. Бере – үзенең туганы Нигъмәтулла ишан /73 а/ угылы Хәйрулла (Чистай мозафәте Әлмәт авылында имам). Икенчесе дә безнең остазымыз Габделфәттах бине Габделкаюм (Бөгелмә мозафәте Шәлчәле авылында имам вә мөдәррис)...

...Сахибе тәрҗемә шәех Мөхәммәд хәзрәтләре дәүләтле бер адәм булса да, үз гомерендә хаҗ кылмады, хаҗ берлә васыять һәм итмәде, варислары үзләре теләп тә аның өчен хаҗ итдермәделәр, аталары вә тугайлары, бөтен сәләфләре шушы мәсләктә булдылар, диләр.

Әхмәд исемле угылы, Мамадыш мозафәте Кече Сөндә Фәхреддин бине Садыйк мәдрәсәсендә укып, Фома авылында вә соңыннан Кизләүдә имам булып торды, Әлмәтнең Хәйрулла ишан рөхсәте берлә ишанлык итте вә 1321/1903 тарихы, 12 шәгъбан (3 ноябрь) аенда дөньядан /74/ үтте. Әүләды күп.

Мәхмүд исемендәге икенче угылы да Кизләүнең икенче җәмигында имам иде. Туганы Әхмәд мәхдүм рөхсәте берлә ишанлык кылды, диләр. 1329/1911 тарихында, 26 җөмадиел-әүвәлдә (25 май) вафат итте. Сембер шәһәрендә имам вә ахунд Мөхәммәдшакир бине Вәлиулла моның өчен хаҗ кылды, диләр. Вәлиәхмәд исемле угылы үз урынында имамдыр.

Сөләйман исемле өченче угылы ошбу авылда рәсми имам булса да, мәсҗедкә йөргәнен күрмәдем. Сәүдә кәсебе берлә мәшгуль иде. Атасыннан соң 1317/1899 ел, 8 шәһре рабигыль-әүвәл (17 июль) көн вафат булды. Балалары бар.

Кызларыннан Маһи Киекледә Вәлиулла бине Габделҗәббар бине Гомәр никахында иде. Гайшә Спас мозафәте Чалайда имам вә Оренбург собраниесендә әгъза булып торган Әхмәдҗан бине Мөхәммәдҗан бине Максуд бине Нурай никахында иде. Гайнелхәят Әхмәдҗан казый ибне Мөхәммәдҗан туганы Зариф никахында иде. Зәһирә Лаеш мозафәте Күгәрчен карьясендә имам Мөхәммәдфатыйх бине Мөхәммәдҗан бине Биккенә никахында иде. Ошбу Мөхәммәдфатыйх бине Мөхәммәдҗан соң вакытында мөэзиннең вазифасы берлә Кизләүнең икенче мәсҗеденә күчте вә 52 яшендә вакытында, 1327/1909 ел, 10 рабигыль-әүвәлдә (19 март) вафат булды. Төрбәсе ошбу карья каберлегендәдер.

Сахибе тәрҗемә Мөхәммәд хәзрәт ошбу өченче җилд «Асар»да язылган затлардан үзем күргән мөдәррисләрнең беренчеләредер. Мәдрәсәи тәрбия итүче вә шәкерд укытучылардан мондан Мөкаддәмдә мөстәкыйль рәвешдә язылганларны күрү мөяссәр булмады» (Риза Фәхреддин. Асар. Казан. Рухият. 2006).

Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин бу нәселдәге имам мөдәррисләрдән «Үзенә алмаш булачак һәм гыйлеменә варис итеп саналачак баласы калмады. Токымы өзелмәгән, бәлки, киләчәктә берәрсе күренер», – дип әйтеп калдырган.

Әхмәтзәки хәзрәт китапларын алганда безнең кулда калган язылмаган буш дәфтәрләрне үз нәселендәге «өзелмәгән токым»нан күренәсе XXI гасыр мәгърифәтче галименә тапшырырбыз, дип хәзер дә саклап тотам.

Рәмзия АБЗАЛИНА,
Милли музейның
фәнни хезмәткәре.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

2 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 5.48 сәгатьтә калка, 22.45 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.26 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Дарусыз дәвалану

Көнгә 2 стакан сөт эчү йөрәк өянәгеннән, 9 өрек ашау күкрәк бакасыннан (стенокардиядән) саклый. Е витаминына бай ризыкларны (яшелчә, сыр, эремчек, борчак, үсемлек мае) көнгә 3 мәртәбә ашау йөрәк һәм кан тамырлары өчен бик файдалы. Атнага 4 кисәк балык ашау миокард инфарктыннан үлү куркынычын 44 процентка киметә. Бер көн калдырмыйча бик озак вакыт көн саен 5 әр әстерхан чикләвеге ашаган кеше гомерен 7 елга озынайта, чөнки әлеге чикләвектә йөрәк һәм кан тамырларын холестериннан саклый торган матдәләр күп. Атнага 7 банан ашау йөрәк ритмын нормальләштерә, нерв системасын тиешле энергия белән тәэмин итә.

3 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 7.06 сәгатьтә калка, 22.57 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.26 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

4 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 8.25 сәгатьтә калка, 23.06 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.24 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Ютәлдән дәва

Халык медицинасында ютәлне басу өчен еш кулланыла торган чаралардан берсе – кура җиләге, шуңа җәен аның яфрагын да, җиләген дә җыеп калу яхшы. Бу җиләктә бакыр, тимер, калий, клетчатка, пектиннар һәм салицил кислотасы, С, В1, В12, А, Е витаминнары, никотин кислотасы (РР), шулай ук фитонцидлар күп. Кура җиләге яфракларын, ботакларын яки чистартылган тамырын 1 сәгать кайнар суда төнәтеп, сөзеп, тәменчә бал кушалар һәм чәй урынына эчәләр, тамакны чайкыйлар. Җиләкне ашау да бик файдалы. Яки кура җиләген изеп, 2:1 исәбеннән шикәр кушалар да, суыткычта саклыйлар, чәй эчкән саен, чынаякка 2 шәр чәй кашыгы салып эчәләр.

5 июль (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

йолдызлыгында, 9.44 сәгатьтә калка, 23.14 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.22 сәгать.

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Тоз тешне ныгыта

Бер чеметем борыч һәм чирек чәй кашыгы аш тозы катнашмасы - менә дигән теш порошогы. Көн саен тешне шуның белән чистарту кариестан саклый, авыздан килгән тәмсез исне бетерә, уртларның канавын, теш сызлавын туктата. Уртларны ныгыту өчен, аларга көн саен сарымсак ышкырга кирәк. Дәва курсы - 2 атна. Аннан соң 5 көн ял итеп, тагын кабатларга мөмкин.

6 июль (чәршәмбе). *Зөлхиҗҗә аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 11.03 сәгатьтә калка, 23.22 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.21 сәгать.*

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Суганлы алма

Цистит интектергәндә, уылган алма белән суганны һәм балны тигез микъдарда кушып, көненә 3 тапкыр 2 шәр аш кашыгы кабалар. Сихәтләнгәнче, шулай дәваланалар.

7 июль (пәнҗешәмбе). *Зөлхиҗҗә аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 12.25 сәгатьтә калка, 23.30 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.18 сәгать.*

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Кишер чәчне үстерә

Чәч тизрәк үссен өчен, тигез микъдарда кушылган кишер һәм лимон согын баш тиресенә әледән-әле сөртергә кирәк. Чәч кавыкланганда, баш тиресенә 10 өлеш календула төнәтмәсенә 1 өлеш касторка мае кушып сөртәләр (атнасына 2-3 тапкыр эшләргә киңәш ителә).

8 июль (җомга). *Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 13.52 сәгатьтә калка, 23.40 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.16 сәгать.*

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң уңай вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Тиз пешә торган пицца

4 әр аш кашыгы каймак һәм майонез, 2 йомырка, 9 аш кашыгы оннан камыр туглыйлар, майланган табага агызалар. Өстенә казылык йә гөмбә, помидор телемнәре тезеп, уылган сыр, тәмләткечләр сибәләр, кетчуп яки майонез белән чылтырлиләр, сурән утка куеп, өстенә капкач ябалар да, сыр эрегәнче пешерәләр.

«Гөлҗамал»ны Мәскәү тыңлады

Җәйге гадәти эш көннәренең берсе иде, редакция бүлмәсенә өлкән яшьтә булса да, көч-куәтен, житезлеген җуймаган күркәм бер ир-ат килеп керде. Таныштык: зәңгәр күзләреннән әле дә нур бөркелеп торучы агай Әнвәр Солтан улы Гыйниятуллин икән, отставкадагы хәрби, 78 яшендә. Тик үзенә һич тә бу яшьне бирерлек түгел. Безгә сөенечле яңалыкларын җиткерергә керүе. Шушы көннәрдә ул уйнап-җырлап йөри торган «Гөлҗамал» ансамбле Мәскәүдә үткән халык иҗаты конкурсыннан беренче дәрәҗә диплом алып кайткан. «Музыка моего народа как национальное достояние» дип аталган әлеге конкурсның финалы башкаланың Чайковский исемендәге кече концерт залында узган. Анда ансамбльнең ике кешесе чыгыш ясаган - Фәрзәнә ханым Кулеева «Гөлҗамал» ны җырлаган, ә Әнвәр әфәнде аңа гармунда уйнаган. Фәрзәнә ханым – тугызынчы дистәсен ваклап килсә дә, кайбер кызларга алыштыргысыз энергияле, куәтле рухлы, көчле күкрәк тавышына, киң сулышка ия җырчы. Гомере буе КАИда укыткан математик, профессор, халык җырларына гашыйк кеше. Гармунчысы да үзенә тиң – яшьтән сәхнәдән төшмәгән Әнвәр ага, ике рәтле гармунын 370 меңгә Италиядән кайтарткан. Аларның чыгышын көчле алкышлар белән бик яратып кабул иткәннәр.

«Гөлҗамал» ансамбле Казанда 1995 елдан бирле эшләп килә, анда хәзер өлкән яшьтәге тугыз кеше җырлап йөри, иң яше дә алтмыштан узган. Бары тик борынгы җырларны – «Уел», «Тәфтиләү», «Порт-Артур» һ.б.ларны гына җырлыйлар. «Каравон», «Балкыш» фестивальләрендә, «Түгәрәк уен»да һ.б. күптөрле чараларда бик теләп чыгыш ясыйлар. «Безне хәтта туйларга да чакыралар», ди Әнвәр әфәнде. Йөрәкләрендә милли рухны, яшәү көчен, җыр-моңнарыбызга карата тирән мәхәббәт саклаган бу матур кешеләргә «Афәрин»нән башка сүз юк, әлбәттә.

Эльмира СИРАҖИ.

Гаяз ИСХАКЫЙ: Зәки Вәлиди кемдер?

(Ахыры. Башы 15 нче биттә).

Фәкать тарихның фәлсәфәсе хакында катгый хәбәре булмаганлыктан, бу мәгълүмат кармагына эләккән кебек, бу рәвештә керешкәндер. Тулысынча файда итәчәгеннән бик озак бер хәлгә куелгандыр. Язган «Төрек-татар тарихы» китабы да бу рәвештә бериш мәкаләләрендә, сөйләгән докладларында бик күп чыганаклар күрсәтелгән бер әфәндедер. Бу чыганаклар арасында даими инглизчә, французча, немецча, финча китапларның исемнәрен мәктәпле рәвештә искә алып китә. Фәкать үзенең белгән теле ялгыз русча гынадыр. Аурупаның һичбер теленнән укып, аңлап беләчәк хәзерлеге юктыр. Моның өчен бу әфәнде гыйльми җәһәттән шарлатандыр. Бу әфәнде сәяси җәһәттән большевизм яклы бер интригачыдыр. Бу әфәнде төрекчелек фикереннән даими яктан төрек берлегенә аяк чалучы, вә даими төрек дошманнары белән кулны кулга бәйләгән бер милли хаиндер. Вә бөтен төрек җәмгыятеннән читләштерелгән җирәнгеч бер шәхес. Тәрбия ихтыяры белән бу әфәнде ялганчы, хыянәтче һәм гаилә җәһәтеннән гаять шомлы бер иптәштер. Хәзер ки көндә бер бәян үзен фән корбаны, икенче бөек күрсәтеп, Аурупадагы гади тел тюркологларын катдырмак алардан финанс ярдәме алып, хәзер ки көндә Төркиягә вә Төркиянең инкыйлабы гыйльми даирәләрен каралату өчен һәм боларга каршы яла ягулар белән мәшгуль булды. Каршы килгән һәр урында, форсаттан файдаланып, бу шомлы хәрәкәт ясамактадыр һәм, төрекләк галәменең кыйммәтен кечерәйтү өчен, төрек тарихы, төрек теле конференциясендә төрек шовинизмы кебек күрсәтергә тырышкандыр. Һәм тюркологлар арасында Төркиянең гыйльми даирәләрендә иминлеген кечерәйтмичә ният булганы шиксездер. Бу инкяр ителгән хәрәкәтләре өчен бөтен төрек милләтчесе бу шарлатан иптәшнең каршылыгына көч бирүчедер вә моны хәзер ки көндә ялгыз Шималь төрекләре, төркестанлылар вә төркияле ләре түгел, бөтен төрек галәме хаине саналачактыр, вә бу иптәш хакыйкать ягынннан хаиндер.

Зәки Вәлиди кемдер? Г.Исхакыйның автографы (имзасыз). Мәкаләнең күчермәсе М.Горький исемендәге музейда И.Нуруллин фондында саклана. Текст кулъязмадан алынды.

Бу мәкаләнең язылу тарихына китергән сәбәпләр гаять кызыклы һәм гыйбрәтле. 1924 елның февраль аенда Берлинга килгән З.Вәлиди немец шәркыятьче галимнәре белән очраша, төрек-татар студентлары белән очрашу вакытларында төрле темаларга чыгышлар ясый. 1917 елның 1–11 маенда узган Бөтенроссия мөселманнарының корылтаенда Г.Исхакый белән ике арада башланган фикри тартыш Германиядә дә дәвам итә. З.Вәлиди истәлекләренә караганда, нинди генә темага багышлап чыгышлар ясамасын, әдип-публицист белән З.Вәлиди бәхәскә кермичә калмый. Мәсәлән, 1925 елның 1 апрелендә З.Вәлиди «Шәрекъ клубы»нда «Төркестан авыл хуҗалыгы тарихы» исемендә чыгышын ясый. Аның истәлекләренә караганда, Г.Исхакый бу докладта күтәрелгән мәсьәләләргә, анда яңгыраган фикерләргә дә үз мөнәсәбәтен белдерә. З.Вәлиди дә аны, нинди генә очрак булмасын, һәрвакыт тәнкыйтьләп чыга. Шул бәхәсләр һәм каршылыкларның нәтиҗәсе әлеге кулъязма мәкаләнең дөньяга килүенә сәбәп биргән. Мәкаләдән аңлашылганча, язылу тарихы чама белән 40 нчы елларга туры килә. Язманың төрекчә булуы әдип-публицистның Төркиядә яшәп иҗат иткән чорын раслый. Әлеге язма бу ике күренекле шәхес арасында туган каршылыкларны күзалларга ярдәм итә.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 13 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. 244 б.

Коллегабыз, кайчандыр «ТНВ» каналында эшләгән журналист Финзия Газизова берничә ел инде гаиләсе белән Австралиядә яши. Күптән түгел ул балалары белән туган якларына – Балтач районының Смәел авылына кунакка кайтты. «Җиде яшәр юлдан кайтса, җитмеш яшәр хәл белешер» дигәндәй, без аның белән чит кыйтгадагы тормышы, тәэсирләре хакында әңгәмә кордык.

«Сабан туена кайттым»

– Финзия, Австралиядә ничә ел яшисең инде?

– 2017 елда улым туды, 2018 елда мин көзен 10 айлык балам белән Дубайга очтым, анда ирем Рифкать каршы алды. (Рифкать әфәнде – Австралия татары. – **Ред.**) Анда ике көн хәл алгач, 12 сәгатьлек рейс белән Австралиягә очтык. Бу юлы исә Катар аша кайттык. Ике балам белән кайттым, ирем билетларны махсус сабан туйларына туры китереп алды. Балалар милли гореф-гадәтләребезне белеп үссеннәр, дибез. Сабан туен кечкенә вакытларында күргәннәре бар иде, бу юлы инде барысын да аңлап карадылар, ярышларга да керделәр. Авыл мәктәбендә балалар өчен дә сабан туе үткәрделәр, анда бигрәк тә рәхәтләнеп күңел ачтылар. Көне салкын булса да, күрсеннәр дип, Балтач сабан туена да алып мендек.

– 2018 елга кире кайтыйк әле. Ничек курыкмыйча чит кыйтгага чыгып киттең? Ошамаса, төенчекләрне җыеп әниләргә кайтып китәрлек җир түгел бит…

– Ул чагында ниндидер тормыш тәҗрибәсе бар иде, шактый нәрсә баштан кичкән иде инде. Рифкать минем тормышыма бик авыр чорларны үткәннән, сыналганнан соң килеп керде. Әлегә хәтле киткәнемә үкенгәнем юк, шөкер. Ләкин сагынып, төшенкелеккә бирелеп алган чорым булды. Чөнки үземне нык ялгыз хис иттем, телне белмим, аралашырга кеше юк, читлектәге кош кебек идем. Шундый чакларның берсендә үземнең туган көнемә торт пешереп карарга булдым. Интернеттан онлайн курс алган идем, шуннан карап пешердем. Ул искиткеч тәмле килеп чыкты. Пешергән тортларымны социаль челтәрләргә куя башладым. Тагын белемнәремне арттырдым. Шулай остардым. Бизнес өчен түгел, үз рәхәтем өчен пешерәм хәзер тортларны, шуннан илһам алам. Шулай итеп, үзүземә шөгыль таптым, сагынуларымны бастым. Блогерлык эше белән мавыга башладым. Интернет челтәрендә Казан, Татарстан белән бәйле нинди проект бар, барысында да катнаштым: әдәби марафон, әниләр марафоны, Татар конгрессы үткәргән конкурслар…

– Тел өйрәнү буенча кыенлыкларны җиңә алдыңмы?

– Без Аделаидада үз йортыбыз белән торабыз. Күршеләр сәлам бирә, ә мин телне белмәгәч, тиз генә кереп китү җаен карыйм. Шуңа күрә дә инглиз телен өйрәнү өчен, килеп төшүемнең икенче атнасында ук курсларга киттем. Читтән килүчеләр өчен бушлай махсус курслар бар, шуларга йөрдем. Атнага биш тапкыр инглиз теле укыдым. Аннары соң монда һәр мәктәп каршысында коммунити клублар бар, шунда чит илләрдән килүчеләр өчен атнага ике-өч тапкыр инглиз теле дәресләре үткәрелә. Рәхәтләнеп өйрән генә. Әниләр һәм балалар өчен махсус төркемнәр бар. Балаң белән бергә ике сәгатькә киләсең, балага уенчыклар бирәләр, аларны уйнаталар, әкиятләр укыйлар, җырлар өйрәтәләр. Болар барысы да бушка. Дәүләтнең ашарга пешерергә, бакчачылык эшенә өйрәтә торган махсус бушлай курслары да бар. Пешерергә өйрәтә торганында мин дә укыдым. Шулай итеп, өй янында гына өч җирдә укып чыктым. Яшәү хокукы алганнан соң, әле тагын дәүләт сиңа инглиз телен өйрәнү өчен бушка 500 сәгатьлек дәрес бирә. Монысы инде училище кебек. Мин шуның 1 нче баскычында укыйм хәзер. Имтихан биргәч, икенче баскычка күчәсең. Анысын тәмамлагач, эшкә урнаша аласың дигән сүз. Телне камил белмәүчеләр дә эш таба ала.

– Балаларың бакчага, мәктәпкә йөриме?

– Улыма – 4, кызыма 7 яшь. Австралиядә балалар 3-4 яшьтән мәктәпкә китә, барлыгы 13 ел укыйлар. Беренче елы әзерлек санала. Монда килгәндә, кызым Эмилиягә 3 яшь иде, татарча гына белә иде. Килгәч тә бакчага бирдек, атнага 3 көн йөрү мөмкинлеге бирделәр. Аннары ул мәктәпкә китте, ике ел дәүләти мәктәптә укыды, инглизчәне өйрәнде. Анда башны бәрә-бәрә укыту юк, күбрәк уйныйлар, рәсем ясыйлар, буйыйлар, төсләрне, хәрефләрне өйрәнәләр. Ниләрдер кисәләр, ябыштыралар…. Кызым мәктәпне дә, укытучыларын да бик яратты. Ике ел дәүләти мәктәптә укыганнан соң, кызыбызны өебез янындагы мөселман колледжына бирдек. Монда Коръәнне, пәйгамбәрләр тарихын, хәдисләрне

дә өйрәнәләр. Монысы хосусый мәктәп санала, тик хакы бик югары түгел, елына мең доллар чамасы, ташламалар да ясыйлар. Монда дини-дөньяви белемне бергә алырга бөтен мөмкинлекләр бар. Ислам колледжлары, төрек колледжлары бар, күп мөселманнарның балалары шунда укый. Милләтләргә үз диннәрен тотуны, мәктәптә өйрәтүне тыючы юк. Элегрәк мөселманнарга кырын карау очраклары булган, ләкин хәзер – әлхәмдүлилләһ.

– Аделаидада татарлар күпме, аралашасызмы?

– Әйе, татарлар шактый. Элек 500ләп кеше диләр иде, ләкин соңгы арада күп яңа кешеләр килде, хәзер артыграктыр. Казаннан килүчеләр дә бар, кемнәрдер минем шикелле килен булып төшә, кемнәрдер студент визасы белән килә. Мин килгәч, бер тапкыр татарлар җыелып Нәүрүзне зурлап үткәргәнне хәтерлим. Элек Сабан туйлары да уздырганнар. Монда «Ак калфак» дигән җыр төркеме бар дип беләм, бер-берендә җыелышып, җырлашып утыралар. Гаетләрне зурлап өчәр көн бәйрәм итәләр. Мул өстәлләр әзерлиләр. Үзебез якын иткән кешеләргә, өлкәннәргә барырга тырышабыз. Гаишә апа Маскиларга, Наил абый Габитовларга, Таш абыйларга… Чәйләр эчеп сөйләшеп утырабыз. Алар бик зыялы, милләт җанлы кешеләр, Казанны сагынып сөйләшәләр. Зөһрә Садрый инглиз телендәге балалар китапларын татарчага тәрҗемә итеп язып, матур итеп төреп, балаларга бүләк итә.

– Татар мәктәбе юкмы?

– Аделаидада татар мәктәбе булган, ләкин мин килгәндә, ул инде эшләми иде. Балалар саны җитми, дип аңлаталар. Бәлки, мәктәп киләчәктә яңадан эшләп тә китәр. Монда татарлардан хәлле кешеләр бар. Әйтик, Рөстәм Садрыйлар. Аларның Ләйлә Садрый исемендәге үзәге бар, ул йорт мәчет вазифаларын да башкара. Монда татар җәмгыяте җыела, татарча диктантларны шунда язабыз.

– Гаиләдә нинди телдә аралашасыз?

– Ирем һөнәре буенча бухгалтер, хәзер аның үз бизнесы бар. Балаларыбыз белән татарча гына аралашабыз. Балалар үзара инглизчә сөйли башласа да, этиләре кисәтү ясый. Ютубтан татар концертларын карыйбыз, балаларга татарча шигырьләр өйрәтәбез, «Туган тел»не яттан беләләр. Татарча мультфильмнар карыйлар. Үткән кайтуында ирем Казаннан татар халык әкиятләренең калын китабын алып килгән иде, һәр кич шуны укыйбыз. Узган кайтуымда бер чемодан китап төяп килгән идем, бу юлы да җыям.

– Финзия, Австралиягә килеп төшүгә, сине иң гаҗәпләндергәне нәрсә булды?

– Иң гаҗәпләндергәне – чисталык. Кешеләрнең гадилегенә исем китте. Бер белмәгән кешегә сәлам бирәләр, елмаялар, хәлеңне сорашалар. Аннары мондагы йортларда җылылык булмавы сәер тоелды. Кышын төннәрен җылылык 7-9 градус кына, бик салкын бу, сеяккә үтәрлек. Биналар кондиционер белән генә җылытыла яки электр радиаторлары куялар, кояш батарее кулланучылар да бар. Искерәк өйләрдә утын яга торган мичләр очрый. Көнгерәләрне күрү, коалалар белән танышу да кызык булды башта. Көнгерәләр анда кешедән дә күбрәк, паркларда да очрый. Ачык табигатьтәге зоопаркта коаланы тотып та карадым, ул шулхәтле авыр икән, эвкалипт яфрагы гына ашап тора димәссең…

Әңгәмәдәш –
Эльмира СИРАҖИ.

Бананда да... нурланыш!

Безнең әйләнә-тирәдә радиоактив кисәкчекләр тарата торган әйбер һәм җиһазлар бик күп, әмма кеше организмы аларга гына бирешерлек түгел, нык. Мәсәлән, бананда калий-40 изотобы булганга, ул нурланыш тарата, аны хәтта Гейгер санагычы да терки ала. Әмма әлеге нурланыш тәэсирен тояр өчен, 500 меңнән артык банан ашарга кирәк... Аэропорттагы контрабанда эзли торган сканер бер мизгел эчендә атом электр станциясеннән 80 чакрым ераклыкта бер ел дәвамында алган кадәр радиация белән йогышлый. 10 мең метр биеклектә Нью-Йорктан Лос-Анджелеска алты сәгать буе очканда пассажир әнә шул сканер аша 400 тапкыр үткәндәге кадәр нурланыш ала. Ташкүмер ягыла торган электр станциясе төтенендәге радиоактив матдәләр 80 чакрым ераклыкта яшәүчеләрне шул ук арадагы атом электр станциясенә караганда күбрәк йогышлый. Бразилия чикләвеге агачының тамыры бик тирәнгә китә һәм радийга бай туфракка кадәр барып җитә, нурланышның табигый чыганагы булган радий чикләвеккә үтеп керә. Офисларны һәм сыйныф бүлмәләрен яктырта торган флуоресцент лампаларда еш кына радиоактив криптон-85 изотобы була. Ә инде бу лампалардагы радиоактив булмаган химикатлар тагын да куркынычрак. Шома ак кәгазьне ялтырату өчен каолин дигән ак балчык кушыла, һәм нәкъ менә шул кәгазьне радиоактивлаштыра, чөнки анда уран һәм торий бар. Күкрәк читлеген рентгенга төшергәндә бер секундта атом электр станциясе бер ел дәвамында чыгарганның биштән бер өлеше кадәр радиация тарала. Кесә телефоны яман шеш барлыкка килү куркынычын арттырырга яки баш миен үзгәртергә сәләтле радиодулкыннар чәчә. Кеше организмында да калий-40, уран, торий, углерод-14 кебек элементлар бар.

(“Интересно.сс”).

Сабыйларга – сыйфатлы сөт

Натан Штраус – Америка тарихында иң атаклы шәхесләрдән берсе. Кибетләр челтәре хуҗасы һәм үз вакытының иң уңышлы эшкуарларыннан берсе булып, ул үзенең бөтен шәхси капиталын диярлек Нью-Йорк хәерчеләренә тотып бетергән. Натан - сөтне пастеризацияләүне гамәлгә кертеп, йөз меңләгән сабыйга тормыш бүләк иткән кеше. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында АКШ та балалар бик күпләп үлгән, шул исәптән йогышланган сөт эчеп тә. Европа буйлап сәяхәт иткәндә, туберкулез белән йогышланган сыер сөтен эчерткәч, Штраусларның яңа туган кызлары үлә. Шул фаҗига эшкуарны яңа эшчәнлек - сөтне пастеризацияләү (сөтне 60 минут буе 60 градуска яки 30 минут буе 70-80 градуска кадәр җылыту һәм тиз арада суыту процессы) белән шөгыльләнүгә этәрә. Ул чакта пастеризацияләүне сәламәтлек өчен зарарлы, бушка акча түгү дип санаганнар, шунлыктан Штраусканың аяк чалырга теләүчеләр бик күп булган. Әмма ул үз акчасына АКШ ның 36 шәһәрендә 297 пастеризацияләү станциясе төзеткән. 1891 елда Нью-Йоркта туган балаларның 24 проценты бер яшь тулганчы үлсә, Штраусның пастеризацияләнгән сөтен эчерткән 20111 баланың алтысы гына җан тәслим кылган. Илдә 1891 елда мең баланың 125 есе үлсә, 1925 елда әлеге күрсәткеч 15 кә кадәр кимегән. Кайбер тарихчылар исәпләвенчә, Натан Штраус барлыгы 445800 сабыйның гомерен саклап калган. Алай гына да түгел, 1893 елдагы икътисадый кризис вакытында Штраус сөт станцияләрендә иң арзан бәягә күмер сатуны да оештырган, түләргә хәленнән килмәгәннәргә исә бушка биргән. Юмарт эшкуар, бөтен кирәкле җиһазлар куелган бүлмәле йортлар ачып, 64 мең фәкыйрьне шунда урнаштырган, аларны көн саен 5 центка гына иртәнге аш белән туендырган, 1 центлык 50 мең төшке аш әзерләткән. Үз компанияләрендә эшләүчеләрне көненә бер тапкыр бушлай ашаткан. Натан Штраус 1931 елда 82 яшендә дөнья куйган.

(“Daily Mail”).

Чемпион булу җиңел түгел

Британия боксчысы, 91 килограммнан артыграк авырлыктагы категориядә дөнья чемпионы, 32 яшьлек Энтони Джошуа (буе – 198 см, авырлыгы – 113 кг) җиһанның иң яхшы әзерлекле спортчыларыннан берсе санала. Аның идеаль мускуллары искиткеч куәтле, бетмәс-төкәнмәс энергияле һәм бик чыдам. Мондый нәтиҗәгә ирешү өчен даими күнекмәләр генә түгел, махсус туклану рационы да таләп ителә. Олимпия чемпионының шәхси диетологы Марк Эллисон тәүлеклек рационны үзе төзи, ул 500 г углеводлар, 220 г аксым һәм төрле чикләвекләрдән алынган нибары 50 г майдан гыйбарәт. Мәсәлән, солы боткасындагы җиләк-җимеш углеводларның тиешле запасын булдыра, йогырт, сөт, 4 йомырка, ысланган сөләйман балыгы һәм тостлар башка кирәкле матдәләр белән тәэмин итә. Мондый рацион гади кешегә зыянлы булачак, Джошуа исә көн саен залда 13 әр сәгать шөгыльләнә һәм ашаганда алган калорияләрен яндырып бетерә бара. Энтони бокс белән 18 яшендә генә шөгыльләнә башлаган, тәүге тапкыр чемпион булгач, әнисенә 80 мең долларлык Range Rover автомобилен бүләк иткән.

(“Die Presse”).

Вәгъдә бирсәң – үтә!

Мексикадагы Лас Маргаритас шәһәре мэрын, сайлау алдыннан биргән вәгъдәләрен үтәмәгән өчен, фермерлар пикап машинасына бәйләп кала урамнары буйлап сөйрәп йөргән. Имгәнеп үлүдән аны полиция генә коткарган. Мэрия бинасын да җимерергә җыенган утызлап кеше кулга алынган. Фермерлар элегрәк тә мэрга һөҗүм иткән һәм аны хатын-кыз киемендә киендергән булган инде. Барыбер сүзендә тормагач, бу юлы катырак куркытырга уйлаганнар.

(“TV Azteca”).

Дәва табылачакмы?

Америкадагы Бингемтон университеты галимнәре, химия һәм нурланыш терапиясе булышмаганда, бер-бер артлы җылыту һәм туңдыруның (термаль абляция) ашказаны асты бизендәге яман шеш күзәнәкләрен юкка чыгаруын ачыклаган. Әлеге биздәге яман шеш онкологиянең иң куркыныч формаларыннан санала. Ул якынча һәр 67 кешенең берсендә табыла. Чирләүчеләрнең 95 проценты нәтиҗәле дәвалау чарасы булмаганнан үлә, чөнки хәтта операция ясаганнан соң да күп очракта шеш кабат үсә. Гадәти ысуллар нәтиҗәсез, ә заманча катнаш препаратлар организмны бик каты агулый. Тикшеренү барышында шеш күзәнәкләре 5 минут буена 45-50 градуска кадәр җылытылган яки минус 10-20 градуска кадәр суытылган. Аннары галимнәр җиде көн дәвамында әлеге күзәнәкләрне күзәткән. Икеләтә термаль абляция вакытында – температураны башта 48-50 градуска кадәр җылытып, аннары минус 25 градуска кадәр суытканда – некроз нәтиҗәсендә яман шеш күзәнәкләренең тулысынча диярлек һәлак булуы ачыкланган. Хәзер галимнәр күзәнәкләрне башта туңдырып, аннары җылытып карарга җыена.

(“MedicalXpress”).

Су кадерен кем белә?

Беренче фотода – Нигердагы биш кешелек гаилә, алар көненә нибары өч шешә булганчык су сарыф итә ала. Икенчесендә – Нью-Йоркта яшәүче өч кешелек гаилә һәм алар барысы бергә бер тәүлектә кулланган су. National Geographic фотографы, Һиндстаннан алып Боливиягә кадәр алты илдә булып, ЮНИСЕФ (БМОның Балалар фонды) өчен мәгълүмат туплаган – башта кешеләрдән көненә күпме су сарыф итүләрен белешкән, аннары аларны тәүлеклек нормалары күләмендәге су салынган пластик шешәләр янында фотога төшергән.

(“t.me/NationGeographic”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

4 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 12+
10.00, 23.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Ком сәгате». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Наил Әюпов турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+
0.55 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Вычеркнуть и забыть».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Черные дыры. Белые пятна.
8.50 «БРОНЗОВАЯ ПТИЦА».
10.15 Красуйся, град Петров! «Мосты».
10.45 Academia. Александр Ващенко. «Сравнительная мифология».
11.30 «Чистая победа. Битва за Севастополь».
12.15 Дороги старых мастеров. «Палех».
12.30 «АДМИРАЛ НАХИМОВ».
14.00 Линия жизни. Наталья Варлей.
15.05 «Музеи без границ». Музей истории Екатеринбурга.
15.35 «Галина Уланова. Незаданные вопросы».
16.30 Симфонические оркестры России. Большой симфонический оркестр им. П.И. Чайковского. Дирижер Владимир Федосеев.
17.35 «2 Верник 2».
18.20 Дмитрий Назаров в фильме-спектакле «Абонент временно недоступен».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 «Сати. Нескучная классика...»
21.15 «Подземные дворцы для вождя и синицы».
21.55 «ГОРОД ЗЕРО».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.40 «ДАЙВЕР». 16+

Сишәмбе

5 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Теймә».
16.00 «Моё колесо фортуны. Николай Зеленов». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Кыр казлары артыннан». Мәсгуть Имашев турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Русская невеста для кровного врага».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Накануне Первой мировой войны».
8.50 «ПОСЛЕДНЕЕ ЛЕТО ДЕТСТВА».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Альфред Парланд. Спас на Крови.
10.45 Academia. Александр Ващенко. «Сравнительная мифология».
11.35 Абсолютный слух.
12.20 «Подземные дворцы для вождя и синицы».
13.05 «ГОРОД ЗЕРО».
14.45 Цвет времени. Эль Греко.
15.05 «Музеи без границ».
15.35 «Диалог с легендой. Ольга Лепешинская».
16.30 Симфонические оркестры России. Государственный академический симфонический оркестр Республики Татарстан. Дирижер Александр Сладковский.
17.25 Больше, чем любовь.
18.05 Марина Неёлова в фильме-спектакле «Шинель». По мотивам постановки Московского театра «Современник».
18.50 Цвет времени. Карандаш.
19.00 «Лесной дворец Асташово».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 К 65-летию Юрия Стоянова. «Белая студия».
21.15 «Невидимый Кремль».
21.55 «ЦАРЕУБИЙЦА».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.40 «ДАЙВЕР». 16+

Чәршәмбе

6 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Сәхнә күрке - сүз». Рәшит Сабиров турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Солдат своего Государя».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «От Генуи до Мюнхена».
8.50 «ПОСЛЕДНЕЕ ЛЕТО ДЕТСТВА».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Карл Росси.
10.45 Academia. Александр Ужанков. «Загадки «Слова о полку Игореве».
11.35, 20.30 Абсолютный слух.
12.20 «Невидимый Кремль».
13.05 «ЦАРЕУБИЙЦА».
14.45, 23.25 Цвет времени. Ван Дейк.
15.05 «Музеи без границ». Омский музей изобразительных искусств имени М.А.Врубеля.
15.35 «Бессмертнова».
16.25 Симфонические оркестры России. Государственный академический симфонический оркестр имени Е.Ф. Светланова. Дирижёр Роберт Тревиньо.
17.35 «Франция. Замок Шамбор».
18.05 Спектакль «Вечер с Достоевским».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Дотянуться до небес».
21.55 «ДЕНЬ ПОЛНОЛУНИЯ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.40 «ДАЙВЕР». 16+

Пәнҗешәмбе

7 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әнвәр Бакиров турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.

9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Роза для королевы».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Великая Отечественная война».
8.45 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
8.55 «ПОСЛЕДНЕЕ ЛЕТО ДЕТСТВА».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Доменико Трезини. Петропавловская крепость.
10.45 Academia. Александр Ужанков. «Загадки «Слова о полку Игореве».
11.35 Абсолютный слух.
12.20 «Дотянуться до небес».
13.05 «ДЕНЬ ПОЛНОЛУНИЯ».
14.40 Цвет времени. Караваджо.
15.05 «Музеи без границ». Коломна. Музей пастилы.
15.30 «Раиса Стручкова. Я жила Большим театром».
16.25 Симфонические оркестры России. Симфонический оркестр Мариинского театра. Дирижер Валерий Гергиев.
17.25 «Каждый выбирает для себя».
18.05 Спектакль «Друзей моих прекрасные черты».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 К 85-летию Владимира Ашкенази. «Энигма».
21.10 «Bauhaus на Урале».
21.55 «ВСАДНИК ПО ИМЕНИ СМЕРТЬ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.40 «ДАЙВЕР». 16+

Җомга

8 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.45 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+
23.30 «ПОЗДНЯЯ ВСТРЕЧА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Рафаэль Сахәбиев турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05 «Аклык турында җыр». Зөһрә Сахәбиева турында телеочерк. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ДОРОГА ПЕРЕМЕН». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «МУЖЧИНА И ЖЕНЩИНА». 16+
23.45 «МУЖЧИНА И ЖЕНЩИНА. ЛУЧШИЕ ГОДЫ». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «БЕЛЫЙ ТИГР». 16+
23.25 «ЗИМНИЙ ВЕЧЕР В ГАГРАХ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Легко ли быть великим князем?»
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Великое противостояние».
8.45 «ПРОДЕЛКИ СОРВАНЦА».
10.20 «МУЗЫКАЛЬНАЯ ИСТОРИЯ».
11.45 Academia. Александр Ужанков. «Повесть о житии святых Петра и Февронии Муромских».
12.30 «Лесной дворец Асташово».
13.00 «ВСАДНИК ПО ИМЕНИ СМЕРТЬ».
14.45 «Забытое ремесло».
15.05 «Музеи без границ». Ивановский музей промышленности и искусства.
15.35 Симфонические оркестры России. Заслуженный коллектив России Академический симфонический оркестр Санкт-Петербургской филармонии. Дирижер Юрий Темирканов.
16.20 Острова.
17.00 «ВЗЯТКА. ИЗ БЛОКНОТА ЖУРНАЛИСТА В. ЦВЕТКОВА».
19.45 Искатели. «Пропавшие шедевры Фаберже».
20.35 70 лет Карену Шахназарову. Линия жизни.
21.30 «МЫ ИЗ ДЖАЗА».
22.55 «Мы из джаза. Проснуться знаменитым».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.40 «ДАЙВЕР». 16+
23.30 Концерт «GO!» 16+

Шимбә

9 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Корбан гаете мөбарәк булсын!» 6+
12.00 «1100 лет принятия ислама Волжской Булгарией». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Каравай». 6+
14.00 Спектакль «Мәхәббәт турында сөйләшик». 12+
16.35 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбленә 10 яшь». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Ватандашлар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.45 «ПРОДЛИСЬ, ПРОДЛИСЬ, ОЧАРОВАНЬЕ...»

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 Концерт «Мөнәҗәт әйтәм». 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Корбан гаете мөбарәк булсын!» 6+
14.00 «Риваять» этно-төркеменең юбилей кичәсе. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 6+
22.30 Спектакль «Зөбәйдә - адәм баласы». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 0.40 «Вместе по России». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Наша марка 2». 12+
8.15 «РАСПЛАТА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЕЛЛЬ И СЕБАСТЬЯН: ДРУЗЬЯ НАВЕК». 6+
14.30 «Прокуроры 4. Матиас Руст. Невозможное возможно». 12+
15.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
16.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПРИМАДОННА». 16+
23.00 «КЛАН КЕННЕДИ: ПОСЛЕ КАМЕЛОТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Курбан-Байрам».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 Специальный репортаж. 16+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.55, 15.15 «Прерванный полет Гарри Пауэрса». 12+
16.10 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ОГНЕННАЯ ДУГА». 12+
18.20 РЭБ. 16+
21.00 «Время».
21.35 «День семьи, любви и верности». 12+
23.45 «МАЛЕНЬКАЯ МИСС СЧАСТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «Формула еды». 12+
9.00 Праздник Курбан-Байрам.
9.55 «По секрету всему свету».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ТАМ, ГДЕ ТЫ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВХОДИТЕ, ЗАКРЫТО!» 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Приключения Незнайки и его друзей».
8.45 «ВСЕГО ОДИН ПОВОРОТ».
9.55 «Обыкновенный концерт».
10.25 «Передвижники. Павел Корин».
10.55 «МЫ ИЗ ДЖАЗА».
12.20 «Мы из джаза. Проснуться знаменитым».
13.00 Музыкальные усадьбы. «Здесь хорошо. Сергей Рахманинов».
13.30 «Дикая природа Баварии».
14.25 «Дом ученых». Вадим Гладышев.
14.50 «Яркая комета».
16.10 «Энциклопедия загадок».
16.45 «ДЕНЬ АНГЕЛА».
17.55 «Первые в мире».
18.10 «Красота по-русски».
19.05 «Лютики-цветочки «Женитьбы Бальзаминова».
19.45 «ЖЕНИТЬБА БАЛЬЗАМИНОВА».
21.15 «Ночь Чайковского».
23.00 «Фрида. Да здравствует жизнь!» 16+

«НТВ»

4.55 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.35 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
22.15 «Маска». 12+

Якшәмбе

10 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Син минем тиң ярым...» Зинира һәм Ризат Рамазановлар концерты. 6+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Наша Республика - Наше дело». 12+
12.00, 19.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.00 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Ркаил Зәйдулланың юбилей кичәсе. 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.30 «Әдәби хәзинә». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
22.00 «МАЛЕНЬКАЯ МИСС ДУЛИТЛ». 6+
23.40 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Банкрот». 12+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Минем күңел». Җәвит Шакировның юбилей кичәсе. 6+
16.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Зур туган көн концерты». Гөлназ Сәфәрова. 6+
22.10 Спектакль «Бурлак». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Эпидемия». 12+
8.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
9.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЖИМ ПУГОВКА И МАШИНИСТ ЛУКАС». 6+
15.00 «Наша марка 2». 12+
15.15 «РАСПЛАТА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖЕНИХ НАПРОКАТ». 16+
23.00 «ЗАЩИТНИК». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.05, 6.10 «ТАБОР УХОДИТ В НЕБО». 12+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Юрий Никулин. Великий многоликий». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
13.50, 15.15 «О ЧЕМ ОНА МОЛЧИТ». 16+
18.20 К 100-летию Юрия Никулина. 16+
19.10 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА».
21.00 «Время».
22.35 «КОМИТЕТ 19-ТИ». 16+

«РОССИЯ»

5.30, 8.35 К юбилеям Ильи Олейникова и Юрия Стоянова. «Городок. Лучшее».
8.00 Местное время. Воскресенье.
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ТАМ, ГДЕ ТЫ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 «Приключения Незнайки и его друзей».
8.50 «ДЕНЬ АНГЕЛА».
10.00 «Обыкновенный концерт».
10.30 «ЖЕНИТЬБА БАЛЬЗАМИНОВА».
11.55 «Лютики-цветочки «Женитьбы Бальзаминова».
12.40 Письма из провинции.
13.10 Диалоги о животных.
13.50 «Коллекция».
14.20 Сергей Шакуров в фильме-спектакле «Полтава».
15.30 «Первые в мире».
15.45, 23.40 «ПРЕСТУПЛЕНИЕ ЛОРДА АРТУРА».
17.20 «Пешком...»
17.45 «Океан надежд».
18.25 65 лет Юрию Стоянову. Творческий вечер в Доме актера.
19.30 Новости культуры.
20.10 «БАЛЛАДА О ДОБЛЕСТНОМ РЫЦАРЕ АЙВЕНГО».
21.40 Большая опера.

«НТВ»

4.55 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.30 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.40 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
22.15 «Маска». 12+

Иң авыры – балаларга...

Тумыштан авыр язмышка дучар балалар күп. Үз ата-аналарыннан җәбер-золым күреп яшәргә, яисә чит гаиләләрдә тәрбияләнергә, ятим балалар йортларында үсәргә мәҗбүр алар. Әлбәттә, күпчелек очракта моңа эчкечелек сәбәпче.

Тумышы белән Түбән Кама районыннан булган 1996 елгы Екатерина Гаранина шул зәхмәт аркасында түбән тәгәрәгән затларның берсе. 2020 ел азагында «сожителе» белән аерылыша ул һәм ана капиталына Яңа Чишмә районындагы Рус Волчья Бистәсе дигән авылда иске йорт сатып алып 2016 елгы улы Илья, яңа туган кызы Мария (балаларның исемнәре үзгәртелә) белән шунда күченә. Ошбу хатынның юньсез икәне авыл гына түгел, тиз арада район оешмаларына да барып җитә. Әтиләре үлгәнгә күрә, туйдыручысын югалтучы булачак балаларга пособие түләнә, ләкин ошбу акча алар хаҗәтенә тотылмый диярлек, өйдә сәрхушләр, башлыча, ир-атлар җыелып эчә, шунда ук тәмәке тарталар, буш шешәләр, төпчек, чүп-чар ауный. Кыскасы, балалар коточкыч шартларда көн күрә.

Сәрхуш ананың алар өчен акчасы да калмый. Ни хикмәт, балаларны ул кайгыртмый, башлыча, 12 яшьлек күрше кызы Анна карый, ошбу игелек иясе аларга макарон ашата, өеннән алып чыгып бәрәңге пешереп бирә. Аның әнисе Т.Зубатова: «Яңа Чишмәгә азык-төлек алырга барганда, Екатеринадан сиңа нәрсә алып кайтыйм дип сорагач, сыра, сигарет ал, балаларга берни кирәкми дип әйтә иде», – ди. Кыскасы, хәмер булса, бала кайгысы калмый анда. Эчәргә шешәдәшләр табыла, 15 яшьлек укучы кыз бала: «Катя исергәнче эчә, әнием ачуланганга күрә мин күп эчми идем», – дип аклана әнә.

Мәсьәләнең тагын бер яман ягы бар, ягъни исерек хатын еш кына ачуын балалардан ала. Чынлыкта, гел шул балалар янында кайнашкан Анна киемен пычратса, уенчыкларын җыеп куймаса, әни кешенең Ильяга ныклап эләктерүен, кечкенә кызчыкны елаган өчен диванга ыргытуларын сөйли, аларны юата, тынычландыра идем, ди. Мондый шартларда ачлы-туклы яшәгән балалар еш авырыйлар, начар үсәләр, Маша бер яшендә тәпи йөрү түгел, тотынмыйча басып та тора алмый, юынмаганга күрә, Ильяның күзләре эренли h.б. Бу хәл дәүләт оешмалары игътибарыннан читтә калмый, тикшерергә килүчеләргә ишек ачмаган чаклар да була, ә өйдән бала елаган тавышлар ишетелә, кай ара анда шау-шулы мәҗлесләр бара. Йөгәнсез хатын балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия утырышларына да килми, килсә дә, файдасы булмый. Хәвефле гаилә махсус исәптә тора.

Өстәвенә, узган ел туктаусыз эчеп йөри торган хатын авырлы булып чыга, өч-дүрт көн РКБда «сохранение»дә дә ятып чыга, берничә тапкыр табибләргә дә күренгәли, анда ошбу бала кирәк түгел миңа, дип сөйләнә. Кирәкмигә карамый дигәндәй, 2020 елның июль ае азагында вакытыннан шактый иртә үз өендә ир бала таба, кило ярым авырлыктагы җитлекмәгән нарасыйны ашыгыч рәвештә Түбән Камадагы махсус клиникага алып китәләр, Екатерина өендә балалары белән кала. Авыл табибе сырхауханәдә бер ай яткан сабыйны анасына август азагында алып кайтып тапшыра. Билгеләп үтмичә булмый, яшь бала өчен кирәк-яракны, дарулардан алып памперс, биләүләргә кадәр игелекле авыл халкы җыеп бирә.

Бала туу акылга утыртмый аны. Ягъни эчү дигәнең бер кая да китми. Узган ел әбиләр чуагының матур көнендә Е.Гаранина дуслары белән чишмә янында «ял итә». Бу вакытта өч сабый янында безгә мәгълүм Анна була. Авылда ошбу галәмәтне район үзәгенә хәбәр итүчеләр табыла, нәтиҗәдә, икенче көнне үк, көнне 21 сентябрьдә аннан җаваплы кешеләр, табибләрдән торган комиссия килеп төшә. Тәртипсезлек хөкем сөргән өйдәге каралмаган, юындырылмаган сабыйлар һәркемне тетрәндерә, алар өчен иң кирәкле әйберләр дә, хәтта ашарга да булмый анда. Ә менә өч бала анасы салмыш йөри. Балаларны район сырхауханәсенә алып баралар, бигрәк тә уртанчы кызчыкка күп диагноз куела, аларны ошбу ханым кулында калдыруга ярамавы аңлашыла. Е.Гаранина моны үзе дә аңлый, балаларга тиешле тәрбия күрсәтә алмавын белдерә, аларны дәүләт оешмалары карамагына тапшыруны сорап гариза яза. Шул рәвешле, балаларның ике кечкенәсе Чаллыдагы сабыйлар йортына, олы малай күрше Алексеевское бистәсендәге «Забота» дигән социаль приютка урнаштырыла.

Приют директоры М.Солдатова биш яшьлек Ильяның тормышындагы мондый кискен борылышны бик авыр кичерүен әйтә. Нинди генә булса да иң якын кешесен югалткан малай беренче көннәрдә әнисен эзләде, сәгатьләр буена тәрәзәгә карап аны көтеп утырды, чит кешеләрдән курыкты, ятсынды, гомумән, бик авыр ияләште, ди. Ләкин язмыштан узмыш юк дигәндәй, тора-бара җайлаша, аң-белем өлкәсендәге арттаглыгын да киметә, активлаша бара ул.

Әлбәттә, әнисен онытты дигән сүз түгел бу. Әмма ул балалары янына килеп тә карамый. Быел гыйнвар аенда авылдагы өен бикләп, Түбән Камадагы

абыйсы янына китеп бара. Әмма бу яклар белән араны өзә алмый ул, чөнки хокук саклау органнары аның балаларына карата кылган явызлыкларын өйрәнә. Шаһитлар күп булганга, бу эш әллә ни зур хезмәт сорамый. Ахыр чиктә, тикшерү комитетының Чистай районара бүлегеннән Ленара Гыйбадуллина дүрт эпизодлы җинаять эше кузгата. 26 яшьлек Е.Гаранина, гади итеп әйткәндә, уртанчы һәм олы балаларына тиешле тәрбия бирмәү һәм аларны даими рәвештә кыерсыту, җәберләүдә гаепләнә.

Бәлки эшнең шулай зурга китүе куркыткандыр, тиздән Екатерина эчүдән туктый. 2 февральдә биргән күрсәтмәсендә ул эчкечелектән дәвалана башлавын, эшкә керергә җыенуын, балаларын бик яратуын, аларны үзенә кайтарырга шартлар тудырырга тырышачагын һәм балаларына карата рәхимсез кылануын тануын белдерә. Яңа Чишмә район суды өч бала анасына мәрхәмәтлелек күрсәтеп, җиңелрәк җәза бирер дә, аңа төзәлергә һәм балаларын үз янына алырга мөмкинлек калдырыр кебек.

* * *

Шул ук районлагы татарлар Черемухово Бистәсе дип йөртә торган авыл кешесе Александр Данилов, яшүсмер үги кызын җәберләгән өчен суд каршында җавап тотачак. Монысы да – ирле-хатынлылар эчкечелеге нәтиҗәсе.

Татьяна белән 2008 елдан бирле яши алар, ул чакта хатынның беренче иреннән тапкан кызына бер генә яшь була, ягъни Валерия соңрак дөньяга килгән ике уртак кызлары белән кечкенәдән тәрбияләнә. 2018 елда Александр аны рәсми рәвештә кызлыкка ала, балага туу турындагы яңа таныклык бирелә. Ир белән хатын маллар асрап, җирле «Закрома» җәмгыятендә эшләп яшиләр. Алдан тормышлары үз җае белән бара, гаиләне хәмер дигән золым яулап алгач кына, эшләр кирегә тәгәри. Эчкечеләр гаиләсе иҗтимагый куркыныч дип табылып районда исәптә дә тора, айнып китеп юньләп яши башлагач, кара исемлектән сызыла, ләкин берникадәр вакыттан алар тагын «запой»га китә.

Узган ел май аеннан декабрь азагына кадәр ташланып эчәләр, эшкә йөрмиләр, үзләренең өч сыер, бер танадан торган хуҗалыкларын да карамыйлар. Әлеге вазифалар 14 яшьлек Валериягә йөкләнә, кыз бала иртәнге сәгать 4 тә торып сыерларны сава, сөт тутырылган авыр савытларны күтәреп кабул итүчегә илтә, малларны ашата, эчертә, асларын җыештыра. Ул чакта кич белән сыйланып утырган сәрхушләр йокы симертә, яшүсмер кыз уятып ярдәмгә дәшеп караса да, тупас сүзләр генә ягъдырый. Авылда уртак кызлары артык иркә тәрбияләнә, олы кыз кыерсытыла дип әйтүчеләр бар. Әлбәттә, сәрхушләр янында 2009, 2015 елларда туган Карина белән Настя да балда, майда йөзмәгәндер, әмма хуҗалык эшләре, шул исәптән, аш-су хәзерләү мәшәкатьләре Валериягә йөкләнүе хак.

Өстәвенә, үги ата абзарны начар чистарткансың дип, яисә башка берәр сәбәп табып аны кимсетеп әрли, хәтта кул күтәргән чаклары да була. 2021 елның август азагында шундый бәрелешләрнең берсеннән соң, тәгәлрәге, исерек ир төртеп егып бәрелгәч, авыз-борыныннан кан киткән Валерия шул авылда яшәүче әби-бабай, ягъни әнисенең әти-әнисе янына чыгып чаба. Ике генә яшькә өлкәнрәк апасына теләктәшлек күрсәтеп, Карина да шунда китә, ләкин ул соңрак кире кайта, ә олы кызның хәтта өйдәгеләр узган елның декабрь азагында дәваланып эчүдән туктагач та рәсми кәгазьләрдә атасы саналган, ләкин үги булып калган кеше янында торасы килми, әби-бабай һәм аларның үзе белән яшьтәш, димәк, бер сыйныфта укучы кызлары Светлана белән яшәвен дәвам иттерә.

Яшүсмернең үги атасы тарафыннан җәберләнүе хак. Бу очракта аның үз анасы, үз каны кая караган дигән сорау туа. Җан тартмаса да кан тарта диләр бит. Ә монда берсе дә тартмаганга охшаган. Исерек хатын ире җәберләгәндә, үз баласын якламау гына түгел, шул кирәк сиңа дип торган, үзе дә аны еш кимсеткән, кыз һәм шаһитлар әйтүенчә, Валериянең тышкы кыяфәтен яманлаган чаклары да булган. Әлбәттә, болар көчеш чоры баласының рухи халәте, үсешенә тискәре йогынты ясамый калмый.

8 нче сыйныф укучысының, чынлыкта, анасы һәм рәсми атасыннан баш тартуы укытучылар, җирле үзидарә, район оешмалары игътибарыннан читтә калмый. Бикләнеп эчеп ятучыларның тикшерүчеләрне кертмәгән чаклары да була. Былтыр декабрь ае башында тәртипсезлек хөкем сөргән өйгә узып, сәрхуш хуҗалар нык кисәтелә, балаларны дәүләт карамагына алу хакында да әйтелә. Шуннан эчә-эчә үзләре дә арган Даниловлар эчкечелектән дәваланырга булалар да инде.

Полиция һәм тикшерү комитеты әлеге гаиләдә булган хәлләрне өйрәнә торгач, ир кеше гамәлләре РФ Җинаять кодексы кысаларына эләгә дип таба. Быел март аенда аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Л.Р. Гыйбадуллина инде айнып фермада эшләп йөргән А.Даниловка карата ике эпизодлы җинаять эше кузгата. Кыскача гына әйткәндә, Александр балигъ булмаган кызны кимсеткән, кыйнаган, борынын канаткан өчен, балаларны системалы рәвештә кыйнау турындагы 117 нче һәм аларга тиешле тәрбия күрсәтмәү хакындагы 156 нчы маддәләр буенча гаепләнә. Җинаять эше май аенда суд карамагына бирелде. Бәйрәм ашы – кара каршы дигәндәй, хәзер инде ир затының язмышы, ягъни җәзаның кырыслыгы күбрәк кызга бәйле. Әгәр ул хөкем утырышларында нык торса, А.Даниловка таякның юан башы эләгергә мөмкин.

Наил ВАХИТОВ.

ЧУЛПАН ШӘМАИЛЛӘРЕ



Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, каллиграф Чулпан Шәрифуллина 1978 елда Чаллыда туган. Шәһәрнең 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбен, Чаллы педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетын тәмамлаган. Берничә ел дәвамында каланың шушы педагогика институтында, Кама сәнгать һәм дизайн институтында студентларга белем биргән. Хәзерге көндә «Арабеска» дип аталган үз сәнгать студиясендә балаларны һәм өлкәннәрне рәсем ясауга һәм декоратив-гамәли сәнгатькә төшендерә.

«Педагогика институтында укыганда да, урта мәктәптә рәсем дәресләрен алып бардым, – дип искә ала Чулпан. – Студент чорымда һәммә ысулга өйрәнергә тырыштым, укытучыларыма сорауларны күп яудырдым, кызыксынучан холыклы булуымны мөгаллимнәр дә мактады. Рәссам үсештә булырга тиеш бит. Менә хәзер мин башка рәссамнар белән берлектә иҗади пленэрларга йөрим, пейзажлар ясыйм. Башка иҗатчылар белән аралашу да һөнәри белемнәрне ныгыта.

Гаиләбездә ирем белән ике кыз бала үстерәбез. Беренче кызыбыз тугач, 2005-2009 елларда читтән торып «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыдым. Укытучыбыз Әхмәт хәзрәт Сабиров гарәп каллиграфиясенә юнәлеш бирде. Тик читтән торып уку сәбәпле гарәп каллиграфиясенә өйрәнү сәгатьләре күп эләкмәде инде. Шулай да «Мөхәммәдия»дәге әлеге дәресләр – әле дә күңелем түрендә. Шушы мөгаллимебез йогынтысында, мин дә 2005 елда беренче шәмаилләремне ясап карадым һәм бу сәнгать юнәлешен үз иттем».

Чулпан Илгизәр кызының беренче шәмаилләре традицион орнаментлы, гадирәк композицияле булган, ул мондый бизәлештәге «Аятел-көрси» догасын каткат язган. Тора-бара шәмаил ясау һөнәрен камилләштергән һәм аның нечкәлекләрен өйрәнүне әле дә дәвам итә.

«Мин төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә, шул исәптән 2009 елда оештырылган I Бөтенроссия каллиграфия бәйгесендә дә катнаштым. Ә 2016 елда «Шәмаил – гаиләм ядкәре» Бөтенроссия бәйгесенең «Заманча традицион татар шәмаиле» номинациясендә «Кышкы Әҗем мәчете» әсәрем белән I урынга лаек булдым. 2010 елда Татар шәмаиле галереясында оештырылган Халыкара каллиграфия күргәзмәсендә катнашуым да истә калды.

Шәмаилләрне сюжетлы композицияләр, натюрморт яисә пейзаж жанрлары белән дә бәйләргә уйладым, шулай итеп зур күләмле әсәрләремнең саны артты. Яңа шәмаил идеясе хакында күп уйланып йөрим. Бер фикергә, бер ысулга киләм, эскизларга алынам. Аннары төп эскизны көзгедәгечә итеп салып, пыяла өслеккә күчерәм. Бизәлешне акрил буяулар яки темпера белән башкарам. Иҗат юлым башында пыялага майлы буяулар белән дә ясап карадым, тик алар озак кибә. Пыялага ясауның үз үзенчәлекләре бар. Җитди шәмаилләр тиз ясалмый. Моның өчен хәтта бер яисә ел ярым вакыт таләп ителә», – ди инде өч дистәгә якын күргәзмәдә катнашкан рәссам-каллиграф.



Останың әсәрләре гаять төрле. Әйтик, Г.Тукайның «Шүрәле» әсәреннән Кырлайга багышланган шигъри юллар гаҗәеп картинада матур чәчәкләр, җиләкләр, авыл күренеше белән бергәләштерелеп бирелгән. Моннан кала Чулпан хатын-кыз исемнәрен тугра ысулында иҗат итә, аларны күп очракта чәчәк сурәтләре эченә урнаштыра. Аның «Җәннәт – аналарның аяк астында» хезмәте исә борынгы чүпылларыбыз сурәтләре аша барланган, һәрберсенә ислам тарихында эз калдырган хатын-кыз исемнәре язылган: Хәүва, Асия, Мәрьям, Һаҗәр, Әминә, Хәдичә, Гайшә һәм Фатыйма радыйаллаһу ганһүм. Рәссам-каллиграф үз шәмаилләрендә Аллаһы Тәгаләнең 99 күркәм исемен лалә чәчәкләре, умарта кортлары кәрәзләре эчләренә дә язган. Мондый әсәрләренең кайберләре Чаллы картиналар галереясында, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгында, Казанның Ислам мәдәнияте музеенда саклана.

«Арабеска» сәнгать студиясенә йөрүчеләр арасында өлкәннәр дә бар. Чаллы ханымнары татар шәмаилләрен үзләренчә, башкаларны кабатламый торган өслүбтә ясарга омтыла. Кайберләре сайлаган ысулын җентекләп өйрәнеп, пыялаларга натюрмортлар да иҗат итә. Остазлары аларның эшләреннән аерым күргәзмә оештыру турында да хыяллана.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 1.07.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2759

16+